КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 18
17 ноябрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Әхәт ФАЗЫЛҖАНОВ.* Чын мәгънәсендә сүз ирреге бирелгәч кенә бөтенләй көндәлек матбугатсыз калабыз бугай.

9 *Мәдинә НУРУЛЛА.* Татар китабы язмышы да халык язмышына охшаган: аны да яндырганнар, юк иткәннәр.

14 *Әлһап ХӘЙРУЛЛИН.* Халыкның рух байлыгын саклый белгән ил генә матди яктан да бай була ала.

19 *Булат СОЛТАНБӘКОВ.* 30 нчы еллар башы һөҗүмчән алласызлыкның котырган еллары була.

23 *Алмаз ХӘМЗИН.* Сәхнәдә ялтыраганда гына түгел, аннан төшкәч тә талантларның кадерен белергә өйрәнсәк, алар эстрадада озаграк яшәр иде.



Көлләрдән яралган кош булып Казанда һәйкәлләр терелә...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Эвене янган кешедәй, һәрдаим кәвеш башына карап йөрү адәм баласының өстәмә көчләрен суыра, отыры... рухын бөкрәйтә. Безгә мондый басынкы халәттә күпме яшәргә туры килде! Тәмам өметсезләнмик әле. Башыбызны бераз гына югарырак тотыйк. Күккә багарга вакыт табыйк: Кояштан — йөрәгебезгә, йолдызлардан зиһенебезгә илаһи җылылык иңгәнен тоярбыз. Беразга гына булса да тормыш авырлыклары онытылыр... Яшәү гаме тулган башыбызны калкыта төшик әле, туганнар!..

Мансуров Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Чын мәгънәсендә сүз иреге бирелгәч кенә бөтенләй көндәлек матбугатсыз калабыз бугай, җәмәгать. Бу елларда газит-журналларыбызның тиражы күзгә күренеп кимеде һәм әле һаман үсүгә йөз тотмый. Сәбәпләренә килгәндә, алар шактый күп. Беренчедән, газит-журналларга капылт кына сикергән бәяләр күпләрнең күңелен кайтарды, мөмкинлекләрен һәм теләкләрен чикләде. Монысы, мәгаен, иң зур һәм җитди сәбәпләрнең берседер. Икенчедән, соңгы елларда матбугат иреге нәтиҗәсендә мәйданга байтак кына әр-яңа басмалар чыкты. Үз чиратында алары да моңарчы нәшер ителеп килгән басмаларның тиражын сизелерлек «ашады», үз укучыларын тапты. Инде ахыр чиктә, кайбер редакцияләрнең бөтенләй яшәүдән туктау ихтималы да юк түгел. Әмма андый язмыш белән бервү дә килешергә теләмәс. Бөтенесе җан сакларга тырыша, исән калу әмәлен эзли. Бүген сүзем күбрәк әнә шул «әмәл»ләрнең берсе хакында.

Белмим, кайсы бәндәсе уйлап чыгаргандыр, хәзер күп кенә районнарда көндәлек матбугат таратуның бик җиңел ысулын эзләп таптылар: теге яки бу басмаларны, кешеләр укырга теләсә-теләмәсә дә, редакцияләр гозере буенча бүләк рәвешендә өләшә башладылар. Әмма дөресен әйтим, әнә шул «бүләк» сүзе артында шактый ямьсез һәм ачы хакыйкать ята. Бу очракта редакция вәкилләре уптым илаһи әбүнәне рәсмиләштерүне үстереп, күбрәк колхозларга, совхозларга мөрәҗәгать итәләр. Штаттагы хәбәрче сыйфатында моннан элегрәк шундый ук үтенеч белән йөз ертып, тәмам бер мескенгә сабышып, үземнең дә байтагының бусагасын таптаганым булды. Хәер, күп очракта колхоз рәисләрен, совхоз директорларын үземнән дә мескенрәк халәттә күрә алдым. Уйлап карагыз, авыл кешесенә өчәр-дүртәр ай хезмәт хакы түли алмыйлар, ул гына да түгел, яңа техника, ашлама һәм төрле химикатлар сатып алырга кирәк, терлек әбзарларын, машина-трактор паркларын яңартасы бар. Бөтенесенә акча кирәк — теләсәң кайдан юнәт. Ниһаять игеннәрне җыеп урнаштыргач, хуҗалыклар бераз тернәкләнеп китмәсме дигән өметләр дә акланмады бит, быел уңышы чамалы гына булды. Ә син бүләк дисең. Әтән арасында бәтән дигәндәй, шундый вакытта без бимазалап йөрибез. Очын-очка ничек ялгап чыгасын белмичә, тәмам аптырашта калган колхоз рәисе бүлмәсенә үз гозерем белән бүрегемне салып кермәс өчен, валлаһи, әллә ниләр бирер дәрәҗәгә җитә идем.

Теләсәгез ни әйтегез, шәхсән мин үзем вакытлы матбугат таратуның мондый ысулын өнәп тә бетермим һәм аның юньле киләчәген дә күрмим. Юк, газит-журналларны һәм аларның редакцияләрен саклап калуның ышанычлы «әмәле» бу түгел. Минемчә, беренче урынга кешеләр белән шәхсән эшләүне куярга кирәк. Юкса, бездә нәкъ әнә шунысы аксый.

Әхәт ФАЗЫЛҖАНОВ

Безнең матбугатны ни көтә?

матбугатка язылу кампанияләре бу елларда тулы мәгънәсендә үзагымына куела, бу җәһәттән мәшәкатьнең иң зурысы журналистлар җилкәсенә төшә. «Союзпечать» хезмәткәрләре хәзер бүлмәләрендә үз аяклары белән килгән әбүнәчеләргә квитанцияләр тутырту белән генә мәшгульләр, беркая чыкмыйлар, үгет-нәсыйхәт дигәне алар өчен бөтенләй ят нәрсә булып калды.

Газит-журналларга әбүнә белән бүләкләүнең мин үтә зарарлы бер ягын күрәм. Әйтик, колхоз яки совхоз кемнәрнедер елның беренче яртысына подписка белән бүләкләде, ди. Ә ул бүләккә лаек булганнар икенче яртыеллыкта да бушлайга өмет сузачак бит, акчасын түләп язылу хакында уйлап та карамаячак. Бүләк дигән нәрсә һаман булып тормый бит ул. Болай итеп әбүнәчеләрне бозып, икеләндереп кенә бетерәбез.

Мәсьәләнең тагын шул ягы бар: редакцияләр үз басмаларына язылуны күпләп колхоз-совхозлар яки предприятиеләр аша оештырып, үзләренең мөстәкыйльлекләрен, принципиальлекләрен корбан итәләр, азмы-күпме юмартлык күрсәткән коллективлар алдында өҗәтле калалар, ә ул өҗәт исә теге яки бу кимчелекләрне йомып калу, коллективның бар-лы-юклы уңышын да күпертеп-шомартып язу белән түләнә. Үзебезнең баштан үткән, бу кадәресен генә беләбез. Бу уңайдан кечкенә генә бер мисал. Балтач районының «Дружба» күмәк хуҗалыгы быелның беренче яртысы өчен унбишләп кешене өлкә газитләренең берсенә (билгеле, инде, редакция гозерен тыңлап) әбүнә белән бүләкләгән иде. Күпмедер вакыттан соң нәкъ шул басмада дружбалылар адресына, аз да түгел, күп тә түгел, бары бер җөмлә белән кечкенә генә тәнкыйть фикере әйтелгән иде. Соңгы чиктә хуҗалык рәисе, әнә шуңа ачу йөзеннән, икенче яртыеллыкка подписка яңартудан баш тартты.

«Арча хәбәрләре» газите быелның икенче яртысына тиражны тулаем диярлек колхоз-совхозлар һәм предприятиеләр ясаган «бүләк» хисабына җыйды. Иманым камил, «бүләктән» өлеш чыгарган коллектив хуҗалары адресына моннан соң тиз генә газит битләрендә кискен тәнкыйть сүзе булмаячак. Гаҗәп түгел, редакция хезмәткәрләре әле якын киләчәктә дә түбәнчелек белән шул ук хуҗалык җитәкчеләре каршысына барасыларын уйлыйлар. Матбугат әнә шулай итеп акчага сатыла.

Миңа калса, район газитләренең тиражын шушылай җыйнау зарурлыгы алай ук кискен тормый дип беләм. Алары болай да авырдан таралмый бит. Беренчедән, язылу бәяләре өлкә газитләренекеннән күпкә түбән, икенчедән, районда яшәп тә үз төбәгендәге яңалыклардан кемнең генә хәбәрдар буласы килмәс икән. Ул җөмләдән мин «Саба таңнары» газитенең эш тәҗрибәсен күпләргә үрнәк итеп куяр идем. Редакция коллективы (мөхәррире Т Нәҗмиев) чагыштырмача шушы кыен шартларда да элекке хезмәт ритмын, үз стилен югалтмыйча, хәбәрчеләр белән эшләүне аз гына да йомшартмады. Газит әле дә даими рәвештә атнага өч тапкыр чыгып килә. Газит тиражының да, бернинди бүләкләүләр оештырмастан, кимегәне юк, халык теләп алдыра. Юкса, инде күпчелек редакцияләр (районныкыларны әйтәм) атнага ике сан чыгару белән чикләнәләр. Әле алай да газит мәйданы тулы көченә файдаланылмый.

Моннан шундый нәтиҗә ясарга кала: көндәлек матбугатның тотрыклы тиражын тәэмин итү өчен аның бай эчтәлекле, кешеләрне мавыктыра торган булып чыгуына ирешергә кирәк. Бөтенесен кыйммәтчелеккә генә кайтарып калдырырга ярамый.

Кыйммәтчелек дигәннән, әле анысын да бөтенләй исәптән сызып ташлап булмый — заманы шундыйрак. Халыкның тормыш-көнкүреш хәле әле һаман рәтләнүдән ерак тора. 1996 елда да ә[...] нәчеләребезнең азмы-күпме иш[...] юенә өмет бик кечкенә һәм алар[...]ның тагын да кимү ихтималы зур. Уйлап карагыз әле: менә газит-журналларга язылу кампаниясе башланганнан соң кыска гына вакыт эчендә бензинга, ип[...]гә, поезд билетларына бәяләр кү[...]тәрелде, телефон тоткан өчен, телефоннан шәһәр эчендә һәм шәһәрара сөйләшүләр өчен түләү тарифлары артты. Инде моннан со[...] башка нәрсәләргә бәяләр күтәре[...]лмәс дип кем әйтер? Кайда гар[...]тия? Кыскасы, киләсе ел өчен [га]зит-журналларга яздыру җиңел[...]дән булмаячак. Инде бу юлы д[а] журналистларыбыз кемнәрде[...]дер «бүләк» гозерләп әрсезлән[...]ләр микәнни?

Соңгы вакытта шәһәрләрдә [...]ргәндә шундый күңелсез нәрсә к[...]згә ташланды. Күп фатирлы йор[т]ларның аскы катлары[...] газит-журналлар һәм хатлар ө[...] куелган калай тартмалар рәх[...]сез рәвештә ватылып бет[...] исәннәреннән дә газит-журна[л]рны күрәләтә урлыйлар [...]. Анысы инде матбугатка язылу [...]леннән килмәгәннәр куль[...] Әнә шул сәбәпле бик күпләр ин[...] газит-журналларга язылмый[...] аларны башлыча киоскларда [...]тып ала башлаганнар. Бу очра[к] инде кеше теге яки бу басма[...] даими укучысы булып калмы[...] төрлесеннән сайлый башла[...] үзенә кызыклырак тоелга[...] алачак. Шулай хәерлерәк тә [...]нысы инде. Үз чиратында [...] зит-журналлар арасындагы к[...]куренцияне көчәйтәчәк. Ә ко[н]ренциядә өстенлек алу өч[ен] продукциябезнең эчтәлеген, [сый]фатын беренче урынга куяр[га т]еш булабыз. Өстенлекне «бү[...]ләү»ләр белән генә алып бу[л]ячак.

Балтач райо[...]

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар
5 6 7 1 2 3 4

Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

Казан Кремле ансамблен саклау, үстерү һәм файдалану концепциясе турында

1. Татарстан Республикасы Президентының 1994 ел, 22 гыйнварында һәм Русия Федерациясе Президентының 1994 ел, 9 августында чыгарылган Указлары нигезендә эшләнгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге тарафыннан тәкъдим ителгән «Казан Кремле ансамблен саклау, торгызу һәм файдалану фәнни концепциясенең төп юнәлешләре»н хупларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Архитекторлар берлеге һәм «Татинвестгражданпроект» фирмасының Артиллерия утары, Губернатор сарае, Благовещение соборындагы һәйкәлләр комплексында беренче чираттагы реставрация һәм торгызу эшләрен башкару кирәклеге хакындагы тәкъдимен кабул итәргә.

3. Моңа бәйле рәвештә Раштуа бәйрәменә (1996 елның 7 гыйнвары) республикакүләм әһәмияткә ия булган архитектура һәйкәлен — Благовешение соборы бинасын реставрацияләү һәи музейлаштыру өчен бушатуны һәм «Казан Кремле» Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы карамагына тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Тарихи мирасның буыннан-буынга күчүен саклау максатында Кол Шәриф мәчете бинасын әүвәлге хәлендә торгызырга һәм киләчәктә анда музей ачуны карарга. Мәчет бинасы корылачак урынга нигез ташлары салуны 1996 елның 21 февралендә — «Ураза бәйрәме» көнендә гамәлгә ашырырга.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Архитекторлар берлегенә, «Казан Кремле» Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгына, фикер алышуга киң җәмәгатьчелекне тартып, мәчетне торгызу буенча республика конкурсы үткәрергә.

5. Благовещение соборы һәм Кол Шәриф мәчете биналарын тантаналы дини чаралар уздыру өчен файдаланырга мөмкин дип исәпләргә.

Благовещение соборын һәм Кол Шәриф мәчетен күрсәтелгән чараларны уздыру өчен бирү тәртибе һәм шартлары «Казан Кремле» Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы белән килешеп билгеләнә.

6. Благовещение соборын реставрацияләүгә һәм Кол Шәриф мәчетен торгызуга үз ихтыярлары белән иганә биргән юридик һәм физик затларның истәлеген мәңгеләштерү өчен истәлек китаплары ачарга һәм мемориаль такталар куярга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

комплекслы геологик, археологик, тарихи-архитектура, шәһәр төзелеше һәм инженер-техник тикшеренүләр нигезендә «Казан Кремле» Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгын комплекслы үстерү Программасын эшләргә һәм расларга;

ирекле рәвештә бирелгән иганәләрне, юридик һәм физик затлардан, чит илләрдән, җәмәгать һәм дини оешмалардан кергән акчаларны җыюны тәртипкә салу максатында Благовещение соборын реставрацияләү һәм Кол Шәриф мәчетен кору өчен хәйрия фондлары төзергә;

истәлек китаплары һәм мемориаль такталар турында нигезләмәләр һәм әлеге Указның үтәлүен тәэмин итә торган бүтән төрле норматив актлар эшләргә һәм расларга.

Татарстан Республикасы Президенты **М.Ш.ШӘЙМИЕВ.**

Казан, Кремль.
1995 ел, 13 ноябрь.

Шәхси күргәзмә дәшә

Бүген 15 сәгатьтә «Казан» милли мәдәният үзәге тамашачыларны Мәскәүдә яшәүче татар рәссамы Эдуард Шаһиевнең шәхси күргәзмәсенә чакыра. Э.Шаһиев — китап бизәү һәм графика остасы. Аның эшләре элекке СССР күләмендәге һәм чит илләрдәге күп кенә күргәзмәләрдә куелды.

Рәссам 1944 елда Омски шәһәрендә туган. 1965 елда Свердловски сәнгать училищесын тәмамлаган, югары ...мәли сәнгать училищесында белем алган.

Эдуард Шаһиевнең иҗатына, ачы юмор хисе белән бәрәттән, эчкерсезлек хас.

Бүген, 17 ноябрьдә, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры «Йолдызлы яңгыр» исемле ике пәрдәле концерт-тамашаның премьерасын күрсәтә. Тамашаның сценарий авторы — Шамил Фәрхетдин. Режиссеры һәм рәссамы — Рәшит ...аһидуллин. Композиторы — Чыңгыз Абызов. Биюләрне Марат Гыймдетдинов куйган. Пластика режиссеры — Рөстәм Фәткуллин.

Башлана 19 сәгатьтә.

● Тамашадан бу күренешне фотохәбәрчебез **Ә.ШӘФИГУЛЛИН** *репетиция вакытында ...шереп алды: Төмлә Тел Мөхәндис — Илгизәр Хәсәнов, Таһирзадә Нурлыйөз — Люция ...лләмова, Велор Вәлимәрдән — Нуретдин Нәҗмиев, конферансье — Шамил Фәрхетдин.*

Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы белән бүләкләү турында

Татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен, язучы **МИҢНУЛЛИН Туфан Абдулла улын Татарстан Республикасының Мактау Грамотасы** белән бүләкләргә

Татарстан Республикасы Президенты **М.Ш.ШӘЙМИЕВ.**

Казан, Кремль
1995 ел, 3 ноябрь

Туфансыз театр, театрсыз Туфан юк

11 ноябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында танылган драматург Туфан Миңнуллинның юбилей кичәсе булып узды.

Әлеге тантана Туфан Миңнуллин әсәрләре буенча куелган спектакльләр декадасының бер йомгагы иде. Хәер, бу кичә зур, олы бер иҗатның, дистәләрчә еллар дәвамында театр күгендә йолдыз булып балкучы шәхеснең зур бәйрәменә әверелде. «Ай булмаса, йолдыз бар» — драматург үзенең бер әсәренә әнә шундый исем куйган, аңа тормышның халыкчан фәлсәфәсен, яшәү мәгънәсе турында, яхшылык һәм яманлык хакында уйлануларын салган иде. Һәм аның бу кичәсендә күңелгә шундый уй да килеп алды: Ай булмаса, йолдыз бар... Ә менә Туфан Миңнуллин иҗаты булмаса, театрыбыз ниндирәк булыр иде икән?

Бәйрәм кичәсендә алтмышын тутырган ир-егетне Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев котлады, аңа иҗат уңышлары, озын гомер теләп, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы дипломын һәм истәлекле бүләк — Президент сәгатен тапшырды.

Юбилярны Казан шәһәре хакимияте башлыгы К.Исхаков, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р.Мөхәммәдиев, драматургның туган ягы — Кама Тамагыннан — район хакимияте башлыгы М.Шәмсетдинов, якын каләмдәшләре Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Ш.Галиев, И.Юзеев, Р.Вәлиев, күпсанлы сәнгать әһелләре җылы котлады.

Кичәдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев, Премьер-министр Ф.Мөхәммәтшин катнашты.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Республикасы Президенты фәрманы белән мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен ***«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»*** *дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:*

Афанасьев *Лев Николаевич — «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе телеоператор-куючысы;*

Фаил Талип улы ***Мөхәммәтов*** *— «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең информацион программалар баш редакциясе баш мөхәррире;*

Рафис Шәриф улы ***ИСМӘГЫЙЛЕВ*** *— Минзәлә район типографиясе директоры;*

МАКАРОВА *Светлана Николаевна — К.Якуб исемендәге полиграфия комбинатының җитештерү идарәчесе.*

Фәнни эшчәнлектәге казанышлары өчен ***«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»*** *дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:*

Илдус Барый улы ***ХӘЙБУЛЛИН*** *— Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе һәм әгъза-мөхбире, профессор.*

Татарстан Республикасы Президенты фәрманы белән уңышлы артистлык эшчәнлеге өчен «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең информацион программалар баш редакциясе программаларын алып баручы Рәисә Ивановна ***Гәрәева «Татарстан Республикасының атказанган артисты»*** *дигән мактаулы исемгә лаек булды.*

Халык мәгарифе системасында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Чистай район һәм шәһәр хакимиятенең кала мәгариф бүлеге мөдире ***ПОТАПКОВ*** *Александр Александрович* ***Татарстан Республикасының Мактау грамотасы*** *белән бүләкләнде.*

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Берләшкән Гарәп Әмирлегенең Дубаи шәһәрендә ачылган авиасалонда Казан вертолет заводы «МИ-17МД» вертолетын күрсәтте.

Чаллыда моңарчы «Шәһри Чаллы» гәзитенең кушымтасы буларак чыгып килгән «Көмеш кыңгырау» яңа елдан мөстәкыйль балалар гәзите буларак нәшер ителә башлаячак.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Милли китапханә директоры, шагыйрь Рәзил Вәлиев Кембридж Халыкара биография үзәге дипломы белән бүләкләнде.

Баулыда республикабызның көньяк-көнчыгыш төбәгендә яшәүче һәвәскәрләрнең «Яшь талантлар-95» бәйгесе булып үтте.

Казан музыка кораллары фабрикасы кубызларның тәҗрибә партиясен эшләп чыгарды.

Башкалада булып үткән Республика партиясе пленумында Рүзәл Йосыпов партия рәисе вазифаларыннан азат ителеп, аның урынына «Шәһри Казан» гәзитә мөхәррире Хәлим Гайнуллин сайланды.

Казанда беренче тапкыр 600 машинага исәпләнгән өч катлы автогараж файдалануга тапшырылды.

Сәхифәләрдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды. 1 нче биттә М.Козловский фотосы.

Әзһәр МӨХӘММӘДИЕВ,
профессор:

«Хакимият белгечләр сүзенә дә колак салсын иде»

— **Әзһәр әфәнде, «Мәдәни җомга» газетенең 7 нче санында чыккан «Мәскәү Кремлендә мәчет булырмы?» дигән мәкаләдә Татарстан Архитекторлар берлеге рәисе Фәридә Зәбирова болай дигән иде:**

«...урыслар Благовещение соборында Пасха, Раштуа бәйрәмнәрен үткәрәчәк.

Благовещение соборы сәнгать музееның иконография бүлеге буларак та файдаланылачак».

Казан Кремлендә археологик тикшеренүләр алып баручы буларак, Сез бу фикергә ничек карыйсыз?

— Мин 1970 нче елларда «Казан ханлыгының историографиясе» дигән күләмле мәкалә язган идем. Аны басмадылар. Әлеге мәкаләне язганда миңа Казан ханлыгы чорына караган күп кенә чыганаклардан файдаланырга туры килде. «Патша китабы» дигән елъязма китабы бар. Явыз Иванның Казанны алуы турында анда бик тәфсилләп язып барылган. Шул китапта мондый юллар бар: «И видиша православнии людие животворящи крест, и царя благочестивого в запустенной мерзости (мәчеттә —·Ә.М.) казанской. Преже на том дворе нечестивые царие водворялись...» (Бу урында элек Казан ханнары тәхеткә утыртыла торган булган. — Ә.М.). Шунда ук Хан мәчетенең чиркәүгә әйләндерелүе турында болай дип аңлатыла: «Того же месяца шестого; свещал (освятил) государь церковь соборную Благовещение». Ягъни Казанны алуның дүртенче көнендә инде собор хәзерге урынында басып торган. Димәк, ул Хан мәчете булган.

— Димәк, шул Хан мәчетендә носарилар бәйрәмнәрен үткәрәчәк булып чыга инде алайса?..

— Моның чынлап Хан мәчете булганлыгы башка фактлар белән дә дәлилләнә. Беренчедән, чиркәүләрнең диварларыннан гадәттә чаң кага торган манаралары (каланчалары) күтәрелә. Ә соборда ул юк. XYI гасырда («Писцовый кенәгә»дә әйтелгән) аның чаң кага торган каланчасы вакытлыча агачтан, читтә төзелгән булган. Икенчедән, собор үзе юнәлеше белән Мәккәгә караган, бу исә христиан гыйбадәтханәләренә хас түгел. Өченчедән, христиан гыйбадәтханәләренең төньягында өч абсиды, ө эчке якта алтаре була. Соборның исә дүрт абсиды бар һәм аның өч абсидтан башка почмактагы каланчалары, күрәсең, борынгы мәчет манаралары булган. Һәм, чынлап та, археологик тикшеренүләр шуны күрсәтә: бу почмактагы каланчалар борынгырак чорга карый. Абсидлар исә манаралар белән бәйләнешсез рәвештә соңыннан гына диварга ябыштырып төзелгән. Эчке ягының кыйблага караган башында михрабның бер стенасы табылды. Михраб, белгәнегезчә, сәхнә рәвешендәрәк эшләнгән, вәгазь укый торган урын. Кызганыч, аның башка өлешләре җимерелгән. Шул ук вакытта Мәккә уңаендагы ягына урнашкан диварның фундаменты астына, Болгар архитектурасына хас рәвештә, казыклар кагылган. Михраб стенасы да шушы стена белән бер тирәнлектә төзелгән һәм аның да астына казыклар кагылган. Өстәп шуны да әйтергә кирәк: әле XIX йездә үк соборның идәне астында (аскы катта идәне кирпечтән) берничә борынгы кабер табылган. Каберләр кирпечтән төзелгән булган. Аны башта Казан епископларының каберләре дип уйлаганнар. Ләкин элекке чорларда христианнарны чиркәү эченә күмү гадәте булмаган. Һәм шунысы гаҗәп, ул каберләр ташландык хәлдә булып, чүп-чар белән тутырылган. Әгәр чыннан да христиан каберлеге булса, аларны шулай чүп-чар белән тутырырлар иде микән? Ә миңа үз вакытында Бөлҗәмин шәһәрлегендә (Волгоградтан Идел буйлап 40 чакрым өстәрәк) 36 мәрмәр колонналы мәчет калдыкларын казырга туры килгән иде. Һәм аның эчендә дә кирпечтән эшләнгән кабер чокырлары бар иде.

Собор эчендә безгә менә шушыларны да өйрәнергә мөмкинлек бирелсә, тарихи хакыйкатьне торгызырга да форсат туар иде. Благовещение соборы эшли торган чиркәүгә әйләндерелсә, безне анда бөтенләй кертмәячәкләр. Әнә «Спутник» кинотеатры янындагы Иванов чиркәвен христианнарга биргәннәр иде, безне хәзер анда якын да җибәрмиләр. Ә бу Благовещение соборы тирәсен казып, фәнни яктан ныклап өйрәнеп бетерәсе бар әле. Шул эш тоткарланмасын иде. Ә соңыннан Казан Кремлендә табылган материалларны бергә туплап (ә алар бик күп), соборны музей итү муафыйк булыр иде. Туристлар өчен дә, татар халкы өчен дә Казан ханлыгы турында бай музей булыр иде ул. Аннары минем шуны да әйтәсем килә: тарихи карарлар кабул иткәндә хөкүмәт кешеләре дә турыдан-туры шул эш белән шөгыльләнүче белгечләр сүзенә колак салсын иде.

Галим белән **Саимә ИБРАҺИМОВА** сөйләште.

КАРАШ

Фирдәвес Вәли кызы САЛИХОВА Казан дәүләт университетының география факультетын тәмамлый. Аннары СССР Фәннәр академиясе каршындагы геология институтында аспирантурада укый. «Казанның географиясе һәм геология инженериясе» дигән темага диссертация яклый. Фирдәвес ханым — Казанның тарихы һәм ландшафт архитектурасы, архитектур һәм табигый һәйкәлләр, Казан топонимикасы буенча дәрәҗәле белгеч. Казан ландшафтында җир убу, иңү законнарын исәә алып, ул Сөембикә манарасының нигезен ныгыту өчен тикшеренү эшләре алып бара һәм аның теориясен эшли. Фирдәвес ханым Алжирда студентларга ике ел французча, Әфганстанда өч ел фарсыча-урысча картография фәнен укыта. Француз, немец, фарсы телләрен белә. Бүген ул Казан педагогия университетының география факультетында укыта. Бу сәхифәдә укучыларга тәкъдим ителә торган язмасында исә ул борынгы мәчетләрнең төзелү вакытын билгеләү өчен эшләнгән өр-яңа гыйльми карашны алга сөрә.

Фирдәвес САЛИХОВА

Ай яктысы...

(Казан ханлыгы

Бу мәкаләне язарга мине Саимә Ибраһимованың «Мәдәни җомга»ның 7 нче санында чыккан «Мәскәү Кремлендә мәчет булырмы?» дигән язмасы этәрде.

«Күптән түгел матбугатта, Свияжскида чиркәүләрне эшләтә башлаячаклар, дигән бер хәбәр күренеп алган иде. Моңа каршы Татар иҗтимагый үзәге, бу бит «татар халкын колониялләштерү һәйкәлләрен яңарту», дип язып чыкты. Кремльдәге чиркәүнең— Благовещение соборын — дин тотучыларга тапшыру нияте дә халыкның ачуын кабартты. Кремльнең бавырында урнашкан шушы чиркәүгә носарилар чыннан да гыйбадәт кылырга, чукынырга йөри башласа, нәрсә була инде бу?!»

Шундый сүзләр белән башланган әлеге язма бик актуаль мәсьәләне күтәрә. Шуңа күрә мин Казандагы кайбер борынгы архитектур һәйкәлләрнең тарихын халыкка ирештерүне изге бурычым дип саныйм. Ә мәкалә башындагы «Мәскәү Кремлендә мәчет булырмы?» дигән сорауга, алга китеп булса да, «юк» дип җавап бирәм. Иван IY Колшәриф мәчетенең күчермәсен Кызыл мәйданга илтеп салдыра, һәм ул Василий Блаженный соборы булып китә. 440 елдан артык вакыт узгач бирәдә мөселманнар түгел, 1987 елның 15 октябрендә, Казанда беренче тапкыр Хәтер көне уздырылганда, христианнар анда гыйбадәт кыла башлады.

Бу мәкаләне мин шулай ук архитекторлар арасында озак еллар буена барган бәхәсне дә исәпкә алып яздым.

Галәм белән турыдан-туры элемтә

Бүгенге көнгә кадәр төрле храм концессияләрендә архитектур формаларның мәгънәсе ачылмаган. Ә бит бу формалар, һичшиксез, тегә яки бу эпоханың дөньяга карашын, дөньяда мәгълүм булган диннәрнең берсен кабул иткән чордагы халыкларның рухани, мәдәни традицияләрен чагылдыра. Төрле вакытта, төрле илләрдә ислам традицияләрендә салынган гыйбадәтханәләрдә уртаклыклар күп, әмма аерымлыклар да шактый. Алар ислам динен кабул иткәнгә кадәр шушы җирдә яшәгән халыкларның рухи формалашуын чагылдыра: дөньяны аңлауда яңа позицияләрен белдерү өчен, бу халыклар гаҗәеп архитектур гармония тудырырга ирешкәннәр.

Борынгы Көнчыгыш цивилизацияләрендә, иң әүвәл Шумер мәдәниятләре чорында, Галәм белән турыдан-туры элемтә тоту, аңлашу доктринасы барлыкка килә: анда вакыт исәбе астраль культ казанышы булып тора. Әмма руханилар йолдызларга карап табигатьне өйрәнү, астрономик күзәтүләр ясап календарь төзү, фараз итүләр белән генә шөгыльләнми. Алар Ай, Кояшка карап көн белән төн тигезлеге, Кояш торгынлыгы көннәрендә яңа елны исәпләп чыгарганда культ корылмаларының кая таба каратып салынуын да өйрәнәләр. Кыскасы, бу корылмалар Галәм ритмында яши, җәмгыятьнең дә тормыш-көнкүреше шуңа җайлаша. Моңа бәйле рәвештә күләмле архитектура композицияләрендә — храмнарда яисә очлары күккә ашкан манараларда гыйбадәт кылучыларның Галәм белән бәйләнешкә керү, берләшү идеясе чагыла.

Шуңа күрә күп диннәрнең нигезендә кешеләрнең уйларын Галәм белән тоташтыручы астраль культ аерым урын алып тора. Борынгы кеше Галәм белән тыгыз элемтәдә булган һәм аның ритмында яшәгән. Кешеләр бу төңгәллекне Кояш, Ай чыгу һәм баю, көн белән төн алмашыну, яз-көз кебек табигать фасыллары үзгәрешендә күргәннәр. Алай гына да түгел, мондый төңгәллек бөтен кешелек җәмгыятенә хас булырга тиеш дип исәпләгәннәр.

Астрономия һәм астрология үсешендә Шумер һәм Бабил дәүләтләре аеруча зур роль уйнаган. Шумерларның тормышы турында Н.Крамерның «История начинается в Шумере» дигән китабында җентекле язылган. Археологлар тапкан Ашшурбанинал китапханәсе — кызыл балчыкка чөй язуы белән язылган җәдвәлләр — (б.э.к 668-626 еллар), Ниппурда Энлиль храмында табылган язуларны уку биш мең ел элекке мәдәниятне аңларга ярдәм итте. Эриду, Ур, Урук, Лагаш, Ниппур, Ларса шәһәрләре икътисад һәм сәүдә юлы белән ул чагында ук Мисыр һәм хәтта Мохенҗо-Даро (Пакистан) мәдәниятләренә йогынты ясаган. Н.Крамер шумер мәдәниятенең арадаш буыннар аркылы борынгы яһүд, грек халыкларына, төркиләргә, хәтта Көнбатыш һәм Көнчыгыш Аурупага йогынтысын (б.э.к. III меңьеллык) дәлилләп күрсәтә. Шумер чорында Месопотамия дине (б.э.к. III меңьеллык) — Төңрегә, Анута, Энлильгә, Эага (Ия), Торага табыну ул. Шумерлар табигать көчләренә, шуларның иң могтәбәрене — күк йөзе, Төңрегә табынганнар. Шумерларның һәм соңрак башка халыкларның Галәм белән шундый бәгланышы культ корылмаларын төзегәндә гәүдәләнеш таба: аларның манаралары күккә ашардай биек итеп эшләнә.

М.Булатов архитектура-астрономия ысулы белән Көнчыгыш, борынгы Греция, Рим, Бактрия, Парфия, Согыд, Хорезм архитектураларын өйрәнеп, храмнарның Кояш чыгу һәм баюга, җәйге һәм кышкы Кояш торгынлыгына ориентлашуын ачыклый. («Геомет

рическая гармонизация в архитектуре Средней Азии» М 1988)

Шумерның Уруктагы иң борынгы Ак храмы кышкы Кояш торгынлыгында, ягъни 22 декабрьдә Кояш чыгышына карап тора, һәм яңа ел исәбе шул көннән башлана М Булатов мәгълүматларына караганда археологлар тапкан 36 борынгы храмның 14е кышкы Кояш торгынлыгында көнчыгышка каратып салынган Алар арасында Троя храмы (б э к XYI XII гг), Бактриядәге Түгәрәк храм (б э к XYII XY гг) Милет урамнары һәм храмнары Херсонес урамнары (б э к III г) Согдианда «Сак календаре» (б э к I г) Әфганстанда Ай Ханым гыйбадәтханәсе (б э к I г) һ б бар

Урта Азиягә гарәпләр килү белән җирле культлар исламга урын бирә әмма кысрыкламый. киресенчә төрле ышану табынулар җай гына яңа дингә яраклашып китә Ярым ай хәтта (төрки кабиләләр Айга табына) ислам диненең символикасына әверелә Үткәннәргә экскурс борынгы Шумерның астраль культы булган күк — Тәңрегә табынуның (соңрак Тәңре Алла белән тиңләштерелә) төрки халыкларның да астраль культ белән бәйләнешен күрсәтә Тәңрегә табына икән бу аның тормышының бөтен-иминлегенә ышаныч бирә

церковь»ның көнчыгыш көнбатышка караган диварлары юнәлеше буенча беренче кояш нурларына туры килә Шулай итеп борынгы капка мәчет исемнәреннән Кояш чыгышы Кояш батышы юнәлеше белән тәңгәл килүе исбатлана бу исә үз чиратында борынгы төркиләрнең XYIII гасырга кадәр диярлек төзелеш традицияләре үзгәрешсез сакланганын дәлилли Димәк мәчетләр XYIII гасырдан гына Мәккә тарафына — көньякка каратып салына башлый Әмма монда да кышкы Кояш торгынлыгында ярым ай элеккечә (XX гасыр башына кадәр) Кояш чыгышына каратып салына

Су төбендә асылташ, су тулкытсаң, чыгадыр

Казан университетының сирәк китаплар бүлегендә 1768 елгы план саклаган Анда Сөембикә манарасы белән берретттән «Дворцовая церковь» как « церковь обращенная из мечети находящаяся ныне в ветхости» дип билгеләнгән Казанның 1560 елгы писцовый кенәгәсе Благовещение соборы каршындагы мәчетнең хәзер артиллерия һәм хәрби цехгаузга әйләндерелүен таныклый Бу мәгълүматлар Н Загоскинга «речь идет в данном случае ...

пәләргә бик үк төгәл җавап бирмәсә дә чыннан да манараның монастырьдан чыгу юлы булып хезмәт итүен раслый Ниһаять «Апофеоз взятия Казани» картинасындагы (бу рәсем икона Третьяков галереясендә саклана алгы пландагы манараның Сөембикә манарасы яисә Хан мәчете икәнлеге бәхәссез Аның артында Кремль чиркәве ягъни элекке Нур Али мәчете күренә Монда берниндu шик юк Бу бөек манара турында А Курбский һәм XY гасырда Казан тарихын язган билгесез автор язып калдырган Дөрес кайбер археологлар һәм архитекторлар 1970 нче елларда манара астында ак нигез ташлары табылды дигән булып алда әйтелгән культ корылмаларының Казан чорына караганлыгын кире кагалар Әмма манара периметры буенча казылган скважиналардан андый материаллар чыкмады Кайбер галимнәр Сөембикә манарасы XYIII гасырда гына төзелгән дип расларга маташалар әмма сүзләрен исбатларга берниндu дәлилләре юк Кызганыч ки алар әле Сөембикә манарасының күләмен үлчәү турындагы тагын бер мә-

риларның бу корылманы «нечестивый» «басурманский» дип атап йөртүләрен яза Собор интерьерында ап ак фонда тамбур белән чиккәндәй чәчәк рәсемнәре бар Андый рәсемнәрне намазлыкларда гына күрергә була Мин Мәскәүгә барып соборны җентекләп тикшереп чыктым Аның директоры бик теләп соборның барлык урыннарын күрсәтте Диварларына хәтта иконалар да ясалмаган Соборның баш куполында (манарасында хәтта азаң әйтә торган балконы да бар Хәзер анда реставрация бара һәм 440 елдан соң беренче тапкыр гыйбадәт кылу башланды

Колшәриф мәчетенең матурлыгын шул чорлар шагыйре Мөхәммәдьяр сурәтли Бу сурәтнамә Колшәриф мәчете белән Василий Блаженный соборының нәкъ бертөсле икәнлеген раслый Н Брунов («Материалы по охране ремонту и реставрации памятников ТССР» вып 2 К 1928) » и другой проблемой связанной с Благовещенским собором г Казани является вопрос о влиянии мусульманского зодчества на древнерусское .. в XY веке оно было особенно сильным Благове-

...галәмгә, шәм яктысы — шәмдәлгә

...чорындагы Кремльнең архитектур истәлекләре)

Җыен йолдыз җыелса да, яктылыгы айда юк

Цивилизация таңында барлыкка килгән бу концепция ислам динен кабул иткәч тә гәүдәләнеш таба М Булатов фикеренчә утрак тормышта яшәүче халыкларның культ корылмалары кышкы Кояш торгынлыгында көнчыгышка караган Гарәп фарсы һәм төрки телләрдә язылган трактатларда астрологлар андый юнәлеш буенча төзелгән корылмалар Галәм белән гармониягә тәгаенләнгән диләр Күргәнебезчә борынгы гореф-гадәтләрне хәтта ислам дине кануннары да бөтенләй юкка чыгара алмаган Бер үк вакытта төрле географик эклималарда храмнар ориентлашсын өчен җәдвәлләр төзелгән Храмнарның шушы концепция нигезендә ориентлашу принцибын болгар цивилизациясе дә кулланган Шундый храм-мәчетләргә һәм көнчыгышка караган капкаларга «Нур Али» исемен биргәннәр Бу исем аларның изгелеген һәм астраль мәгънәсен күрсәткән Казандагы Нур Али мәчете һәм капкасы да шул функцияләрне үтәгән

М Булатов тикшеренүләре Казан Кремлендә мәчетләрнең төзелү вакытларын билгеләргә шактый ярдәм итте Казан шәһәренең 1560 елгы писцовый кенәгәсе материаллары Нур Али мәчете һәм капкасы борынгы Казанда да астраль мәгънәгә ия булган дияргә нигез калдыралар Борынгы Кремль тупрагында писцовый кенәгәдә күрсәтелгән шул принципта төзелгән мәчет Болгар-Казан чорына караган биналар сакланып калганмы дигән сорау туа Сөембикә манарасын һәм «Дворцовая церковь» — (Нур Али мәчетен хәзерге ашханә бинасын) тикшереп карагач шул ачыкланды Сөембикә манарасы һәм «Дворцовая

госкинга «речь идет в данном случае о здании нынешней Дворцовой церкви бывшем когда-то мусульманской мечетью затем реставрированной в настоящем виде» дип расларга урын калдыра «Итак современное нам здание церкви Кремлевского дворца мы имеем полное основание отнести к архитектурным памятникам татарской Казани существуют весьма веские доказательства в пользу того что это именно та Муралеева мизгить то есть мечеть» (Н Загоскин «Спутник по Казани» К 1895 99 б)

Аннары Витзен рәсемендә (XYII гасырның беренче чиреге) Сөембикә манарасы урынында Дворец чиркәве дип аталган храм манарасы аермачык күренеп тора Кайбер галимнәр аны Благовещение соборының чиркәү манарасы белән тиңли Әмма бу собор хан сараеннан шактый ерак тора һәм аны беркайчан да «дворцовая церковь» димәгәннәр ул вакытта аның манарасы да булмаган Витзен рәсемендә Благовещение соборы пландагыча үз урынында тора ул чагында аның чаң манарасы булмый әле Писцовый кенәгәдә «у монастырского двора Илантовского мизгить что была Муралеева» диелә Витзен рәсемендә ул митрополит йорты белән янәшәдәге чиркәү итеп күрсәтелгән 1768 елгы документта (Борынгы актлар архивы Мәскәү) монастырьдан чыгу юлы — вазифасы билгесез булган биек азиат манарасы аша диелгән Бу фаразны XYII гасыр урталарында ясалган Кремль планы да раслый Ул Г Алферованың XYI-XYII гасырларда Русиядә шәһәрләр төзү тарихы турындагы китабында шулай ук «Знание — сила» журналының 1981 елгы 3 нче санында күрсәтелә План геодезик таһим документ барлыгын белми торгандыр Шул документта әйтелгәнчә Казанда воевода булып торган Лопухинны гадәти булмаган манара шаккатыра Аның кызы — сарайдан куылган Петр I нең хатыны — Сөембикә фаҗигасенә дучар була һәм ул кызы истәлегенә Подкопаеводагы вотчинасында Сөембикә манарасының күчермәсен төзетә (Казан университетының сирәк китаплар бүлеге Сөембикә манарасын өйрәнү буенча М Синявер материаллары 1943 ел) Шунда ук Мәскәү Кремлендәге шуңа охшаш Боровицкий манарасының соңрак төзелүе хәбәр ителә Димәк Сөембикә манарасы һәм Нур Али мәчете XYII гасыр азагында XYIII гасыр башында төзелгән дигән имеш-мимешләр — нигезсез дәлилсез сүзләр Барлык бәхәсләргә нокта куючы соңгы документ 1690 ел белән билгеләнә Витзенның рәсеме 1630 нчы елларга туры килә Благовещение соборының ак таштан салынган ике катлы дүрткеленә игътибар итик ул Сөембикә манарасының юнәлешенә туры килә Бу — Колшәриф мәчетенең төп өлеше дияргә тулы нигез бирә чөнки олы манараларның аскы өлешендә соборның төньяк көнбатыш һәм көньяк көнчыгыш почмакларында контрофорс булып төпләре сакланган «Иоанн повелел всех казанских татар мольбища мизгити или мечети разорить до основания а на их месте строить церкви православия и сам он первый среди иноверческого города на месте кремлевской мечети заложил соборный храм во имя Благовещения Пресвятые Богородицы» ЦПА ФТФ 10 оh2 Д.221 Л 56-57 «Церковно-историческая жизнь города Казани ч 1 К 1904)

Ташкын китте, юшкын калды

Колшәриф мәчетенең салынган урыны аның архитектурасы кабатланмас матурлыгы Иван Грозныйны шулкадәр сокландырган күрәсең, тиздән ул Мәскәүдәге Кызыл мәйданга аның күчермәсен салдырырга куша Ә Казандагысының алты манарасын җимереп тиз генә чиркәүгә әйләндерәләр Колшәриф мәчетенең күчермәсен — Василий Блаженный соборын — Казанда аны җимереп остарган төзүчеләр — Барма һәм Постник Яковлевлар Мәскәүдә сала Колшәриф мәчете нигезендә Благовещение соборы булуы хакында Червонная «Искусство Татарстана» дигән китабында язып чыкты

Лев Толстой «Война и мир» романында Василий Блаженный соборының мәчет күчермәсе икәнлеген һәм анда гыйбадәтләр үтәлмәвен чөнки нәса-

щенский собор имеет вместо парусов главного купола тромпы расчлененные на два сводика с вертикальной стенкой между ними Заимствование из местных мусульманских памятников не подлежит в данном случае никакому сомнению» — дип яза Моннан күренгәнчә Казан Кремлендәге мәчетләрне чиркәү итеп үзгәрткәндә аларны тулысынча җимерүнең мәгънәсе булмаган

Башка чыганаклар мондый тугыз манаралы мәчетнең Һиндстанда Хазанабад шәһәрендә XYII гасырда салынганлыгын бәян итә Миңа калса бу шәһәрнең исеме — Казанабад. һәм Казанны урыслар яулап алганнан соң, болгар-татарлар шунда күчеп китеп үзләренең туган илләрен сагынып гүзәл Колшәриф мәчетенең күчермәсен эшләгәннәр

Ниһаять 1970 нче елларда археологик казулар вакытында табылган таш манара борынгы Казан архитектурасына дүртенче һәйкәл булып тора Ул сәламәтлек саклау министрлыгы бинасыннан төньяк-көнчыгыштарак габылды әмма аны 1980 нче елларда яңадан күмеп асфальтлап куйдылар Бу манара Витзен рәсемендә сакланып калган һәм ул «Җәгъфәр тарихы»нда язылган чирмеш манарасы булырга тиеш Ул манараның хан сарае белән Дмитриев капкасының өске коймасын тоташтыру вазифасын башкаруы Казан Кремле планында да сакланып калган

Бүгенгә көндә борынгы Казан чорыннан дүрт архитектур истәлек сакланып калган Гасырлар аларның исемен йөзен үзгәртсә дә милли балкышларын югалтмаган менә ул корылмалар

Сөембикә манарасы

Хан мәчете яисә Нур Али мәчете

— Колшәриф мәчетенең бер өлеше (Благовещение соборы)

Борынгы манара (җир астында өч метр тирәнлектә) Кремльдә сакланып калган өч чиркәү дә юнәлешләре буенча элекке мәчетләр өстендә утыра

Колшәриф мәчете хәзерге заманда шушындый катлаулы тарихи процесслар белән бәйле булганлыктан, һичшиксез, музейга әверелергә тиеш Фәкать музейга! Мәчетнең эчен-тышын да мәчет рәвешенә китерергә кирәк

Дөньяда моңа аналоглар бар Истанбулдагы Айя-Суфия мәчете чиркәүдән мәчеткә әверелгән һәм хәзер ул музей булып тора Эчендә ике дин мәдәниятенең традицияләре күрсәтелгән Фәкать шул юл белән генә без Татарстанда яшәүче халыкларның тарихи бәйләнешләрен күрсәтә алабыз



«Останкино»да кыскарту бара

25 октябрьдә әлеге телекомпаниянең бетерү турындагы документка кул куелды Хәзер анда эшләгән 1789 кеше эштән бушатыла Килешү беләп эшләүчә 300гә якын телевизиончы эштән чыгарылган иде бу төркемгә тагын 300 штаттагы хезмәткәр кушылачак «Останкино» штатында торган 500 радио хезмәткәре шулай ук компаниянең идарә аппаратында эшләгән 224 кеше щул ук язмышка дучар Аларның бик азы гына үзенә эш таба алыр дип яза **«Комсомольская правда» (№203).**

Урыс тудырган, татар терелткән

Казанда 75 елдан соң «Неврологический вестник» («Неврология хәбәрләре») дигән журнал яңадан туды Аны моннан 100 ел элек академик В Бехтеров оештырган булган Бу юлы журналны терелтүче — татар галиме. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш невропатологы профессор Мәксум Фәсех улы Исмәгыйлев Бу — медицина өлкәсендә урысча-татарча-инглизчә чыгарган бердәнбер журнал Аның баш мөхәррире М Исмәгыйлев — Татарстан Республикасының узган елгы Дәүләт бүләге лауреаты атказанган фән эшлеклесе 150 фәнни хезмәт авторы

(«Казанские ведомости», 4.11.95).

Фахишәлек — гаилә авыруы

Фахишәләр каян килә? Матди мохтаҗлыктанмы? Элек шулай дип раслыйлар иде Табиб-сексопатолог тикшеренүләреннән күренгәнчә 106 фахишәнең 2се генә матди мохтаҗлыктан бу кәсепкә керешкән Ә башкалары бала чактан ук шундый хәлләргә күреп үскәнгә күрә әлеге «кәсеп»не сайлаганнар Моны «гаилә авыруы» дип саный табиб Күп кенә гаиләләрдә ирләр үз гаиләсендә канәгатьләнү таптмаганга «тәтәй»ләр рәтенә кителәр Бу да — гаилә авыруы

(«Труд», 2.11.95).

Миңнекәевләр 300 елга бер генә туа

Күптән түгел **«Вечерняя Казань»** гәзите экстрасенс «Планетаны яңарту» халыкара ассоциациясе вице-президенты Рафикъ Миңнекәев белән турыдан-туры сөйләшү оештырган иде Бу өңгәмәгә гәзиттә (№173) тулы бер сәхифә багышланган

— Кашпировский һәм Чумактан кайсы ягыгыз белән аерыласыз? — дигән сорауга ул

— Кеше буларак без бер төсле үк Ә дәвалаучы буларак аермаларыбыз байтак Мин күрәзәчә дә галәм белән элемтәм дә бар Аларда бу сыйфатлар юк Алар дәвалаучы белгечләр генә, — дип җавап бирә

Инде килеп Р Миңнекәев үзе кебек кеше тагын 300 елдан соң гына туачак ди

Читләр белән якынлык кылсагыз...

Ни булыр? «СПИД яки венерик авыру алырсыз» дигән җавап көтәсездер, мөгаен Юк аннан да куркынычрак — үлемгә үк китергән хәлләр дә була Бервакыт Куровлар өенә Катя исемле кыз килә дә хуҗабикәгә аның ире белән булган интим мөнәсәбәтләре турында сөйли Ул киткәч өйдә нинди җәнҗал купканын күз алдына китерәсездер Ир моны үзенә «яла ягу» дип аңлата һәм хатынына бу кызны үтерергә өзер булуын белдерә Хатыны аңа ярдәм итә әлеге кызны үзләренә кунакка чакыралар ашаталар аракы эчертәләр Аннан соң урамда йөреп керергә тәкъдим итәләр Урамда кыз үзенә куркыныч янавын сизенеп кычкырга маташа Куров куып тотып кызның бугазына пычак батыра

(«Вечерняя Казань», № 172).

Эшсезләр фиркасе «көчәя» бара

Хезмәт статистикасы начальнигы Т Горбачева исәпләвенчә. Русиядә хәзер эшсезләр саны 5,8 миллион, ягъни эшкә сәләтле гражданнарның 7 9 проценты тәшкил итә Аларның 2,1 проценты эш белән тәэмин итү службасында теркәлгән Моннан тыш 1,6 миллион кеше мәҗбүри ялда, аларның 45 процентына берни дә түләнми Ел азагында эшсезләрнең 6 миллионга җитүе көтелә.

(«Известия», № 210).

Депутатлыкка үтсәң килсә, кесәң калын булсын

«Российская газета» Дәүләт Думасына сайлауларда теге яки бу блок кандидатларын агитацияли торган язмаларны түләүлә бастырырга булган Әгәр язма бер сәхифә күләмендә булса. моның өчен 80 миллион сум.ярты сәхифәгә — 42 миллион өчтән беренә 34 миллион сум чамасы акча түләргә кирәк.

(«Российская газета», № 216).

Ельцин акчасына — чит илгә

Кем генә чит илгә барып белем алырга теләмәс икән! Тик моның өчен акча каян аласың? Әгәр дә 1996-97 уку елында чит илгә барып укырга теләүче студент һәм аспирантлар конкурстан үтсәләр аларга стипендияне Русия Федерациясе Президенты үзе түләячәк РФнең югары белем буенча дәүләт комитеты игълан иткән бу конкурстан узу өчен вузның гыйльми советы тәкъдиме. Русия яки чит ил вузларының ике галиме фикере. олимпиада. фестиваль. иҗат конкурсларында җиңүне раслаучы дипломнар булу шарт.

(«Казанский университет», №10).

Сазлык ташбакасы

Октябрь районының Зур Чирмешән елгасында сазлык ташбакасы табылган Бу — ташбакалар яши торган иң төньяк чик Аны Казан университетының биология факультеты студентлары табып. университетка алып кайткан Ташбака Татарстанга көньяктан йөзеп килгән булса кирәк

Алла Пугачева Филиппны «әти» итәрме?

Алла Пугачева Америкага китәр алдыннан Әлмәттә концерт куйды һәм шунда бераз гаилә серләрен дә ачты

Сәхнә йолдызы үзенең нефтьчеләр башкаласына килүе өчен күпме сөмен сорагандыр аны*сын* кунакчыл хуҗалар яшерен сер итеп саклый Шунысы хак артист бурычлы булып калмый 20гә якын җыр башкара 15ләп егет һәм ир белән парлап бии хәтта хакимият башлыгы И Гәрәев белән ике тавышка җыр да башкара Шәһәр хакимияте башлыгы үзе дә аны иң олы кунак итеп самолет трабыннан ук каршы ала

Җырчы жирле журналистлар белән очрашырга да вакыт таба Матбугат конференциясендә интим мәсьәлә — Киркоровның нәселен дәвам иттерү мәсьәләсен дә читләтеп үтми «Яшь Филиппка әти булырга вакыттыр?» дигән сорауга «Әйе» дип җавап бирә Күптән түгел аның Валентин Юдашкинга «кирәк булуы бар» дип киңрәк күлмәк тегәргә заказ бирүе юкка гына түгелдер мөгаен

Сүз уңаенда шунысын да әйтик. аның ире Әлмәткә килмәгән иде

Алла Пугачеваны каршыларга алдан ук яхшы әзерләнделәр Хәтта аның менюсы белән дә кызыксындылар Алла Борисовна биредә пилмәнне дә бәлешне дә яратып ашады **«Аргументы и факты»** атналыгының (№45) Татарстанда чыга торган кушымтасы шул хакта яза

Бу концертны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары З Вәлиева да карады Билет бәясе кайберәүләр уйлаганча, 1 миллион сум түгел 250 мең сум гына иде

Брежневның кызы — кызыл принцесса

— Леонид Брежневның кызы Галина турында соңгы вакытта бер хәбәр дә юк Кайда ул? — дигән сорауга **«Аргументы и факты»** атналыгы №45) болай җавап бирә «Галина Леонидовна элеккечә Мәскәүдә яши һәм ни гаҗәп - ул Англиядәге «Ревшифт компани» театры куйган «Кызыл принцесса» спектакленең яшь драматург Николас Мах Инерни пьесасы буенча) төп каһарманы булып уйнаган Спектакль Британиянең 24 шәһәрендә уйналачак Бу илдә берничә ел элек «Брежнев кызы» дигән документаль фильм күрсәтелгән һәм ул сенсациягә әверелгән»

Тагын сиам игезәкләре

Күптән түгел Кишиневтагы ана һәм бала үзәгендә сиам игезәкләре туды

— Яңа туган игезәк малайларның озак яшәвенә өмет аз — дип хәбәр итте әлеге үзәкнең акушерлык бүлеге мөдире Валентин Фрипту — Муеннан кендеккә чаклы күкрәк читләре тоташып үскән Йөрәк һәм бавыр икесенә уртак ө башлары - ике аяк һәм кул лары - дүртәү

Молдовада соңгы ун елда сиам игезәкләре икенче тапкыр туган Моннан 2 ел элек ян яклары тоташкан кыз балалар туган ләкин 8 көннән соң алар үлгән булган

(«Российская газета», № 218)

Башы бар, йомгагы бар!..

Юк һич кенә дә өйдәге «сер»не читкә чыгару. читкә тарату түгел бу Киресенчә — үз шатлыгыбызны гәзит укучыларыбыз белән дә уртаклашырга ашыгу! Ә моның сәбәбе-сылтавы шул узган атнаның җомгасында фотохәбәрчебез Әкрам Шәфигуллинның хатыны Зөһрә ханым дөньяга (димәк. «Мәдәни җомга»га да!) бер туп-түгәрәк, сау-сәламәт ир бала бүләк итте Шушы атнаның дүшәмбесендә исә тагын бер шатлыклы хәбәр килеп ирешә бу юлы гәзитебезнең рәссамы Ринат Хәсәншинның хатыны Гөлнур ханым малай тапкан! Менә шундый хәл җәмәгать тормыш дәвам итә юллар алга-карый

Димәк килечәктә «Мәдәни җомга»ны алдыручылар да артыр дип ышанабыз Ир-егетләр туа ласаса!

Бу котлауларга исә укучылары быз да теләктәш булыр дип уйлыйбыз

ЗӨҺРӘ, ӘКРАМ!

Ошбу көннең иртәсендә
Дөньяга шатлык тулган —
Җир шарында хәбәр йөри
Әкрамның улы туган!

Уллар белән олпатлы без —
Шулар белән котлы без
«Соңгысы булмасын!» — диеп
Чын йөрәктән котлыйбыз!

ГӨЛНУР, РИНАТ!

Бу дөньяда һәрбер эшнең
Башы бар йомгагы бар —
Атна саен малай таба
«Мәдәни җомга»лылар!

Кызлар туса — шатлык дилә.
Малай туса — горурлык, —
Хәсәншинның бер малае
Ун җегеткә торырлык!

Һәр гамәлнең башы бар да,
Һәр эшнең йомгагы бар,
«Соңгысы булмасын!» — диләр
«Мәдәни җомга»лылар.

Нияз АКМАЛ.
Рөстәм НУРИЕВ рәсемнәре

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ



ШАГЫЙРЬ 5 НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛА

Без — бар. Димәк, сөю яши

Октябрь, 1995. Аккош күле

I

Кол Галинең Зөләйхасы,
Йосыфы да түгелдер без.
Җан теләсә, мөлдерәмә
Тулырбыз да түгелербез.

Хак Тәгалә бар кылган бит
Шушы мәхшәр уртасында,
Без — бар. Димәк, сөю яши...
«Яшәрмен, — дип, — сездән соң да».

Бер-беребезне төштә түгел,
Өндә күреп булдык гашыйк.
Бер туфракта,
Бер үк шартта,
Бергә үстек тәгәрәшеп.

Көтми безне пәйгамбәрлек,
Көтми тәхет,
Патшалык та...
Йосыф-Зөләйха түгелбез,
Безнең бәхет башкалыкта.

II

Халкыбызның Зөһрәсе дә,
Таһиры да булмабыздыр.
Без башлаган сөю түгел,
Ахыры да булмабыздыр.

Мичкәләрдә акмамыйдыр
Ыргытсалар суларга да.
Гомер узар-китәр шулай,
Өлгермәбез суларга да.

Теркелдәсен безнең сөю,
Төшмик әле бу арбадан.
Халык аны эч пошудан
Гына уйлап чыгармаган.

Бу заманның зеңләп торган
Зиндан кебек авыр мәле...
Ә кем белә?
Бәхет заты
Шунда — төптәдер дә әле.

III

Синдә яши Ләйләсе дә,
Миндә яши Мәҗнүне дә.
Шуңа күрә йөртәбез без
Дөньялыкка рәнҗүне дә.

Рәнҗү — аңлый алмаулары
Безнең сөю-сәгадәтне...
«Ах, дөнья бу! Оныттырыр
Әле, — диләр, — ул гадәтне!»

Табигатьнең үзе биргән
Кодрәтле хис гадәтмени?
Шуны татырга теләми
Яши алу әдәпмени?

IY

Кайный казан, гөрли Казан,
Без нәкъ шуның уртасында.
Без — бар. Димәк, сөю яши,
Димәк, яшәр бездән соң да.

... — Шундый чорда ничек туган ул?

1986. Кырлай

— Нәрсә сорап торасың син монда?
Тукай туган халык хыялында.
Ә хыялның төбе — Без барлык.
Без барында — туа чынбарлык.

Күчеп йөрми агач... күчерәләр

Март, 1985

Урман булып,
Үз кабилә булып
Яшәп ята агач...
Кеше ни хәл итсен,
Күчеп йөри
Агач булалмагач.

Торма елап,
Салмый колак,
Дөнья бара тора.
Карт агачлар әкрен-әкрен генә
Һаман ава тора.

Ава тора...
Кайберләре аның
Шартлап кына сына.
Син ышанма, әнә шундый язмыш -
Сиңа булмасына!
Гыйбрәтләр ал! —

Кайберләре әле
Череп таркалалар
Һәм гөрселдәп ауганнарда...
Алар арта бара.

Бу — табигать.
Канун.
Тыңлап кара,
Чыгып ындыр аша!
Тумыштан ук аның кайберләре
Һаман ыңгыраша.

Мәгънә, акыл туплаганнар киткән
Җиде күккә ашып.
Шалтыравык агач һаман яши,
Яши ыңгырашып.
Син урманга чык та,
Утыр,
Уйлан,
Табып агач төбен.
Һәм күрерсең тирәсендә аның
Яшьләр үскәнлеген.

Син утырган төпне ясаган бит
Синең әллә кемең.
Үсентеләр бәлмәс дисеңме син
Кемнәр кискәнлеген.

Кешене дә агач кебек шулай
Җә кисәләр,
Җә...
Кучерәләр генә.
Халыклар шул фаҗигане
Кичерәләр генә.

Ә шулай да урман булып, әнә,
Яшәп ята агач.
Кешенең үз хәле хәлдән ашкан,
Агач булалмагач.

Син — әҗәт!

Октябрь, 1995

«Ни гамь — бәлсәм...»
Дәрдмәнд.

Ни гамь — баесам,
«Аh!» итмә,
Ни гаҗәп!
Бер хаҗәт эчендә яши
Мең хаҗәт...
... Мең хаҗәт эчендә бар тик
Бер хаҗәт —
Халкың өчен дөньялыкка
Син — әҗәт...

Болай да бит инде...

Октябрь, 1995. Аккош күле

Мин дә куркам,
Куркам югалтудан,
Һәммәбезгә хас ул:
Югалтулар кайгылы моң булып
Иңри ничә гас...

Җиргә-суга,
Ай, Кояшка
Күпме булма гашыйк,
Дәүләтеңне югалттыңмы,
Димәк, артык кашык.

Болай да бит чор әнәсе белән
Язмышлар каела.
Сак-Сок бул, дип тәрки халыкларның
Язмыйк маңгаена.

Җитмәгәнме,
Инде җитмәгәнме
Тарих суккан мөһер...
Мәскәү якадан җибәрсә
Дуслашабыз, шөкер!

Болай да бит безнең хакта
Әйткәннәре хәтәр:
«Чучка чалсаң — кяфер чыга,
Кяфер чалсаң — татар»

Чынлыкта ул шулай да бит,
Тик чынлыкта гына...
Аста... Эчтә... Мөселманлык
Һаман чыңлап тора.
Болай да бит безне борылыш саен
Тайгак көтеп тора.

Калсын алар,
Калсын әкиятләрдә
Гыйбрәт булып кына.
Менә шушы мәхшәрләрдән
Җай гына ычкынып,
Яшәмәскә иде безгә
Сак белән Сок булып.

Ни хикмәттер, мәчет түгел,
Чиркәү калыплады...
Сак белән Сок булып очты
Төрки халыклары.

Болай да бит инде... Ярар
Җан әрнүем — юкка!
Әйдә, суга керик әле,
Без һаман да утта.

Су йөгереп килә...

1971. Минзәлә

Көймә күчерәбез күлдән-күлгә,
Арттан эзе бара сыдырылып...
Калган эздән су йөгереп килә,
Су йөгереп килә... эзгә тулып.
...Аерылырга гына язмасын ул,
Бәгырьләрең чыгар суырылып.

Аз таптык

1987. Әхмәт Исхак

— Ни гомерләр кәрешсәк тә,
Азатлыкны аз таптык,
Үздәүләтле бер Пушкинда
Ирек яши, Азатлык.

СӘХНӘ БИЕКЛЕГЕНДӘ КАЛУ

Безне яшьләр дисәләр дә...

Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап өч ел мәктәптә укытсам да, күңелем һаман балачак хыялы — театрга тартыла иде. Нәрсә булса да булыр, дип, тәвәккәлләп, мин май аеның матур бер көнендә Островский урамында урнашкан Татар дәүләт яшьләр театрына юл тоттым.

Икенче катка менеп, театр директоры Фәрит абый Хәбибуллинны сорадым. «Ул репетициядә, нинди йомыш белән килгән идегез?» — диделәр. Турыдан-туры: «Актриса булып эшкә урнашасым килә», — дип җавап бирдем. Шул мизгелдә мин үземә кызыксынып карап торган, Г.Камал исемендәге театр актеры һәм режиссеры Ринат Әюповны күреп алдым. Әле өч көн элек кенә аны яшьләр театрына баш режиссер итеп билгеләгәннәр икән. Г.Камал исемендәге театр тамашачылары Р.Әюповны «Һинд кызы», «Әлепле әртисләре» спектакльләре режиссеры, «Казан егетләре» һәм «Тагын Казан егетләре» спектакльләрендә Тукай ролен башкарган актер буларак беләләр. Ә мин аның яшьләр театрында Ф.Шиллер әсәре буенча куелган «Мәкер һәм мәхәббәт» спектаклен дә карарга өлгергән идем инде.

Ул мине тыңлаганнан соң: «Мин актерлык белеме булмаганнарны эшкә алмыйм шул. Сезнең профессиягез бик яхшы бит, ә монда акчасы да юк, бинасы да җимерек, Чаллы яисә Түбән Кама театрына барып карагыз. Андагы театрлар әллә кайдан «мин» дип күренеп торалар», — дип куйды.

Турысын гына әйткәндә, мин бу сүзләрне шикләнеп кабул иттем. Ник дигәндә, театрның киләчәгенә ышанмаган булса, ул үзе бирегә килер идемени? Шуннан соң мин бер сүз дә әйтмичә театрдан чыгып киттем. Минем яңадан килергә исәбем бар иде әле. Икенче килүемдә мине баш режиссер «фанатик» дип атады. Ә театрда эшли башлагач, мин үзем генә түгел, монда эшләүчеләрнең күбесенең үз һөнәрләрен үлеп яратуларын күрдем.

Баш режиссерның гадилеге, кешеләрне аңлый һәм тыңлый белүе беренче очрашуда ук миндә аңа карата ихтирам хисе уятты. Шуңа күрә дә театр артистлары аңа бертавыштан үзләренең ышанычларын белдергәннәрдер дә.

Баш режиссер тумышы белән Татарстанның Питрәч районы Шәле авылыннан. Шунда урта мәктәпне тәмамлап, Ринат әфәнде Казанга театр училищесына укырга керә. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Мәскәүдәге Щепкин исемендәге театр училищесының актерлар бүлегендә белем ала. Менә шул студент елларында режиссура белән кызыксына башлый.

Мәскәүдәге «Болгар» татар театрында Туфан абый Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» әсәрен сәхнәләштерә. Мәскәү тамашачылары аны бик җылы кабул итә. Яшь артист, институтны тәмамлагач, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлый, шул ук вакытта читтән торып Щукин исемендәге югары театр институтының режиссура факультетын тәмамлый. Хәзерге вакытта ул, Казан дәүләт яшьләр театрында эшләү белән беррәттән, Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә актерлар әзерләү факультетында шәкертләргә дәрес бирә. Хәтта җәйге ял вакытын да эшләп үткәрде ул. «Нур» театры чакыруы буенча Башкортстанга барып, аның актерлары белән Аманулланың «Әлепле әртисләре» пьесасын икенче тапкыр сәхнәләштерде.

Гадәттә, без театр турында сүз чыкса: «Театр нәрсәдән башлана?» — дип сорарга яратабыз. Ә менә безнең театрга иң беренче нәүбәттә: «Театр кемнән башлана?» — дигән сорау бирергә кирәктер. Татар дәүләт яшьләр театры сигез ел элек студия буларак оеша. Аңа театрыбызның хәзерге директоры Фәрит Хәбибуллин нигез сала. Шул чорда ул театр-студиянең сәнгать җитәкчесе булып эшли.

Шөкер, театрыбыз талантлы актерларга да бай. Татарстанның халык артисты Нуриәхмәт Сафин театр-студиядә беренче көннән башлап эшли. Шушы кыска гына вакыт эчендә ул бик күп онытылмаслык образлар иҗат итте.

Тамашачылар Нуриәхмәт Сафинның Солтан («Кырларым-тугайларым»), Хәмзин («Сандугачлар килгән безгә»), Моталлап («Уеннан уймак»), Президент («Мәкер һәм мәхәббәт») Җәгур («Хыялдагы дөнья»), Юлдаш Адамович («Оят төне») образларын бик яратып кабул итте.

Фәнәвил Галиев, Мәдинә Сафиуллина, Рәсил Акбашев, Раушания Әхмәтова, Гөлнара Илалиева, Земфира Хәсәнова, Вәли Якуповлар да театрда инде шактый эшләп, якты, матур, онытылмаслык образлар иҗат иткән актерлар.

Быел театрыбызга Казан театр училищесын тәмамлап бертөркем яшьләр килде. Алар да килү белән җиң сыганып эшкә тотындылар.

Театрның труппа мөдире Диләрә Егорованы да артистлар әниләре кебек якын күрәләр.

Берочтан «Мәдәни җомга» укучылары белән зур шатлыгыбызны уртаклашасыбыз килә. Быел безгә яңа бина — җитен комбинатының элекке мәдәният сараен бирделәр. Бу безнең өчен генә түгел, ә бөтен Казан шәһәрендә, бигрәк тә Киров һәм Мәскәү районында яшәүче театр сөюче дусларыбыз өчен дә сөенечле вакыйга булыр дип ышанабыз.

Быелгы яңа — тугызынчы сезонны без мәшһүр «Башмагым» музыкаль комедиясе белән ачып җибәрәбез. Репертуарыбызда, «Башмагым»нан тыш, Н.Кәримованың «Үп мине, Зәйтүнә» комедиясе, И.Сәлаховның «Тайгак кичү»е, Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясе, В.Розовның «Шатлык эзләгәндә» пьесасы, В.Шекспирның «Король Лир» трагедиясе, Т.Миңнуллинның «Кырларым-тугайларым» драмасы, Ш.Зәйнинең «Уеннан-уймак» комедиясе, Ф.Галиевнең «Хыялдагы дөнья» лирик комедиясе, Б.Мокаевның «Оят төне»; Н.Дәүлинең «Тозакка төшкән аучы», Р.Корбанның «Керпе малае дуслар эзли», Н.Новоселецкаяның «Кадерне белмәүче бурсык» дигән балалар өчен язылган әкиятләре дә бар. Безнең театрга рәхим итегез!

Нәфисә ИСМӘГЫЙЛЕВА,
яшьләр театрының әдәби бүлек мөдире.

● *Артистлар Мәдинә Сафиуллина, Лилия Нәгыймуллина һәм Лилия Җиһангирова Т.Гыйззәтнең «Башмагым» спектаклендә.*

● *Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» дигән спектакленнән күренешләр. Нуриәхмәт Сафин — президент фон Вальтер, Илфат Камалиев — майор Фердинант рольләрендә.*

Фоат **ГАРИФУЛЛИН** төшергән рәсемнәр.

ҖӘНӘТ ӘҢГӘМӘ

Рәссам Фәрит ВАХИТ:

«Мин үз журналымны чыгарырга телим»

— Нихәлләрең бар, Фәрит дус?

— Хәлләр изге, кызлар бизде, диләрме әле.

— Кызлар бизсә, бизсен, илһамың бизмәсен.

— Илһам бар, алда эшлисе эшләр күп, ләкин...

— Нигә «ләкин»? Синең рәсемнәрең чит илләрдә дә мәшһүр бит, тагын ни җитми?

— Мин үз журналымны чыгарырга телим. Ул журнал «Сәясәт вә карикатура» исемле булырга тиеш, ягъни анда бөтен дөнья карикатурачыларының бөтендөнья сәясәтенә карата сатирик-көлке-шаян рәсемнәре, хикәяләр, мәкаләләр урын алыр иде. Әлбәттә, татар рәссамнарының, татар сатирик язучыларының әсәрләре журналның төп нигезе булачак. Ләкин иганәче, химаяче юк. Акчасыз андый шәп журналны чыгару мөмкин түгел.

— Хөкүмәтебез ничек карый бу эшкә?

— Берничек тә карамый.

— Бу журналның кирәклеген исбат иткәндә, хөкүмәт андый акчаны табар иде, шәт.

— Мин рәссам, мин иҗатчы, ә исбат итү акча артыннан йөрү, дөресен әйтим, кулдан килми.

— Димәк, «Мәдәни җомга» белән берләшергә кирәк булып чыга?...

— Әйдәгез, тырышып карыйк... Ул журнал киләчәктә бөтен чыгымнарны аклаячак, валюта китерәчәк.

— Тагын ни гозерең бар, Фәрит туган?

— Дөньяда ФЕКО (Аурупа карикатурачылары оешмаларының федерациясе) дигән җәмгыять бар. Бу федерациядә егерме дүрт ил әгъза булып тора. Шулар арасыннан Русия белән Татарстан да 1992 елда әгъза булып кергән иде. Җәмгыятьтә әгъзалыкны саклар өчен елга 120 доллар түләп барырга кирәк. Мин моңарчы үз акчамны түли килдем. Хәзер кесә такырайды. Соңгы ике елга шул керемне түләмәгәннәре өчен Русия белән Татарстан федерациядән чыгарылу алдында тора. Төркия, Италия хөкүмәтләре һәм башка илләр вакытында түләп бара. Ике хәерче генә түли алмый. Әле соң түгел, ике йөз кырык долларны түләсәк, Татарстан федерациядә калачак.

— Бу федерациянең ни файдасы бар?

— Федерация белән кулга-кул тотынып эшләсәк, Татарстан рәссамнарының аерым рәсемнәре, күргәзмәләре дөньяга чыгар иде, чит ил рәссамнары безгә килә алыр иде. Файдасы бөтен дөнья белән аралашудан, күргәзмәләрдән керем алудан гыйбарәт.

— Эш һаман акчага килеп терәлә, димәк?..

— Кызганыч, ни хөкүмәт, ни бай татарлар бу эшне җитдигә санамый, ахрысы.

— Синең бу сүзләрең турыдан-туры химаячеләргә, хөкүмәт әһелләренә мөрәҗәгать булып яңгырасын. Бәлки, кызыксынучы табылыр.

— Амин!

— Әйдә, Фәрит, алайса без син башлаган бу мөһим эшне иң кечкенәсеннән, без булдыра ала торганыннан башлап карыйк. Син карикатураларыңны безгә — «Мәдәни җомга»га китер, халык аларны күреп, шатлана торсын. Алга таба бу ике эшне үстерәлтер өчен тәдбирләр корыйк!

— Иншалла!

Әңгәмәне **БАТУЛЛА** әзерләде.

Сүзгә аз, көйгә бай

9-11 ноябрьдә Татарстан Композиторлар берлегенең пленумы булып узды

Татарстан Композиторлар берлегенең XXIY пленумы сүзгә аз, музыкага бай булды диясе килә. Чынлап та Берлек рәисе Рәшит Кәлимуллин, да сүзне кыска тотты. Ул бары тик шушы көннәрдә узган Русия Композиторлар берлегенең YII съездында Татарстан композиторларының әсәрләре яңгыравын һәм аларның югары бәя алуын әйтте. Музыка белгече — концертны алып баручы Йолдыз Исәнбәт тә әсәрләре яңгыраячак композиторлар эшчәнлегенә кыскача гына тукталды.

Татарстан дәүләт симфоник оркестры беренче булып Леонид Любовскийның кыллы оркестр өчен симфониниеттасын башкарды. Әсәр караңгы төсләрдән, авыр хисләрдән башланып китә. Музыка әкренләп яктыра, җиңеләя һәм яшәү мәгънәсенең гүзәл төсмерләрен гәүдәләндерә.

Шулай да бу җыенда иң тәэсирле яңгыраган әсәр композитор Алмаз Монасыйповның Муса Җәлил турындагы симфоник поэмасы булды кебек. Скрипка аһәңе артыннан ялгыз гына яшәү авазы ишетелә, аңа татар моңы кушыла, дөньяга отыры киңрәк җәелә бара. Дәһшәтле музыка үлем якынлашуын искәртеп-искәртеп торса да, кеше соңгы сулышына кадәр яши, көрәшә, өмет итә. Йа, Ходаем, автор бу әсәрен иҗат иткәндә үзе дә авыр хисләр аша яшәү нурына, тормыш яктылыгына омтылгандыр, мең газаплар кичергәндер. Зур, тирән эчтәлеккә ия әсәр бары тик киеренке һәм әрнүле кичерешләр, тетрәнүләр аша гына туа, барлыкка килә ала. Алмаз аганың үзеннән шул хакта сорагач:

— Бу әсәремне үкси-үкси яздым, — диде.

... Менә меңләгән шәһитләр аһәңе яңгырый. Тик музыканың төп көче — яшәү сулышын җиткерә алуда. Җәлилебез, Моабит төрмәсе михнәтләрен кичкән һәм шунда башын салган татар улы безнең йөрәкләрдә, ул музыка булып яши. Татарның яшәү көчен чагылдырган, ачып биргән мондый симфоник әсәрләр пленумнарда гына түгел, ә һәр тантанада яңгырарга, татар горурлыгын исебезгә төшереп торырга лаек.

Композитор Альберт Леманның «Татар рапсодиясе» чишмәләр агуын, кошлар сайравын, меңләгән кыңгыраулар чыңлавын, болыннардан аллы-гөлле чәчәкләрнең таң җилендә талпынуын, Кояшка үрелүен, ә аяз күкнең, зәңгәр һаваның безне еракларга әйдәвен, гүзәллеккә чакыруын, бәхеткә, яшәүгә омтылдыруын күз алдына китерә. Әйтерсең лә, йөзләгән, меңләгән бәхетле сабый «Әпипә»гә бии.

Шөкер, Татарстаныбызда җаннарны тетрәндереп, рухыбызны сафландырырга сәләтле әсәрләр язарлык композиторларыбыз булу белән бәрәттән, аларны теләсә кайсы ил сәхнәләрендә уйнарга сәләтле көчле симфоник оркестрыбыз да бар. Бу — безнең зур байлыгыбыз. Тик без хәзергә әлеге байлыгыбызны тулысынча күрсәтә дә, файдалана да белмибез бугай. Әйтик, радиодан да, телевидениедән дә югары кимәлдә шәет ителгән симфоник әсәрләрне ешрак яңгырату максатка ярашлы булыр иде. Югыйсә, безнең тыңлаучы тирән эчтәлеккә ия музыкаль әсәрләрдән беркадәр читтә кала килә.

Шунысы куанычлы, композитор Рәшит Кәлимуллинның дүртенче кыллы квартеты беренче тапкыр япон тыңлаучыларына тәкъдим ителеп, аларның югары бәясенә лаек булган иде. Композитор Мәсгудә Шәмсетдинова әсәрләре дә ерак илләргә барып җитте.

Пленумның икенче, өченче концертлары камера әсәрләренә багышланган иде. Үзенчәлекле камера әсәрләре иҗат итүчеләр дә, аны оста итеп башкаручылар да байтак икән бездә. Мәсәлән, Р.Кәлимуллинның Япония тамашачысын таң калдырган дүртенче кыллы квартетын илкүләм танылган, Германиядә җиңү яулап кайткан Шамил Монасыйпов җитәкчелегендәге Казан дәүләт консерваториясе квартеты (М.Зарипов, К.Монасыйпов, А.Әсәдуллин) башкарды. Композитор Илдус Якуповның Антон Дельвиг шигырьләренә язылган вокаль циклын Татарстанның һәм Русиянең атказанган артисты Эмиль Җәләлетдинов җырлады. Леонид Любовскийның кагып уйнала торган уен кораллары өчен дүрт классик фугасын Идрис Сабирьянов җитәкчелегендәге кагып уйнала торган уен кораллары квартеты башкарды.

Киләчәктә без композиторларыбызның җитди, күләмле әсәрләре белән сәхнәләрдә, радио һәм телевидение тапшыруларында танышуны дәвам итәрләр, дигән ниятә калабыз.

Сәрмәдия СӘЛӘЙМАН.

ИДЕ БУЫН ЯДКАРЕ

Җир куенында күпме китап ята?

Бу хакта бер Аллаһы Тәгалә үзе генә белә торгандыр

Татар китабы язмышы да халык язмышына охшаган. Аны да яндырганнар, юк иткәннәр. Әмма әллә нинди болгавыр заманнарда да татар китабын саклап калу, аны мәсхәрә итүгә юл куймас өчен гомерләрен кызганмаган каһарманнар да булган. Берәүләр аны киләчәк буыннар өчен чолан-чормаларда, базда саклаган, икенчеләре җиргә күмгән. Хәер, җир куенына кергән китап инде беркайчан да тормышка кайта алмас. Ул ике ай эчендә тәмам череп, таркалып бетә икән. Кулга алуга ук кирпеч кебек сына, уала. Ни кызганыч, заманалар уңай якка үзгәрсә дә, татар кешесе һаман китап күмә. Гасырлар буена изеп, кимсетеп шул хәлгә җиткергәннәр аны.



Менә без Кукмара районының Төркәш авылы зиратында тагын бер шундый каберне казыйбыз. Инде эңгер-меңгер. Татарстан Милли китапханәсенең сирәк китаплар бүлеге мөдире Раиф Мәрданов, аның гыйльми хезмәткәре Ирек Һадиев якындагы кабер ташларын өйрәнеп йөри. Зират шактый борынгы. Монда узган гасыр каберлекләре дә шактый. Авылда мулла булып торган Габделхак Хәйретдиновның гозере белән әлеге зиратка аның китапларын күмгән Әмирхан ага Рәфыйков һәм тагын берничә кеше чиратлашып кабер казый. Милли китапханә хезмәткәре Халит Вәлитов белән Кукмара район гәзите редакциясенең җаваплы сәркатибе Рәшит Миңлегалиев аларны кинотасмага төшереп тора. Төркәш зиратында борынгы китаплар күмелгән, дигән хәбәрне ишеткәч, язучы Мәгъсүм ага Насыйбуллин да бирегә килсә иткән. Йөзе бик борчулы.

— Исән генә булса идә китаплар, — дип уфтана.

— Ай-һай, сакланган микән, — ди безнең янга килеп баскан Раиф. — Мондый каберләр Әгерҗе районында да бар иде. Берсе дә денгә кертердәй түгел. Явыз Иван Казанны басып алганнан бирле күмәләр татар китабын.

Мәгъсүм абыйның йөзе тагын да моңсулана төшә:

— Элекке гасырларда, репрессия елларында китап күмгән кешеләрне аңлап була, тик менә хәзер китап күмә торган заман түгел бит.

Ул арада инде шактый тирән чокырдан менеп баскан Әмирхан абый телгә килә:

— Миннән соң теләсә кайда аунап, мәсхәрәләнеп ятмасыннар, дип күмдерде ул китапларны Габделхак бабай. Туксан яшьтән узган иде үзе. Хәтерем ялгышмаса, күбесе гарәп, фарсы телендә иде. Аларны хәзер авылда укый белүче дә юк бит.

Форсаттан файдаланып, Милли китапханәнең сирәк китаплар бүлеге мөдире Раиф Мәрдановка сорау бирәм:

— Дини китапларны, кулъязмаларны җиргә күмү Шәригать тарафыннан тыелмыймыни? — дим.

— Тыелмый шул, — ди Раиф, кәрсенеп. — Китапны җир куенына салу аны Аллаһы Тәгаләнең үзенә тапшыру дип санала. Яндыру да гөнаһ түгел. Халыкны гаепләп булмый, ул бит аны кяфер кулына килеп эләкмәсен дип шулай эшләгән. Тик хәзер бу һич тә дөрес гамәл түгел. Бөртекләп җыябыз без китапларны. Борынгы китаплары булган кешеләр кулларына кәрәк алганчы! Милли китапханәнең сирәк китаплар бүлегенә мөрәҗәгать итсеннәр иде.

Әйе, күмәләр татар китабын. Казан каласының Яңа бистә зиратында да бик күп китаплар ята. Анда Казан атабы, Даган, Капитан юллары белән бергә Китап юлы да бар. Утызынчы елларда ул урынга бер олау китап күмелгән, дип сөйлиләр.

Ниһаять, чокырдан өстенә клеенка капланган зур гына бер ләгәнне өстерәп чыгарабыз. Бәлки, сакланганнардыр әле, дигән өмет тә бар. Ник дигәндә, алты-җиде ел элек кенә күмелгән бит алар.

Менә Раиф Мәрданов инде җир төсенә керә башлаган бер китапны кулына ала. Юк, сакланмаган китап. Укый алмаслык дәрәҗәгә җитеп, череп, коргаксып, юешләнеп беткән. Арада саф гарәп телендә басылган китаплар да бар. Күбесе Мисырдан алып кайтылган. Башлыча дини китаплар: Шәригать кануннары, Ислам нигезләре, дини хикәяләр. Китапларны барлый торгач, күренекле татар философы Зыя Камалиның «Фәлсәфи игътисадия» дигән әсәре дә килеп чыкты. XX гасыр башында Казанда дөнья күргән басмалар да бар иде. Ул заманда укырга җайлы булган Казан басмалары Шәрык илләрендә дә дан тоткан. Җәмгысе кырык китап җир куенында яткан булып чыкты.

— Әрәм хәзинә, — дип авыр сулады Раиф. — Тәмам яраксыз хәлгә килгәннәр. Бер-икесен гыйбрәт өчен мәктәп музеена куярга кирәк. Татар китабы бүтән беркайчан да күмелергә тиеш түгел. Тарихыбызны күмәбез бит, җәмәгать.

Кич. Аяк астында юеш кар шыгырдый. Томан күтәрелеп, күз күреме дә начарланды. Без Мәгъсүм абый Насыйбуллин белән юл уңаенда яткан Нырты авылына барып, андагы музей белән танышып йөргән арада Раиф Мәрданов һәм аның хезмәттәшләре Төркәш авылыннан бер капчык китап җыеп алып кайттылар. Болары бик яхшы сакланган тагын берничә гасыр буена халыкка хезмәт итәрдәй хәлдә.

— Шәригать китабын музейга биреп калдырабыз, — дип, Раиф мәктәп музее мөдире Роза апага саллы гына бер китап суза. — XIX гасыр ахырында басылган. Саклагыз.

Җиңел машина тайгак тигез юлдан Казанга чаба. Әнә читтә тагын бер авыл калды. Якында гына томанга төренгән зират шәйләнә.

Татар зиратлары... Күпме сәр, күпмә китап саклана синең куеныңда.

Күммәгез китапларны. Аларны бөртекләп җыяр, күз карасыдай саклар вакыт җитте, милләттәшләр.

Мәдинә НУРУЛЛА,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
Төркәш — Казан.

● Әзһәр Хөсәенов.

● Гөлшат Зәйнашева.

● Хәләф Низамов.

Укучыларыбызга хәбәр иткән идек инде: редакциядә 27 октябрьдә, сөекле композиторыбызның чираттагы, алтынчы табыны узды. 1 ноябрьдә исә аның каберен зиярәт кылу булды.
Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды һәм «Мәдәни җомга» оештырган бу табында сөйләнгән истәлекләрне, хатирә-теләкләрне без укучыларыбызга да җиткерергә вәгъдә иткән идек. Әлбәттә, һәр истәлекне ахырынача сөйләп-әйтеп бетереп булмас. Шулай да, вәгъдәдә торырга тырыштык.

Шәмдәлләрдә генә

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА, шагыйрә, табынның хуҗабикәсе:

— Бу мәҗлесне — алтынчы табынны да — без, гадәттәгечә, шәм яндырып башлыйк. Халкыбызның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» дигән җырыннан килә бу. Белгәнегезчә, Сара Садыйкованың мәдәни фонды рәисе — Әзһәр Хөсәенов. Әзһәр, әйдә, быелгы беренче табын шәмен үзең яндырып-балкытып җибәр әле! (Шәм кабынганнан соң, Гөлшат ханым Татарстан Президенты аппаратының җитәкчесенә мөрәҗәгать итте): Хәләф туган, сез — Президентыбызның уң кулы булган мөхтәрәм кеше. Сара апа белән дә якын дуслар, гаилә дуслары идегез. Беренче сүзне башлап җибәрегез әле.

Хәләф НИЗАМОВ, Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе:

— Сара апа турында мин бик күп матур, күркәм сүзләр әйтә алыр идем. 1968 елда беренче тапкыр очрашып, соңгы көннәренә кадәр аның белән аралашып, хәтта гаилә дуслары булып яшәдек.

Менә, аның белән берничә очрашудан кайбер хатирәләр. 1968 елдан миңа Актаныш районында идеология эшен алып барырга туры килде. Сара апаны без кунакка еш чакыра идек, аралаша идек. Минем балалар, ул килсә, шулкадәр шатланышалар иде. Хәләл җефетем белән дә аның фикерләре, ничектер, уртак туры килә иде. Кызык табып, үзара бик аралашып, сөйләшеп утыралар иде.

1975 елда Актаныштта, район үзәгендә, яңа культура йорты ачтык. Шулчак мин аны өйгә кунакка да дәштем. Сара апа белән тормыш иптәшем мунча керергә киттеләр. Мунча кереп чыккач, иптәшем әйтте: «Сара апа мунча кергәндә кинәт кычкырып җибәрде, «Актаныш турында көй туды!» — диде».

Сара апаның элегрәк тә «Актаныш — ак кала турында көй язасым бар әле», — дигәнен ишеткән идем инде. Хәтерлисезме: «Бер гүзәлен, сагынам Чишмәнең, онытылмасам аны нишләрмен?!» Мостафа Ногман шигыре. Әнә шул 1975 елда без Сара апа белән «Чишмә» колхозында булдык. Колхоз рәисе Ясәви Хөсәенов безне урманнарга алып чыкты, Сон буйларында йөрттек. Җырны иң беренче булып бергә тыңладык.

...«Чишмә» колхозының 50 еллыгын үткәрергә әзерләнгәч, кунакка Сара апа Садыйкованы да дәштек. Ул сары күлмәк кигән иде. Кояш кебек балкып, очынып йөрде. «Чишмә»нең илле еллыгына килдем, йөз еллыгына да килерге Зур Кызыл урамында аңа фатир бирелгән булган. Ул фатир әле хәзер дә бар. Бәлки, әнә шул фатирны аның музее итәргәдер?

Гомумән, Сара апа Садыйкованың исемен композитор буларак кына түгел, ә бәлки кабатланмас шәхес, татар халкының горурлыгы буларак та мәңгеләштерү зарур...

Рәйсә БИЛАЛОВА, Татарстанның халык артисты:

— Мин беренче кат, Сара апаның үзен күреп түгел, ә аны граммофоннан, «Һаваларда йолдыз» җырын җырлавыннан ишетеп белдем. Андагы моң, аның тавышындагы милизмнар!..

Адәми зат булып түгел, ниндидер бер фәрештә булып тоела иде ул миңа. Соңыннан, очрашып-күрешкәч тә сокландым: гади, матур, барысы да иптәшләрчә, һаваланмый. Сара апа белән күп серләшә-сөйләшә идек. Аның вальслары... «Минем тавышка да бер вальс яз әле», — дигәч, ул язды. «Вальс турында вальс», Мәхмүт Хөсәен шигыре иде ул...

Рабит БАТУЛЛА, язучы, драматург, «Мәдәни җомга» гәзитенең сәнгать бүлеге мөдире:

— Сара апаны мәзәкчән кеше буларак та беләм әле», — диде. Әлбәттә, бөтенесен сөйләп-әйтеп тә бетереп булмыйдыр. Әле менә мин, күптән түгел, Сара апаның кызы, оныгы белән очраштым. Аның мирасын, иҗади мирасын мәңгеләштерү хакында да сүз булды. Президент каршындагы Мәдәнияткә булышлык фонды идарәсе җитәкчесе буларак та шул хакта уйлыйм мин: Сара Садыйкова урамын, аның музеен булдыру юнәлешендә безгә җиң сызганып эшләргә кирәк. Әйтик, Мәскәү консерваториясен тәмамлап кайткач ук, хәзерлә идек. Әмма бит аның белән бөйле күп, бик күп мәзәк хәлләрне әле белеп бетермибез. Менә мин үзем шул хакта бер җыентык әзерләп йөрим.

Пушкин әйткән бит, мин үз-үземә һәйкәл салдым, дигән. Аллаһы Тәгалә кайберәүләргә талантны учлап бирә һәм шул талантка ябышып үсә кешеләр. Ә кайсыбер кешегә Аллаһы Тәгалә талантны чамалап кына бирә һәм инде калганын кешенең үзенә калдыра. Әнә шул чамалап кына бирелгән талантны кеше дигәнең йә үтерә, йә инде үзе үк үстерә. Сара апа — үзенә чамалап кына бирелгән талантны үз көче белән даһилар дәрәҗәсенә күтәрә алган кеше...

Әхсән БАЯН, язучы, шагыйрь:

— Дөресен генә әйткәндә, елларын төгәл генә хәтерләмим, әмма мин Сара Садыйкованы малай чактан беләм.

...Казанга килгәч, 50 нче елларда университетны тәмамлагач, «Социалистик Татарстан» гәзитенең әдәбият-сәнгать бүлегендә эшләп йөрим. Бүлектә пианино бар иде. Бервакыт шулай ул килеп керде дә, көй уйный башлады. Кыюлыгы! Миңа шунда әйттеләр, бу — Сара Садыйкова, диделәр. Без әнә шулай шәхсән танышып киттек. Тик минем беркайчан да үземнең аңа җыр сүзләре тәкъдим иткәнем булмады. Беренче җырыбыз «Шауласа кичен агачлар»ның шигырен ул үзе эзләп тапкан иде, өенә чакырды. Ул җыр шулай туды.

Аннан тагын шул: инде «Казан утлары»нда эшләгәндә, Татарстан китап нәшрияты коридорында ничектер шулай өчәү — Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова һәм мин бергә туры килдек. Шунда Рөстәм Яхин, минем бер шигырьне ошатып истә калдырганын әйтеп, шуның ике строфасын укып күрсәтте. Ә Сара Садыйкова шундук әйтте: «И, мин бу шигырьгә көйне яздым шул инде», — диде. Кем белә, бәлки әле язмаган булгандыр да... Әмма икенче көнгә ул җыр әзер иде. Әнә шуннан соң

● Әхсән Баян.

● Рәйсә Билалова һәм Кирам Сатиев.

● Рифкать Исмәгыйлев, Бельгус Сафиуллин һәм Нажия Мусина.

● Әхмәт Рәшит.

● Рәйсә Бикколова һәм Айрат Арсланов.

● Нурмөхәммәт Хисамов.

утлар яна

инде Илһам Шакиров бик яратып башкара торган «Ачуланма» дигән җыр туды.

Лена ШАГЫЙРЬҖАН, шагыйрә:

— Дусларым, миндә шундый бер хис бар: Сара апа чыгыш ясаган барлык-барлык сәхнәләр аны сагынадыр төсле миңа. Бигрәк тә, мин аның Тукай клубында, ул клубның менә шушы Бауман урамында, шушы ук йортта чыгында чыгыш ясавын хәтерлим. Сара апаның сәхнәдәге артистизмына багышлап, мин хәтта «Саумы, сәхнә! Саумы җырларым!» дигән шигырь дә язган идем.

Рифкать ИСМӘГЫЙЛЕВ, ветеран:

— Минем ул елларда Министрлар Советында культура бүлеген алып барган чагым иде. Зөһрә Сәхабиеваны иҗатка-җырга алып кергән Сара Садыйкова эшемә йөгереп килгән. «Менә шундый сандугач бар, аны карга алып китмәсен иде, — ди. — Кияве шундый акыллы егет — Хәйдәр», — ди. Хәер, Хәйдәр Бигичевны — Зөһрәнең иптәшен — барыбыз да яхшы беләбез бит инде хәзер. Менә шул, Зөһрәнең үзен актерлар йортында бер очраткач, Сара апаның сүзе турында ничектер әйттем. Шунда Зөһрә әйтте: «Сара апа минем җырларымны гына яратып тыңлап йөри дип уйлаган идем, ә ул минем бөтен язмышым-тормышыма бәйләнгән икән бит», — диде...

Айрат АРСЛАНОВ, Татарстанның һәм Русия Федерациясенең халык артисты:

— Әле мин бу гүзәл мәҗлестә, бу гүзәл табында беренче тапкыр гына катнашам. Әмма матбугаттан аның хакта әлгәреләреннән үк укып барам. Үзем, әйткәнемчә, төрле сәбәпләр аркасында, беренче тапкыр монда.

Сара апа... Шушы олы шәхес белән таныш булуым, коллегалар булуым белән мин бәхетле. Тукай клубында аның белән еш очраша идем. Миндә Сара апаның үзе язган шигырьләре дә саклана.

Сибгат Хәким аның иң якын дусларыннан иде. Бервакыт Сара Садыйкова әйтте. «Сибгат белән күрештек әле, күп сөйләштек, авыл турында сөйләштек», — диде. Ә минем Сибгат абыйның авыл турында язганын-сөйләгәнен тыңлаганым бар... Бер шигырен сәхнәдән үзем сөйләгән идем, Сара апа аны миннән шундук сорап алды. «Сусау» дигән җыр чыкты шуннан соң. Авылга сусау, табигатькә сусау.

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА:

— Хөрмәтле дуслар, безнең арабызда бүген танылган шагыйрь Шәриф Бикколның хатыны Рәйсә ханым да бар. Алар Шәриф Биккол белән бергә бик матур гомер иттеләр. Аңа сүз бирик әле.

Рәйсә БИККОЛОВА:

— Безнең буын кешеләре Сара апаны яшьтән ишетеп үсте. Илаһи зат итеп күрә идек. Кем уйлаган ул чакта, гаилә дуслары булып әверелербез, дип?! Ел саен ул Уфага килеп китми калмый иде. Җил кебек кенә, безгә гел кереп чыгар иде. Безгә әллә нинди бер җиңеллек, шатлык-рәхәтлек калдырып китә иде...

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА:

— Дусларым, безнең бу кичәдә танылган баянчылар Кирам Сатиев һәм Бельгус Сафиуллин катнаша. Ә менә хәзер чыгыш ясаячак Нәҗия Мусина — халык арасыннан чыккан җырчы. Юк, һәвәскәр җырчы дип әйтәсем килми. Ул сезгә Сара апаның кайбер җырларын җырлап күрсәтер һәм сез Зифа Басыйрованың тавышын танырсыз, тыңлап сокланырсыз. Охшатып җырлау, кеше көлдерү өчен пародияләр башкару түгел бу. Нәҗиягә табигать биргән ул тавышны.

Моңы белән, күңеле белән охшаган ул Зифа Басыйровага. (Сара Садыйкованың җырларын башкарылганнан соң, хуҗабикә сүзне янә табындашларга бирә).

— Сара апа егетләрне дә егет булырак ярата белде. Әйтик, Мөнир Якуповны ярата иде ул. Мәхәббәт мәсьәләсенә килсәк, анда Нурмөхәммәт Хисамовка да урын бар иде.

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ, галим.

— Гөлшат ханым, сез дөрес, яшерми әйттегез: ул мәхәббәт — уртак мәхәббәт иде безнең. Ләкин ул мәхәббәт мине утлы табага бастырырга Сара апага һич комачауламады. Без аның белән «Горурлыгым» дигән җыр яздык. Шунда «Ил йомышын кайда үтәсәм дә...» — дигән юллар бар иде. Шунда ул мине ачуланды. «Сез йөрисез инде ул, йомыш үтәп...» — диде...

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА:

— Хәзер мин сүзне «Сагыналар сине якын дуслар» исемле җыентыкка кергән «Хушлашу» шигыре авторы, Гаяз Исхакый исемендәге бүләк иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан радиосында әдәбият-сәнгать редакциясен җитәкләүче, шагыйрь Әхмәт Рәшиткә бирергә телим.

Әхмәт РӘШИТ:

— Әйе, менә шушы «Хушлашу» шигыренең ике юлы Сара апаның кабер ташына да язылган: «Җырың гына калды микәнни соң, истәлегең булып дөньяга...» Без Сара апа белән уннан артык җыр яздык. «Беренче мәхәббәт» исемле җырыбыз утыз ел элек язылган иде. Бу җыр урыс, чуваш, мари телләрендә яңгырады, чит илләргә чыкты. Сара апа көчле канатлар куйган, без бергә язган җырлардан «Күңелләрдә яз булсын», «Яшәү гимны» кебек җырлар бар. Аларның — дистәдән артык җырның — күбесе популяр җырлар булып чыкты.

Әзһәр ХӨСӘЕНОВ, мәдәни-хәйрия фонды рәисе.

— Минем бүген бер нәрсәгә аеруча игътибар итәсем килә. Сара апа туган илне, туган җирне, туган якны бик тә ярата торган кеше иде. Аның Татарстан төбәкләренә, Татарстанга багышлап язган сиксәнгә якын җыры бар: «Әй ямьле син, Минзәләм ягы» «Актаныш таңнары» «Мөслим тугайлары» «Арча кичләре» «Балтачым туган ягым» — барысы да кабатланмас җырлар бит. Туган якны ярату хисе аша ул үз халкын яратты.

Менә без хәзер Сара апа Садыйкованың бу табынын тагын да киңәйтергә уйладык. аны зур залларга чыгарырга уйлыйбыз. Юк, концерт куеп, тамашачы җыю гына түгел максат ә бәлки «Казанның кадерле кичләре» дигән әлеге табынга — «Сара апа табынына» — тагын да күбрәк кешене бергә җыя алу.

Зиннур МАНСУРОВ, шагыйрь, «Мәдәни җомга» газетенең баш мөхәррире.

— Безнең тарихта Гыйффәт туташлар бар, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Сөләймановалар бар. Менә шулар арасында Сара апабыз бик тә, бик тө аерылып тора. Безнең татар халкының язмышыннан киләдер инде ул тоташ моң белән өретелгән Сара апа да шундый бер шәхес. Үзенең нерв җепселләре белән ул туган халкына, һәрбер татар кешесенең бәгыренә береккән.

Без еш кына әйтергә яратабыз. Сара Садыйкова кебек шәхесләре булса, бөтән халыклар инде әллә нәрсәләр эшләрләр иде, һәйкәлләр салып куярлар иде, янәсе. Мондый сүзләрне без, еш кына, башка шәхесләргә карата да кулланабыз. Бу рәвешле аклану — инде безнең ялкаулыкны, битарафлыкны белдерә башлады. Әйдәгез, купшы сүзләр кабатлаудан туктыйк, әйдәгез, күркәм гореф-гадәтләр арттырыйк. Тукай кеннәре кебек үк, Сара Садыйкова көннәре дә булсын. Аның музее да дәшсен безне, һәйкәле дә үз тирәсенә җыйсын.

Мәшһүр композиторыбыз Сара апа Садыйкованы, аның олы иҗатын, моңын зурлап, һәм дә «Мәдәни җомга»ны хөрмәт итеп килүегез өчен барчагызга да зур рәхмәт. Сара апа безне һәрдаим шулай берләштерсен. Ишекләребез, күңелләребез — сезгә һәрчак ачык!

Табындашлар хатирәсен **Нияз АКМАЛ** язып алды.



● 1 ноябрь. Татар зираты. Сара Садыйкова каберә янында.

Көзге рәнҗү

(Хикәя)

Кояш ТИМБИКОВА

Эш көне азагына авышкан иде инде. Күрше бүлмәдә утыручы егет, ишектән башын тыгып, Камәриягә эндәште:

— Камәрия ханым, башлык үзе (!) чакыра сезне...

Аның һәр сүзе Камәриянең бәгыренә пычактай кадалды. Бердән, Камәрия — ханым-әфәнде була алмыйча, кыз килеш картайган зат, икенчедән, «үзе!» чакыра, дип «олылау»га ул һич тә мохтаҗ түгел. Зур бухгалтериягә баш булып килгән бу бәндә Камәриянең кискән тырнагына да тормый. Әмма, әмма... Камәрия моның ише вак-төяк кимсетүләргә күптән ияләнгән инде.

Иң әүвәл ул үзенә тапшырылган эшләрне фикереннән кичерде: һәммәсенә туры җавап бирерлек мөмкинлеге бар, аннары, өстәл тартмасындагы кеп-кечкенә көзге кыйпылчыгын алып, йөзенә-кашына күз салды. Пөхтәлекне ярата Камәрия. Кулына куен дәфтәрен, каләм эләктерде дә, сабыр атлап, башлык бүлмәсенә китте.

— Ә-ә, әйдә, уз әле, утыр! — дип каршылады аны башлык. Мондый мөрәҗәгать, гадәттә, эшкә бәйле булмый. — Утыр әле, күгәрченкәем!

Камәрия, ни уйларга да белмичә, баш бухгалтерның болындай зур ялтыравык «мәйданы»на аркылы куелган кечкенә генә өстәл янындагы ялгыз урындыкка чүмәшергә мәҗбүр булды. Әлегәчә, «күгәрчен»нәргә мөрәҗәгать иткәндә, башлык әнә шул урынга утыруны мөгъкуль күрә.

— Куен дәфтәреңнең бер тиенгә дә кирәге юк! — диде башлык. — Эштен дә хәзер үк кайтып китә аласың. Беләсеңме нәрсә: иртәгә безнең оешма чөгендергә бара икән. Бездән дә бер кеше сорыйлар. Егетләрнең барысы белән дә сөйләшеп чыктым, берсенең дә мөмкинлеге юк — Гомәрнең хатыны авырый, Сәлимне хатыны җибәрми... Синең бит берәү алдында да отчет бирәсең юк. Әйдә, синнән башлыйбыз, аннары һәркемне, берәм-берәм, барыбыз да барачак. Башлап җибәрергә генә кирәк! Килештекме?!

Башлык Камәриянең һичсүзсез ризалык бирүенә өметләнгән иде, тик бу юлы карт кыз башын аска игән килеш сүзсез тора. Димәк, катырак булырга кирәк.

— Күгәрченкәем, сиңа артка чигергә туры килми: ирең юк, елап торган балаң юк, кемнеңдер рөхсәтен сорарга кирәкми...

— Миңа шифаханәдән шалтыратканнар иде... — Камәрия бу таш бәгырьле кешегә әйтергәме-юкмы, дигәндәй, салмак кына аңлатырга тотынды. — Гаҗиләбезне кабат монда, операциягә китергәннәр. Ул, бездә эшләп, инвалидлыкка чыкты...

Башлык аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәде:

— Карале, ташла әле син ул үлем хәлендәге мәхлуклар артыннан йөрүеңне! Ул шифаханәдә, беләсеңме, күпме микроб?! Гомер кыскарткыч хәлләр?! Мин хәтта әниемне дә чит кешеләрдән генә күмдердем. Сакланырга кирәк! Бетте! Бернинди дә шифаханәләр юк, иртәгә — чөгендергә! Син, соңгысын әйтерәсең инде, төрле чирләшкәләрне карап йөргән өчен түгел, ә менә мин кушканнарны үтәгән өчен хак аласың һәм би-и-к зур акча түләнә!.. Сәгать биштә гаражда бул, шуннан кузгалалар!

Бичара Камәрия чөгендер басуына әзерләнде: чалбар, резин итек, кыска бишмәт кияргә булды, ипи, салкын ит, кыяр, помидор, пешкән йомырка төенләде. Бу сәфәреннән бер генә яхшылык көтте ул, хәерсез авыруга дучар ителгән дусты Гаҗиләгә бик шифалы чөгендерне җир куеныннан үз куллары белән алып кайтып, тиешенчә әзерләп, шифаханәгә барачак. Тик бер көнгә соңгарып. Гаҗилә аны иртәгә иртәдән үк көтә бит. Нишләмәк кирәк?! Булмый, юк, мөмкин түгел...

Кушылган вакытта, чөгендер басуына китәргә тиешле автобус янында, бер эт тә юк иде әле. Шофер гына.

— Чөгендергәме сез? — дип сорады Камәрия.

— Ә? Әйе, ыһы... — Йокысы ачылмаган шоферның сөйләшәсе килми иде.

Башкаларны озак көтәргә туры килде. Шофер рәхәтләнеп йоклап алды, Камәрия исә, операциядә ятучы ахирәтенең, әлеге бухгалтерияләренә мең яхшылык күрсәткән күрше шәһәрдәге дустының хәле турында уйланып, газаплы минутлар кичерде, йөрәге урыныннан кубардай типте, башы чатнады, күз алдында әллә нинди кара очкыннар йөгергәләде.

Бераздан машина ишегендә шәмәхә йөзле ир-ат күренде. «Ага, ху-ху, то-то», дип, үзалдына сөйләнеп алды ул. «Бияләйләр кирәк булачак! — диде. — Синеке дә юкмы?»

— Юк, — диде Камәрия. — Мөмкин булса, миңа да алыгыз, зинһар!

Шактый вакыт узгач, машинага берсеннән-берсе яшьрәк малайлар кереп тула башлады. Сүзләрен һич аңларлык түгел. Ярты гына сүз әйтәләр дә... сүгенәләр.

Берсе ишектән башын сузуга, Камәрия утырган якка тартылды:

— Әбекәй! Бу — минем урын, — диде. — Мин атна буе шунда утырып йөрим инде.

Каян тапкандыр Камәрия шундый кирелекне?! Авызын җыя алмаган малай алдында чигенмәскә булды: «Иртәрәк килергә кирәк иде, — диде. — Мин үзем сайлаган урыннан күчмим!»

Әй, чәпчемәкче булган иде теге тәрбиясез зат, арттагы утыргычлардагы бер иптәше кычкырып өлгерде: «Ташласана шул карчыкларны! Кил минем янга. Менә, сырам да бар!..»

Камәрия янындагы икенче урынга бияләй алып килүче өлкәнрәк кеше утырды. Бу — әлеге малайларның җитәкчесе сыман кешеләре икән. Төркем исә, сигез-тугыз класс бетереп, бухгалтерлар курсына кергән укучылардан тора. Беренче мизгелләрдә Камәрия аларга игътибар итмәскә тырышты, бераздан, бөтен автобусны бары тик шул төр бәндәләр генә тутыргач, аптырап, аларның ни-нәрсә хакында сөйләшүләренә игътибар итте. Йа, Алла, булса да булыр икән мәгънәсезлек: берсе чүптәй әңгәмә башлап җибәрә дә, калганнары шуңа кушыла, зиһенгә һичнинди ризык бирмәстәй буш сүзне, сүгенүнең җиде катына күтәреп, куертыпмы куерталар! Камәриянең мондый хәлдә калганы юк иде. Янындагы «җитәкче»гә теләр-теләмәс мөрәҗәгать итте:

— Бу — сезнең укучыларымы? Ник шул кадәр сүгенешәләр?

— Авызларын ватасыңмыни аларның?! Сугышып кына китмәсеннәр инде! Бәргәләшә башласалар, — диде дә ул, чалбар балагыннан озын резин таяк, тагын нindидер «коткару коралы» алып күрсәтте. — Син курыкма-а-а!

Аның сүләрендә дә иман ишарәсен сизә алмаганга Камәрия тәмам хафага төште. Машинага утырганнар арасында бер генә хатын-кыз җәмәгате дә, бер генә татарча сөйләшүче дә юк иде. Моңарчы да тормыш кыенлыкларыннан, башка затларга таянмыйча, чыга килгән Камәрия бу көнне ничек тә исән-имин үткәрүне бары үзенә генә тапшырды. Ризыклар салынган букчасын аяклары арасына кыстырды, терсәкләрен машина тәрәзәсенең төбенә терәде дә, пыяла аша күренгән манзарага шаккаткандай, өнсез калды.

Машина дигәннәре чөгендер басуына шактый ара калдырып тукталды: «Ары үтеп булмый», — диде шофер. Кырыклап малай-егет арасында Камәрия дә җәяүләп китте. Көзге җир дымлы. Бер-ике адым китүгә, аяктагы итеккә авыр саз ябышты. Тиз барулар кыенлашты, малайлар исә элдертә генә. Авызларында — тәмәке, кулларында — сыра банкасы, телләрендә сүгенү. Кирәккәндә дә, гел хаҗәте булмаганда да, ике сүзнең берсендә — «анаңны» да «анаңны». Әле анысы да — урысча. Кая барып бәрелергә, кемгә сүз кушарга, нинди күләгәдә тын алырга белми интекте Камәрия. Малайлар исә, аның бичараланганын сизеп, басуда да һаман ыржая бардылар. Йолкырга алынган буразналары буйлап бер генә карыш алгарак китсәләр дә, Камәриянең азрак артталыгын чамалап: «Э-э-э-й, бабуля, ник ялкауланасың, синең өчен без эшләмәячәкбез бит!» — диләр дә барысы бергә коточкыч тавыш белән шаркылдашалар.

Малайлар эшне алай-болай гына сыдыртып бара иде. Камәрия исә кечкенә генә чөгендерне дә исраф итмәскә тырышып, бик бирелеп эшли, шунлыктан әллә ни алга ыргылып китә алмый. Моңа хафаланмый да иде ул, тик әнә шул малай-шалайның мәгънәсез шаяртуына гына эче поша, биниһая гарьләнә иде. Буразнаның башына чыгып җиткән малайлар, гәрчә алар артыннан өр-яңадан җыярлык чөгендер түмәрләре калган булса да, үзләрен бөтенләй чыгырдан чыгардылар, теләсә кемгә яман сүз аталар, бигрәк тә Камәриягә, арадагы бердәнбер кызга, иң өлкән кешегә телгә алмаслык ямьсез сүзләр яудыралар. Әлеге дә баягы: ике сүзнең берсе — урысчалап, аналар каберен мәсхәрәләү, хатыннарның җенесен кимсетү...

Камәрия, чарасызлыктан, боларның берсен дә исәпкә алмаска булды, башын җүләргә салды. Белә иде бит ул: малай-шалайның күбесе — исерек, ә бездә «Исереккә бирмә сәлам, ул бирсә дә син алма!» — дигән мәкаль бар. Икенчедән, алар әле бик яшь, үзләренең сүз байлыкларын да, көч-куәтләрен дә кая куярга белми интегәләр. Тиешле тәрбия бирелмәгән, үзлекләреннән гыйбрәт ала алмаганнар — нишләтәсең инде аларны?!.

Һич уйламаганда, буразналар башыннан моңарчы гүләп торган тәрбиясез сүзләргә караганда да яманрак авазлар яңгырады. Ул да түгел, әлеге сүгенүчеләр төркеме, бөтенесе бер булып, чөгендер басуының аргы, эш башланган очына ыргылды. Телләрендә ни генә юк?! Ул сызгыру, кычкыру, янау галәмәтләренә һич чыдап торырлык түгел. Камәрия борылып карарга мәҗбүр булды. Караса, шуны аңлады: алар калдырып киткән букчалар янына бер көтү эт барып ябышкан. Әллә авылның андый-мондый кагыйдәгә өйрәтелмәгән этләре инде, әллә хуҗаларыннан аерылып киткән шәһәр бичаралары. Дистәгә якын, эреле-ваклы этләр, мөгаен, ашарга эзләп бу тирәгә килеп чыкканнардыр да әлеге мәгънәсез «чөгендерчеләр»нең букча тирәсен чамалап алганнардыр.

Ач хайваннардан да болайрак ямьсез кыйланып, әллә нинди кыргый авазлар салып йөгерешкән малайларны күреп, этләр бик тиз читкә ташландылар. Камәрия бу тамашаны үзе йолкый торган чөгендер буразнасының аргы башыннан гына күзәтеп торды. Аннары кабат буразнага бөкерәйде.

— Әбекәй, анда... синеке, бугай, бер букчаны тәмам ерткалап киткәннәр, акча янчыгы да, ачкычлар да чәчелеп ята... — дигән тавышка Камәрия сынын турайтырга мәҗбүр булды.

...ә-ә, ни дисең?
...вап бирүче булмады.
...хәбәр китергән ма-
...лләә кая китеп барган.
...рия билен турайтып,
... тамак ялгар вакыт
...н дә исенә төшереп,
...ларын салып килгән
...сын калдырган якка
... Анда инде этләр
...арып килсәң дә ярар
...Термоста чәй дә бар
...ле
... бурaзнаның чигенә
...алды, азрак ял итеп
...н соң, эшнең түгәрәк-
...нә ышанды һәм тә-
...ләп, тамак ялгарга
...әде Аларның әйбер-
... саклана торган урын
...ый ераклыкта иде.
...ак кына барды ул.
...й-уйлый барды Ике
... булса да чөгендер
...айтырга иде мон-
...йл өметләнде. Гаҗи-
... шифаханәсенә шу-
...п илтсәң, иң файда-
...късдар булачак бит.
... килмәсәң, шундый
...әгендерне кайдан та-
...дең әле?! Базарда да
...чә кон тотылганны
...туры китерергә мөм-
...у бит — җир куенын-
...а гына суырып алы-
...өгендер.
...еп җитте Монда дө-
...ң асты өскә әйләнде-
... Аның җиңел генә
...ы, читкә тибәрелеп,
... ташланган, эчендәге
...әкләре дә, ипи те-
...-дә этләр тара-
... ермачланып бет-
...р якта — күзлек та-
..., икенче тарафта
...нчыгы ята...
...ил әле монда! Тер-
...ны мин алдым...
...ат коры яңгыраган
... Камәрияне, өме-
...рүдән бигрәк, сискә-
... җибәрделәр. Игъ-
...тсә, әйберләр куел-
...рдән читтәрәк, кар-
...на тал-тирәкләр ар-
... әлеге малайларның
...ы, Камәриягә тупас
...дән тегелгән бияләй
... «җитәкче» утыра
...арсак, ябык, сары
... кысык күзле...
...л әле! — диде ул.
...ндәвендә нindидер
...ь тә, миһербанлык
...лми иде. Шуңа да
... аны тагы да
...дырмаска тыры-
...быр гына үз сүзен
...
...ә, юк, ярый, этләр
...шлаган икән...
...л диләр сиңа! Кил!
...әрсәң монда.
...чек? Минем бөтен
...е этләр ашап бете-
..., калганнарын җы-
...ым: ачкычларым,
...ыгым, барысын да
...
...шылыкны аңлама-
... «Җитәкче», ук бу-
...лып, Камәрия яны-
...е дә аны тирәкләр
...гы үз «утарына»
... — Аңладыңмы
...
...рсәне аңларга ти-
...? — Камәрия бу
...ең юньлелеккә ба-
...н чамаласа да,
...ы сизмәмешкә са-
... яманлыктан коты-
...ятләде.
...инем монда бер
...ар, шуны сынды-
..., чит ил фильмна-
...ча, мәхәббәт бе-
...ыльләнеп алабыз!
...?! Аңладыңмы ин-
... каршы сөйләгән-
...ратмыйм. Махсус
...ым, малайлар бе-

Бу кадәр ачыктан-ачык әйтмәсә дә, Камәрия әлеге бәндәнең ниятен сиземләгән иде инде Юньлелеккә эндәшмәвен бөтен вөҗүде белән тойган иде Әмма ул, шушы яшенә җитеп, инде тагын бер-ике елга түзсәм, пенсиягә чыгам, дип йөргән дәверендә, үзен шул дәрәҗәдә мәсхәрәләрләр, дип уйламый иде

Камәрия, күңеленнән шул соңгы чиккә җитәчәк биниһая күңелсез мизгелгә әзерләнде Әмма хәл, ул фаразлаганга караганда, мең мәртәбә катлаулырак булды. «Җитәкче»нең йөзе-күзе бурлаттай кызарган, авызыннан селәгәе ага, борыны юеш, кулларына карарлык түгел — бармак аралары сазланып каткан, сыяудай тырнаклар астында — бер батман туфрак. «Йа, ходаем, шушы бәндә белән юри генә дә иплә п сөйләшү мөмкин түгел бит инде», дип уйланды Камәрия. Тик аның башка чарасы да юк иде шул.

— Ачыктырды, — дигән булып, тегенең кырына иплә п кенә килеп утырды ул.

Әлеге адәм мәсхәрәсенең табынында бер-ике кыяр кисәге, ипи кыерчыклары, Камәриянең термосы һәм яртылаш эчелгән аракы шешәсеннән башка ризык күренмәде.

Ул үзе, табынының хәерчелеген чамалар хәлдә түгел:

— Әйдә! — дип өндәде.
— Аша! Эч!

— Бик сусадым. Термоста чәй калган булса...

— А-а! Юк инде, монда чәй эчеп маташмыйбыз, мәйдән башлыйбыз!

— Мәүлет ае бит, — дип котылмакчы булды Камәрия. — Миндәй мөэмин-мөселманнарга килешмәс!

— Безнең ниндидер мәүлетләрдә катнашыбыз юк, чәйдән түгел, мәйдән башлыйбыз, яме?!

Әлеге бәндәне мөмкин кадәр ачуландырмаска тырышты Камәрия, шулай да аракыдан баш тартты.

— А-а-а, юк инде,юк! Монда миңа каршы килергә ярамый, каплыйбыз бере!

Камәрия термос капкачына салынган укшытырлык аракыны кулына алмый булдыра алмады. Аңа арадагы мөнәсәбәтләрне мөмкин кадәр тыныч хәл итә бару кирәк.

— Ярар, — диде ул һәм уенга бирелде. — Алайса, матур гына бер теләк әйт. Кавказ халыклары, бер йотым шәраб эчкәнче, ярты сәгатьлек нотык тота. — Әйт бер матур теләк!

— Сиңа тагын да берәр нәрсә кирәкмиме, .. мать! Капла да куй, аннары мин сине каплыйм!..

Бу коточкыч җанварның күзләре алаланган, куллары, тезләре калтырана иде инде Аннан ни шәфкать, ни мәрхәмәт, нинди аңлашу көтәсең?! Ул, шул ачы хакыйкатьне аңлап, тәмам өметсезлеккә бирелде Бу оятсызның карашы тонган бер мизгелне сайлап, Камәрия купындагы аракыны җиргә каплап куйды.

— Нәрсә, чөмердеңме? — Аның тавышында кыргый тантана яңгырады. — Менә-ә-ә, шулай! Хәзер — «лап та лоп» ясыйбыз! Килештекме? — Мин моны иртә таңнан ук чамаладым инде — чөгендергә берәр хатынны җибәрүләренә өметем дә юк иде.

Ул яньчек кружкасын авызына каплады. «Хәзер, хәзер, хәзер», — дип тәкрарлады. Әйтерсең лә аның вәхшилеген көтеп торучы бар?! Камәрия, бичара, аның тагын нинди яманлыклар кылуыннан гаҗизләнеп, кымшанырга да кыймыйча, алдагы мизгелләрдән мәрхәмәт көтте. «Йа, бер Ходаем, бир сабырлык!»

— Артыгын чишенеп торыш юк! — дип боерды «җитәкче». Аның теле көрмәкләнгән, кул-аяклары үзенә буйсынмыйлар иде инде. — Син, ни, давай, чабуыңны күтәр, миңа әллә ни эш калдырма, яме-е, э-э, хәзе-ер...

Моның тәмам хәлсезләнүен аңлап, Камәрия сикереп торды да, мөмкин кадәр еракка рак атылмакчы булды, тик теге хәсис, үзе ярым үлек хәлендә булса да, җенси азгынлыгын көчкә җигеп, Камәриянең сазлы итәкләренә очып кына кунды. Шул ук сазга буялган куллары белән Камәриянең алма-битләренә кагылды, тутыккан тимер кебек бармаклары белән аның әлегәчә ир-ат назы тоймаган гәүдәсен тырмачлады.

Камәрия, бу бәндәгә үз сафлыгын мәңге бирмәслеген бик тирәннән аңлаган хәлдә: «Ярый да кияүгә чыкмаганмын әле!» дип, үзен тынычландыргыч бер фикер дә эзләп өлгерде. — Бу хөкүмәт эшеннән арып кайткан ничәмә-ничә хатын шушындый исерек җаннар тарафыннан мәсхәрәләнеп яшәргә мәҗбүр бит инде ..» Әмма Камәриянең фәлсәфи тынычлануы күпкә алданрак бупып чыкты Ул үз хәленең ни дәрәҗәдә мөшкелләгән чамалап бетермәгән иде әле, бу аяусыз хәлдән бер чара табу өметен көтеп

— Тукта инде! — диде ул — Сабыр ит! Үзең әйтмешли, мәхәббәт белән шөгыльләнергә, бераз аңлашу да кирәк ләбаса!

— Ә-ә-әй, ул шартлар каһәр суккан капиталистларныкы гына бит Бездә андый шартлар куелмаган һәм куелмас та! Аналарын орам мин ул капиталистларның!..

Камәрия бу бәндә кулында ниндидер адәми зат түгел иде инде. Аны хәзер ботарлап ташлаячаклар.

Ярты акыллы исерек ирнең авызыннан бөркелгән сасы сулыш Камәрияне укшыта ук башлады, бу җанварның кәрәктәй куллары, имән казыгыдай тезләре моңарчы бер ир заты белән дә якын мөнәсәбәттә булмаган гәүдәне, уып-ватып, кара җиргә сеңдерергә әзерләнде. Бары тик калын тукымадан, биге артка куелып тегелгән чалбар гына бу җаһилнең җинаятен тыя торды.

Шул чалбар бигеннән башка ярдәмчесе юк иде инде Камәриянең. Фикерен юктан барны табардай чараларга юнәлтеп карады. Исенә төште. Аларны — бик кечкенә укучы балаларны — борчак кырына йөрткәннәр иде. Бөртек коелмасын өчен, борчакны кул белән генә йолкырга куштылар. Мәктәп балалары да чыкты. Авыл хатыннарының иң әрсез саналганы Маһирә апа Камәрия белән күрше рәткә туры килде. Аның икенче ягында исә Маһирә ападан да өлкәнрәк бер хатын эшли иде. Алар, яннарында ир-хатын мөнәсәбәтләрен бөтенләй белмәүче кыз бала барын чамалап та тормадылар, үз хәсрәтләре белән уртаклаштылар.

— Бригадир Исмай килде кичә, әй кыса, әй бирелергә кыстый, — ди берсе.

Икенчесе, Маһирә апа, тегеңә акыл өйрәтә.

— Малакаем, бергә-бер генә булганда, котылып калырга була. Теге нәмәрсәсен учлап кысасың — үрле-кырлы сикерә...

Әллә нинди фаразлар үтте Камәрия башыннан. «Көчләү-көчләнү» хафасыннан ничек котылу чараларының бөтен әмәлләрен башыннан кичерде ул. Хәзер, шәрран ярып: «Мине көчлиләр, коткарыгыз!» — дисәң, тирә-юньдәге малайлар бөтен дөньяны көлкегә саптырачак. Иллегә баручы ни хатын, ни кыз кешене кем «көчләсен» инде?!

Ул арада әлеге исерек «җитәкче» белән ике арадагы тарткалаш кискенләшкәннән-кискенләшә барды.

— Ну-у-у, бераз булыш, ... мать! — дип Камәрия колагына пышылдады көчләүче ир. — Мин дә җан иясе бит! Хәл юк...

— Нәрсә кирәк соң сиңа? — дигән булып, Камәрия сорауны арткарак сузмакчы булды — Мин бит аны-моны аңламыйм .

— Аңлыйсың! Твою... Йомшар бераз, селкен, агач кебек катма!

Камәрия хәйләгә керешөте

— Ярар, ярар, — дигән булды. — Хәзер чишенәм ..

— Чишенүеңнең ике тиенә — бер бакыр, менә бу чалбарыңны гына ычкындыр син!..

Камәрия үз гомерендә бер генә егетне яраткан иде. Бер күрде дә — кабынды Егет тә аңа игътибарсыз түгел иде, гик, озак тормыйча, аны Мәскәүдән килгән бер марҗа үзенә каратты. Камәрияне мәңге ялгыз итте Марҗа коткысына бирелгән егет Камәриянең бер хыялый ымсынуы булып кына калды. Башкалар исә аның күңелен кузгата алмады, ә, соңра, балаларыннан, ирләреннән җәфа чигүче хатыннар Камәриягә ялгыз яшәүнең дөресрәк икәнлегенә инанырга гына ярдәм иттеләр.

Касыгына терәлгән каты тезләрне һичничек өнәмичә, Камәрия кабат сүз белән котылмакчы булды

— Туктале! — диде. — Аңлашыйк, сөйләшик!..

— Нинди сүзләр кирәк сиңа, давай, булыш!.. — Ул үзе, әле Камәриянең битенә сыланып, әле тезләренә ышкылып адәм баласы күңеленә һич кенә дә рәхәтлек китерә алмастай хәрәкәтләр ясады. — Ә-әйдә... — ди дә селәгәйле авызы белән Камәриянең чит илдән кайтартылган майлар белән шомартылган битенә селәгәен сылый, аннары, пычрак тырнаклы куллары белән бичара карт кызның тезләренә-ботларына ябыша.

— Син, нәрсә? Ник җүнләп үбешмисең? Агачмы әллә син? — «Җитәкче» хәтта акрынлап аңлый да бара иде. Ул Камәрия чалбарының «сер»ен эзли, тәмам үз теләгенә ирешергә маташа иде.

— Туктале-е! — дигән булып Камәрия вакытны сузмакчы булды. — Мин бит...

— Монда син юк! Монда — мин генә!

Пычрак куллар Камәриянең изүен аерып ташлады, аның авызын каплады, аннары, җентекләп, чалбарның кайда каптырылганын капшый башладылар. Изелде, сытылды Камәрия. Әйтер сүзе, кылыр гамәле калмады. Шәрран ярып кычкырсаң да, теге малайлардан шәфкать күрүгә ышаныч юк. Инде авылдашы Маһирә апаның «сере» дә ярдәм итәрлек түгел, чөнки Камәрия бу ямьсез кеше белән «ризалашкан» булып кыйлана алмый. Юк. Бетте бөтен «тәҗрибәләр» Ул бары шушы минуттагы көченә генә гаяна ала иде. Тотты да типте тегеңә Өметләнмәгән иде. Теге ябык, сары бәндә тәгәрәде дә китте яһәннәм чокырына. Шул мизгелдән файдаланып, Камәрия тиз генә әйберләрен җыештырды, кулына эләккән ике чөгендерне алып, кесәләренә тыкты да машина юлына чапты

(Ахыры бар).

● Хөсәенова Динара.



● Әхмәтшина Алсу, Әхмәтшина Гүзәл.

● Гыймадиева Гөлназ.

● Хәйруллина Дилбәр.





БАЛАЧАКНЫҢ БАЛИГЪ УЙЛАРЫ

Хәтәр килә, хәтәр китә, хәтер кала

Казан каласының Яңа Савин районындагы 85 нче мәктәп-гимназия шәкертләре Хәтер көненә багышлап инша язганнар иде. Һәр инша — Казан каласын вәйран иткән, аны канга батырган Явыз Иванга карата тирән нәфрәт, татар халкының үткәннәре һәм бүгенгесе өчен чиксез горурлык, милли телгә һәм мәдәниятка карата гаҗәеп зур мәхәббәт белән сугарылган. Балаларның әлеге иншаларын һәм рәсемнәрен редакциягә татар теле һәм әдәбияты укытучылары Роза Әхмәтшина һәм Фаилә Мөхәммәтҗанова алып килде. Ошбу сәхифәдә сезгә иң яхшы дип табылган иншалардан алынган өзекләрне һәм рәсемнәрне тәкъдим итәбез.

«Казан каласын саклап һәлак булган сугышчыларның батырлыгын күреп, хәтта Явыз Иван да таң калган. Шуңа күрә дә ул, татар халкының бик озак еллар каршылык күрсәтәчәген аңлап, буе тәгәрмәч көпчәгеннән узып киткән барча ир балаларны да үтертеп, Казан суына салган Урыс патшасының бу вәхшилеге бездә — татар балаларында һәрвакыт нәфрәт хисе уята.

Динара ХӨСӘЕНОВА,
YIII сыйныф укучысы».

«15 октябрь — татар халкы тарихында иң аяныччы көн. Явыз Иван Казан каласын вәйран итә алса да, татар халкының рухын сындыра алмаган. 1990 елдан башлап, без, ниһаять, үзебезнең дәүләтчелегебезне торгыза башладык. 443 елга сузылган коллык һәр татар баласы өчен гыйбрәт булсын. Мәскәү әле бүген дә башка халыкларны буйсындырып, талап яшәү сәясәтен алга сөрә. Чечня — моңа бер мисал. Уяу бул, татар кешесе!

Гүзәл ӘХМӘТШИНА,
YII сыйныф укучысы.
Алсу ӘХМӘТШИНА,
IX сыйныф укучысы.»

«Хәтер көне... Аллага шөкер, ничәмә-ничә гасырлардан соң татар халкы үзенең каһарманнарын зурлап искә ала. Дөрес, без ата-бабаларыбызның батырлыгына элек тә соклана идек. Ләкин ул чакта Матәм көнен үткәрү һич мөмкин түгел иде. Чөнки Я... Иван уку әсбапларында Русия и... ясенә нигез салган алдынгы кара... патша буларак сурәтләнә иде. Хә... инде без аның нинди «алдынгы кара...лы» патша булганлыгын бик яхшы ...ләбез. Гап-гади башкисәр икән г... са.

Быелның октябрь аенда Каз... узган Хәтер көнендә мин дә катн...тым. Күр, уяна бит халык, уяна!

Гөлназ ГЫЙМАД...
YII сыйныф укучы...

«Киләчәк буын әби-бабаларыбыз т...ле үк саф татар телендә генә сөйл... башлар, дип уйлыйм мин. Минем ... әбием кебек Казан урамнарында ... яулык бәйләп, читек киеп йөрисем ...лә. Ә мәркәзебез урамнарында т... төйлә малайлар, ак яулыклы кы... көннән-көн күбәя бара бит. 15 окт...рьдә Матәм көнендә булып кайт... мин Казан каласын саклаганда һ... булган ата-бабаларыбыз тоткан к...ладан тайпылмаска ант иттем. Т... булдым, татар булып калачакмын

Дилбәр ХӘЙРУЛЛИ...
YII сыйныф укучы...

«Исәннәрнең кадерен бел, үлгән...нең каберен бел, балам», — д... минем әбием. Һәм мин аның ...ләре белән килешәм.

Шуңа күрә дә мин 15 октябрьдә ... кызларым белән Казан Крем... ашыктым. Бу Хәтер көне мәңге исе... калыр. Ул көнне мин никтер гел ч... халкы язмышы турында уйлан... Алар бүген үз бәйсезлекләрен са... калу өчен граната белән урыс т... астына ташланалар. Мин бу гору... лык белән чиксез горурланам. Бе... ата-бабаларыбыз да Казан ханл... әнә шулай үз-үзләрен аямыйча са...ганнар бит

Гөлназ СОЛТАНО...
YII сыйныф укучы...



Икмәк, җыр һәм китап...

Әле кайчан гына партиянең махсус идеология бүлекләре эшли иде Кешенең аңын агарту шушы бүлекләр аша алып барылды Бүген партия дә идеологик тәрбия дә юк Хәзер барлык эшләр республика район авыл мәдәният хезмәткәрләре өстендә Юбилейлар Сабантуйлары бәйрәм көннәре шушы тынгысыз җаннар тарафыннан баштан ахырына кадәр оештырыла Ә бу чаралар зур осталык сәләт таләп итә Безнең Кама Тамагы районында үз эшләренә ихлас бирелгән кешеләр уңганнар байтак Кләнче мәдәният йорты директоры К Нәҗмиева Каратай мәдәният йорты директоры Т Яруллина сәнгать җитәкчесе И Фәйзуллина, Олы Салтыктан сәнгать җитәкчесе Г Садыйкова Балтачтан мәдәният йорты директоры Р Гатауллина әнә шундыйлардан

Авыл мәдәнияте тирә-юньдәге кешеләр катнашы белән генә яши ала Һәр төбәкнең үз осталары җырчы-биючеләре, нәфис сүз осталары бар Без аларны үзебезнең дусларыбыз дип саныйбыз Район элемтә бүлекчәсе урынбасары А Айтуганов янгын сүндерү часте хезмәткәре Ф Йосыпов, саклык банкыннан А Алиәкбәрова һәм башка бик күп сәнгать сөючеләр белән көчле без

Райондагы җитмешләп мәдәният йорты музыка мәктәпләре китапханәләр клублар һәм утызлап киноҗайланма авыл эшчәннәренә хезмәт күрсәтә Шунысын да әйтергә кирәк быел районда ике мәдәни учак берләште район киночелтәре мәдәният бүлеге карамагына күчте Бу — икене бер итеп финанс хәлен яхшыртуны күздә тота Ләкин мәдәниятебез акча кытлыгы кичерә Ярый әле кайбер хуҗалык җитәкчеләре бу хәлне яхшы аңлыйлар һәм мәдәният биналарын төзекләндерүдә, кышка әзерлек күрүдә ярдәм итәләр

Районыбыз калалардан шактый ерак торса да, авыл халкы сәнгать, мәдәният яңалыкларыннан, сәхнә әсәрләреннән читтә калмый Авылларда даими рәвештә теге яки бу театрның, сәхнә йолдызларының гастрольләре була Халыкка танылган сәнгать коллективларын без үзебез дә чакырабыз Мәсәлән, Казанның Сәетгалиев исемендәге мәдәният йортыннан якташыбыз Рәис Сафиуллин җитәкләгән халык фольклор ансамбле чыгышын районыбызның байтак авылларында карадылар. Һәр җомга, шимбә кичекарамалыларга, бәрлегуҗалыларга, көрәлеләргә, балтачлыларга бәйрәм конен хәтерләтте.

Кама Тамагы районы республикабызга бик күп күренекле кешеләр бирде Шуларның берсе — драматург Туфан Миңнуллин Якташыбызга 60 яшь тулды Бу уңайдан мәдәният йортларында, китапханәләрдә очрашулар, сөйләшүләр, әсәрләре буенча фикер алышулар булып узды Авыл халкы күргәзмәләрдә аның китаплары, көндәлек матбугатта донья күргән әсәрләре белән танышты.

Китапханә, клуб хезмәт...ләренең белемен күтәрү ... зеннән район мәдәният й... каршында һәм Красно... китапханәсендә даими р... тә семинар-уку үткәрелә ... тәҗрибә туплаган китап... ләрдә, мәдәният йортла... күргәзмә эш оештырыла ... дәният заманнан артта к... сын өчен башка гамәли ... лар күрелә

Әйе, мәдәниятне бор... мәсьәләләр күп бүген ... ил күләмендәге икътисад... яси хәлләрне уңышлы х... кәндә, мәдәниятебез чит... лмас дип ышанам Чөнки ... дә яши торган адәм бал... икмәк белән бергә җы... музыка да яхшы китап... милли нәфис фильмнар ... рәк Халыкның рухи бай... саклый белгән ил генә ... яктан да бай була ала

Әлһап ХӘЙРУЛ...
Кама Тамагы райо... мәдәният бүлеге м...

Сакләбиләр патшасына

әл-Мөктәдирдән илче булып барган Әхмәд ибне Фазлан китабы

(Борынгы текстны СОЛТАН ШӘМСИ эшкәртте һәм тәрҗемә итте)

(Дәвамы. Башы 16-17 нче саннарда).

Чыннан да, миңа шундый бер вакыйга сөйләделәр: көннәрдән бер көнне ике ...ше дөяләр җигеп урманга утынга дип китә. Тик шулай килеп чыга, икесе дә чакма ташы белән мамык алырга оныталар. Шуңа күрә аларга төнне учак якмыйча чыгарга туры килә. Иртәгесен күзләрен ачкаңда дөяләр инде катып үлгән була. Дөрестән дә, миңа суыктан зеңләп торган һаваны үз күзләрем белән күрергә туры килде, андый көнне базар да, урамнар да тәмам бушап кала. Мунчадан чыгып өйгә кергәч, күп тапкырлар сакалыма күз салганым булды — ул кардай ак бәс белән каплана иде. Ул мин учак янына килеп утыргач кына эри торган иде.

Дөрестән дә, миңа анда көннәр буе өйдә утырырга туры килгәләде, өй эченә төрек киезләреннән ...ыелган тирмә дә куелган. Мин ул тирмә эчендә төрле киемнәргә ...ренеп, өстемә мехлар ябынып ...ыруымны беләм. Шулай да яңак...рым салкын мендәргә ябышкан ...ла. Бервакыт сарык тиреләре ...н капланган сулы савытлар...ың суыкта катып, төнлә шартлап ...ылуларын күрдем. Димәк, җы...ытуның да файдасы тимәгән. Мин ...улай ук суыктан җирнең ярылу...н, анда тирән эзләр хасил булу...н, карт агачның икегә аерылуын ...рдем.

Ниһаять, 309 ел шәүвәл аеның ...тысы үтү белән һавалар үзгәрә ...шлады, Җәйһүн елгасында боз ...еде, без сәфәр хәстәрен күрә ба...ладык. Төрек дөяләре сатып ал...ык, төрекләр җирендә очраячак ...галарны кичү өчен дөя тиресен...н капчыклар тегәргә куштык. Өч ... җитәрлек икмәк, тары, кипте...лгән ит хәзерләдек. Безнең бе...н аралашып-дуслашып яшәгән ...ирле халыктан кирәкле киемнәр ... буда ярдәм итүләрен үтендек. ...лардан шушы сәфәр өчен күпме ...ем-салым алырга кирәклеген бе...еч, шаклар каттык. Чынлыкта ...ә безгә кием-салым тагын да кү...әк кирәк булып чыкты.

Нәтиҗәдә, һәркем өстендә курт..., аның өстеннән кафтан, аның ...теннән тун, башыбызда киез бү...к белән башлык — кыскасы, ике ...ебез генә күренеп тора. Өстәве..., бездә юка һәм ике катлы итеп ...гелгән чалбарлар, озын балтыр... оек, йомшак тиредән тегелгән ...тек, аның өстеннән итек — бо...й кешегә дөя өстендә барулары ...к кыенга туры килә, чөнки кый...ылдап та булмый. Шул сәбәпле, ...знең белән Мәдинәт әс-Сәлам...н сәфәр чыккан кешеләрдән фә...йһ, могаллим һәм байтак углан...р, ят илдәге юл газапларыннан ...ркып, аерылып калдылар.

Юлны мин үзем, илче, аның ба...сы һәм дә ике углан — Тәгин ...лән Барс дәвам иттерергә бул...ык. Юлга чыгар алдыннан мин ...арга болай дидем:

— Җәмәгать, тыңлагыз! Сезнең ...н болгар патшасы вәкиле бер...ән да бара. Ул бөтен эшләрне ...лә. Кулыгызда хәлифә хәзрәтлә...нең хаты, анда болгар патшасы... тәгаенләнгән дүрт мең мусәййә... динарлары хакында да сүзләр ...пуына һич шигем юк. Сез чит ...тша хозурына килеп баскач, ул бит сездән ул акчаларны таләп итәчәк.

Юлдашларым миңа:

— Син борчылма. Ул бездән акча таләп итмәскә тиеш, — диделәр.

Мин исә:

— Мин беләмен, ул аларны сездән барыбер таләп итәчәк, — дип, юлдашларымны тагын бер кат кисәтергә кирәк таптым.

Кәрванны юлга әзерләү тәмам булды. Җөрҗаниядән озата бару өчен без Фәлүс атлы бер адәмне ялладык. Аннары, үзебезне Аллаһ хөкеменә тапшырып, Җөрҗаниядән чыгып киттек. Бу хәл 309 ел зөлкагдә аеның икенче киче узгач дүшәмбе көн булды (922 елның 4 марты). Бераздан Зимҗан дип аталган рабатта тукталдык, бу Баб әт-Төрек, дип атап йөртелгән урын үзе икән. Икенче көнне сәфәрне дәвам иттердек, Җит дигән тукталышка барып җиттек. Шул вакыт көчле кар ява башлады, дөяләр тездән карга кереп баттылар.

Анда ике көн тукталып торганнан соң төрекләр җиренә аяк бастык. Шулай, берничә дә карамастан, төрекләр иленнән бардык, таусыз-нисез буш далада безгә берәү дә очрамады. Шулай ун көн бардык, юлда безгә байтак кыенлыклар, бәла-казалар очрап торды, көчле суыклар мул кар явулар белән алышынды. Болары белән чагыштырганда, Харәзем салкыннары җәй генә булган икән! Без хәтта тирә-юньдә ниләр барын да күрмибез, чөнки җаннарыбыз үлем каршына ук килеп баскан иде.

Шулай берничә көн рәттән көчле суыклар торды. Тәгин минем янәшәмдә бара, ә аның яныннан барган төрек тегенең белән үз телендә нидер сөйләшә. Менә Тәгин кинәт



● Болгарда халыкара базар (Ага базар).

Канәфи НӘФИКОВ рәсеме.

көләп җибәрде дә миңа борылды:

— Тыңлале, бу төрек сиңа әнә нәрсә ди: әфәнде бездән ни таләп итә соң, ди. Ул безнә катырып үтерә бит инде, әгәр дә без аңа ни кирәген белсәк, һичшиксез үтәгән булыр идек, ди.

Мин Тәгингә:

— Әйт үзенә, мин аның «Лә иләһи илләә Аллаһ, Мөхәммәдер рәсүлуллаһ» дип әйтүен телим, — дидем.

Тәгин сүзләремне аңа тапшыргач, төрек көлеп җибәрде дә

— Өйрәткән булсалар, һичшиксез, әйтер идем, — диде

Аннан без ялга туктадык. Монда саксаул агачлары күп үсә иде Мин ботаклар сындырып алдым да учак тергезеп җибәрдем Юлдашларым җылындылар, киемнәрен салып киптерергә керештеләр Ял иткәннән соң кабат юлга чыктык Көн саен зур ашыгычлык белән төн уртасыннан кояш чыкканчыга кадәр юлда булдык. Аннары туктап ял иттек Аннан өйләгә кадәр тагын бардык һәм ялга тукталдык. Гел шулай бардык.

Унбиш көн баргач, биек кенә бер тау янына килеп чыктык, аның итәгендә чишмәләр күп иде Бу тауны аркылы чыкканнан соң төрекләрнең угыз кабиләсе яшәгән җиргә аяк бастык. Алар күчмә тормыш белән яшиләр, киез тирмәләрдә торалар һәм урыннарын еш алыштыралар икән. Тирмәләрен әле бер, әле икенче җирдә күрергә була.

Алар мәҗүсиләр икән. Адашып йөргән ишәкләр сыман, Аллаһка итагать күрсәтмиләр, акылга таянып эш итмиләр, берничә дә табынмыйлар. Ләкин картларны бик нык хөрмәт итәләр, аксакалларны аеруча олылыйлар. Берәрсе аксакалдан киңәш сорарга килгәндә:

— Аксакал, фәлән эштә ни кыла алам? — дип әйтә.

Мөһим һәм җитди эшләрен алар киңәшеп хәл итәләр. Әмма шунысы сәер: бер мәсьәләне инде хәл иттек, уртак фикергә килдек дигәндә генә арадан иң түбән дәрәҗәле берәрсе килә дә үзенең ризасызлыгы белән бөтен эшне харап итә дә куя. Миңа еш кына алар авызыннан: «Лә иләһи илләә Аллаһ, Мөхәммәдер рәсүлуллах» дигән кәлимәләрне ишетергә туры килгәләде. Шулай алар үз илләренә килгән мөселманнарга охшарга тырышалар, ләкин чын инану аларда юк. Берәрсе нинди дә булса бәла-казага юлыкса, башын югары күтәреп, күзләрен күккә терәп: «Бер тәңре!» дип ялвара башлый. Алар олы һәм кече йомышларыннан соң юынып тормыйлар, якынлык кылганнан соң да госелләнмиләр. Гомумән, алар юынмыйлар, ахры, кыш көннәрендә бигрәк тә. Хатын-кызлар ир-аттан яшеренми, төннәрен дә чит кешеләр алдында капламыйлар Дөрестән дә без шундый бер очракның шаһиты булдык ничек тер бер көнне, аларның берсендә тукталдык та, әңгәмә корып утырдык Ул кешенең хатыны да безнең белән иде Сөйләшеп утырган чакта хуҗабикә күлмәген күтәрде дә оят җирен кашып алды Без оятыбыздан йөзләребезне капладык «Йа, Аллаһ, кичерә күр!» дидек Аның ире көлеп кенә куйды да тылмачка.

— Әйт аларга. ул сезнең алда ачылды ачылуын, анысын үзегез дә күрдегез. әмма ул үзен шундый итеп саклый белә — берәүне дә якын җибәрми. Бу бит капланып йөреп тә берәрсенә бирелүгә караганда әйбәтрәк. Шулай түгелмени? — диде

Зина кылуны алар гомумән белмиләр Шулай да, берәрсе бу кыек эш белән тотылса, ике агачны бер-берсенә каршы бөгәләр дә, зиначының ике аягын ике агачка бәйләп куялар Аннан соң агачларны кинәт ычкындырып җибәрәләр, аны урталай аералар

Шулай бер көнне арадан берсе

— Коръән тыңлап карыйм әле. — дип үтенде. Мин көйләп укып күрсәттем.

Коръән тыңлау аңа шул кадәр ошады, ул тылмач аша миңа.

— Әйт, туктамасын, — диде.

Икенче бер вакыт шушы ук кеше тылмач аша миңа мөрәҗәгать итеп:

— Бел әле бу гарәптән, кодрәте чиксез Аллаһының хатыны бармы икән? — дип сорады.

Мин бу көфер сүзләрдән бик нык курыктым. Ходайдан ярлыкавын сорадым Әлеге адәм дә сүзләремне кабатлады. Гомумән, төрекләрдә шундый гадәт бар: әгәр дә берәрсе мөселман авызыннан Аллаһыны олылау кәлимәсе ишетсә, бу сүзләрне кабатларга тырыша.

Аларда өйләнү йоласы түбәндәгечә башкарыла: әгәр берәү кемнеңдер гаиләсеннән берәр хатын-кызны кодалый икән, ул кеше гаилә башына фәлән-фәлән кадәр харәзем киемнәре бүләк итәргә тиеш була. Шуны башкарганнан соң ул теге хатын-кызны үзенә алып китә ала. Кайчакта мәһәрне дөя, ат яки башка шундый нәрсә белән дә түлиләр. Тик берәү дә гаилә башы таләп иткән калымны түләп бетерми торып хатыны белән кушыла алмый. Калым түләнеп бетсә, кияү кеше, тартынмый-нитми аларның өенә килә дә, өйдәгеләр күз алдында кәләшен үз йортына алып кайтып китә. Һәм берәү дә аның теләгенә каршы килә алмый — атасы да, анасы да, кәләшнең абый-энеләре дә. Әгәр дә өй хуҗасы үлеп китсә, өлкән угыл атасының хатынына өйләнә ала — тик ул аның үз анасы гына булмасын.

(Дәвамы бар).

УРТАК ТАРИХЫБЫЗ

Явыз АКПЫНАР,
Төркиянең Эгей университеты доценты

Әдәбият тарихын бүгенге төшенчәдә карасак. төрки әдәбиятларны тулаем колачлаган һәм беренче мәртәбә аларның үткәнен. гыйльми һәм объектив рәвештә өйрәнә башлаган. бу әдәбиятлар мәйданга чыккан дәверне һәм аларның нинди шартларда барлыкка килүләрен. үзара багланышларын тикшергән беренче төрки галимнең мәрхүм Фуат Күпреле булганлыгын күрәбез.

Димәк ки. гомумтөрки әдәбият тарихы мәйданында яңа һәм аурупача төшенчәдәге әүвәлге тикшеренүләр Төркия төрекләре тарафыннан тормышка ашырылган. Хәлбуки. бу мәйданнарда яшәгән төрки кавемнәренең телләрен. тарихларын. халык әдәбиятларын өйрәнү Русиядә Төркиядәгедән күп элгәрәк гамәлгә ашырылган. Төркия Русиядә башкарылган эшләр белән бары шушы гасыр башларында гына чын мәгънәсендә танышырга кереште.

Бу җәһәттән башыбызга шундый бер сорау килә: «Русиядә төрки кавемнәр тарихы. теле һәм мәдәнияты хакында беренче әһәмиятле тикшеренүләр ясалганда. гомумтөрки әдәбият тарихы буенча хезмәтләр нигә шулай соңгарып дөньяга килгән?»

Моның җавабы урысларның төркиләр тарихына карашларында яшерелгән, дип уйлыйм. Алар төрки кавемнәр тарихы һәм мәдәниятенең бербөтен тәшкил итүен беркайчан да кабул итмәделәр. Чөнки андый караш аларның колонизаторлык сәясәтенә туры килми иде.

Урыслар башта Казанны, аннары Касыйм һәм Кырым ханлыкларын. Кавказны һәм Төркестанны басып ала башлаганда каршыларына чыккан кешеләргә. «мөселман». «татар» кебек гомуми исемнәр бирүләренә дә карамастан, һәр төрки кавемне мөстәкыйль халык итеп күрделәр һәм аларга кагылган тикшеренүләрне дә аерым халыклар хакында ясалган тикшеренү шикелле күрсәттеләр. Тел. халык әдәбияты һәм мифләре сыман тармакларда эзләнгән урыс галимнәренең бер өлеше мондый карашны уртаклашмаса да, гомуми рух үзгәрмәде.

Урысларның алда саналган төньяктагы ханлыкларны, Казакъстанны һәм Төркестанны . Кавказ һәм Әзәрбәйҗанны басып алулары игътибар белән өйрәнелсә, төрки кавемнәрне һәм ханлыкларны бер-бер артлы кулына төшергәндә, андагы идарәче нәселләр арасындагы каршылыкларны файдалануларын, алар арасында дошманлык чәчеп, җиңү һәм басып алуларын җиңеләйтүләрен күрербез. Шуның өстенә, шул замандагы төрле төрки кавемнәр арасында барлыкка китерелгән дошманлыкларның йогынтысы бүген дә дәвам итүен аңларбыз.

Урыслар XIX йөз ахырында да җирле милләтчелек аңының киңәюенә һәм тамыр җибәрүенә көч түкте. Бу сәясәт совет дәверендә тагын да эзлеклерәк үткәрелде. Аңа тәрәк биргән икенче бер нәрсә Көнбатыш мәдәниятен урыслар аркылы үзләштергән укымышлыларның үз тарихы тамырларын урыс һөҗүмнәре нәтиҗәсендә онытулары һәм кайбер зыялыларының үз мәдәниятләреннән ераклашуы булды Аеруча 1905-1920 еллар арасында кайбер укымышлыларның милләтчелекне кабиләчелек төсендә .кабул итүе урыслар эшен тагын да ансатлаштырды.

Шундый аңга ия кайбер укымышлыларның үз кавемнәрен караңгылыктан. артта калудан коткару. мәдәни бер югарылыкка күтәрү өчен белем-тәрбия алуга зур әһәмит бирүләре һәм моның өчен урыс алфавитын кулланулары мәгълүм. Чөнки аларча. гарәп алфавитын куллану уңайсыз иде. Болай уйлаган укымышлылар. хәтта, урыс миссионерлары һәм урыс зыялылары йогынтысында. газиз кавемнәренең артта калуын мөселманлыктан күрү хәленә дә җиткәннәр иде. Төркиләрнең алга китешенә урысларның яхшы ният белән булышачагына да өметләнәләр иде. Ибраһим Алтынсарин, Чукан Вәлиханов һәм Мирза Фатыйхгали Ахунзадә кебек шәхесләр әнә шундыйлар исәбенә керә.

Гаять көчле урыс басымын һәм йогынтысын кичергәнлектән, төрки кавемнәрнең теле һәм халык авыз иҗатлары буенча хезмәтләрнең Русиядә торган саен арта барган хәлдә, әлеге күп санлы һәм бай материалга таянып, аларны чагыштырып анализлау. уртак хәзинә итеп таныту. төрки әдәбиятлар һәм аларның уртак тарихын язу артта калган иде.

Бу эшнең гаҗәп бер үзенчәлеге әнә шунда ки. XIX йөзнең ахыры XX гасыр башларында сәясәттә төрекчелек һәм туранчылык төшенчәләре киң таралган һәм кабул ителгән шартта, Русия идарәсе астындагы төркиләрдә әдәбият тарихы буенча хезмәтләрдә шундый ук күренеш барлыкка килмәде. Бары тик җирле милли әдәбият тарихлары гына языла башлады.

Патша Русиясендә яшәгән, төрекче, туранчы буларак танылган кайбер укымышлылар күбрәк төркиләрнең милли тарихы уртаклыгын алга чыгардылар. әмма шушы принципны әдәбият тарихына да җәяргә өлгермәделәр.

Әдәбият тарихын тикшерүләрнең артта калуының тагын бер сәбәбе. һич шөбһәсез, әдәбият теориясенең җитәрлек үсмәвендә иде. Әдәбият теориясенә багышланган китапларның 1920-1930 елларда гына мәйданга чыгуы да нәкъ менә шушы хакыйкатьне раслый.

Зарури булган шушы көрәштән соң, әдәбият тарихы темасына әйләнеп кайтыйк. Гомумтөрки әдәбият тарихы мәйданындагы хезмәтләр Төркиядән соң башка төрки төбәкләрдә дә языла башлады. Аннары бер-бер артлы Әзәрбәйҗан, Идел-Урал (Казан) төркиләре, казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмән, каракалпак, башкорт, уйгыр һәм кырым-татар әдәбиятлары тарихына багышланган хезмәтләр дөнья күрде. Боларның иң зур өлеше совет дәверендә язылды.

Шуны да ачыклап китик: без монда. барлыкка килүләре һәм үсешләре бер-берсенә баглы булганлыктан, бары тик Ислам динен кабул иткән төрки кавемнәр әдәбияты хакында гына сүз алып барачакбыз.

Бу җәһәттән. урыс идарәсе астында яшәгән төркиләр эчендә яңа рухтагы беренче әдәбият тарихына баглы хезмәтләрнең Әзәрбәйҗанда языла башлавын күрербез. Кемнәрнең нинди әсәрләре кайчан басылуына күзәтү ясыйк:

Әзәрбәйҗанда аурупачыл мәгънәдәге тәүге әдәбият тарихын иҗат итүче Фәридун Күчәрле «Әзәрбәйҗан татарларының әдәбияты»н (1903 ел. урысча) һәм «Әзәрбәйҗан әдәбияты тарихы материаллары»н (1926-1927) нәшер иттерә; Абдулла Сур «Төрек әдәбияты тарихы» .(1908 ел), «Төркия төрекләре әдәбияты тарихы» хезмәтен бастыра. Йосыф Вәзирев (Й.В. Чәмәнзәминле) «Әзәрбәйҗан әдәбиятына бер нәзәр» (Истанбул, 1926), Сәлман Мөмтаз «Әзәрбәйҗан әдәбияты» (серия рәвешендә төрле китаплар; 1925-1926), «Ил шаирләре» (1927-1928), Әмин Абид «Әзәри әдәбияты тарихы» (Кулъязма, Истанбул университеты Төркият институты хәзинәсе. Истанбул, 1924), Исмаил Хикмәт «Әзәрбәйҗан әдәбияты тарихы» (Бакы, 1928),хезмәтләрен барлыкка китерәләр. Болардан Абдулла Сур белән Әмин Абидның Истанбулда укыганлыкларын һәм Әмин Абидның хөрмәтле Күпреле шәкерте булганлыгын искәртү урынлы булыр. Совет дәверендә язылган әдәбият тарихлары арасында иң зур күләмлесе — өч томлы «Әзәрбәйҗан әдәбияты тарихы» (1957-1960).

Шушында ук искәртеп үтүебез кирәк ки, совет дәверендә язылган барлык төрки әдәбият тарихлары аерым авторлар тарафыннан түгел, нигездә махсус тәгаенләнгән төркем тарафыннан иҗат ителгән хезмәтләр. Әдәбият тарихларының бер һәйәт тарафыннан язылуы, күбесенең «Фәннәр академиясе» тарафыннан күздән кичерелүе чынлыкта цензурадан уздырылуы хакында сөйли. Шунлыктан мондый хезмәтләрдә совет карашына ят төшенчәләргә һәм фикерләргә урын бирелми.

Идел-Урал төрекләренең әдәбият тарихлары арасында Г.Рәхим белән Г.Газизнең «Татар әдәбияты тарихы» (Казан, 1925) хезмәтен беренче телгә алу фарыз. Бу әсәр Надия Мәһмәт тарафыннан Төркия төрекчәсенә дә тәрҗемә ителә. Икенче әһәмиятле бер әсәр — Габдрахман Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (Казан, 1926). Совет дәверендә соңгы вакытта бастырылган иң күләмле хезмәт — авторлар коллективы тарафыннан язылган «Татар әдәбияты тарихы» (6 том, Казан, 1984-1989).

Үзбәкләргә килсәк, байтак әдәбият тарихлары арасында Габдрахман Сәгъдинең «Гамәли һәм назари әдәбият дәресләре» (Ташкент, 1925), Илбәкнең «Нәмүнә» (5 кисәк, 1925), Габделхәмит Сөләйман Чулпан белән Ашурали Заһириның «Әдәбият парчалары» (1926), Габделрәүф Фитрәтнең «Үзбәк әдәбияты нәмүнәләре» (Ташкент, 1928) бар. М.Салихов Бузрукның «Урта Азия вә үзбәк әдәбиятига умуми караш» (Сәмәрканд-Ташкент, 1930) һәм соңрак бер төркем галимнәр тарафыннан язылган «Үзбәк әдәбияты тарихы» (5 том, Ташкент, 1977-1980) иң әһәмиятле әсәрләр исәбенә керә. Болардан тыш аерым шәхесләр тарафыннан язылган һәм аерым дәверләрне яктырткан әдәбият тарихлары да бар.

Казакълар арасында бу эшләргә беренче булып Чукан Вәлиханов һәм бигрәк тә Ибрай Алтынсарин белән Әхмәт Байторсын тотына. И.Алтынсаринның «Хрестоматия» исемле антологиясе (1860-1870 елларда язылган) иң әүвәлге әһәмиятле әсәр буларак кабул ителергә лаек. Аннары «Казакъ әдәбиятының тарихы» (Алматы, 1948) һәм шундый ук исемдә ике томлык (Алматы, 1961-1965), М.Габдуллиның «Казакъ халкының авыз әдәбияты»(1958) һәм, ниһаять, Мөхтәр Әүтзевнең төрле хезмәтләрен санап китәргә мөмкин.

Төрекмәннәр арасында әдәбият тарихы хезмәтләре шактый соң барлыкка килә. «Төрекмән әдәбияты тарихы» (6 том, Ашгабат, 1975-1984) — арада иң күләмле бер басма.

Совет идарәсе астында булмаса да, уйгыр әдәбияты тарихларын да монда искә алырга мөмкин: Нурмөхәммәт Заманның «Уйгыр әдәбияты тарихы» (Шинҗәң), Гайрәтҗан Усманның «Уйгыр классик әдәбиятыннан тәзиз» (Шинҗән, Дашу нәшрияте, 1987), «Уйгыр совет әдәбиятының тарихы» (Алмута, 1986), С.Моллаудовның «XYIII гасыр уйгыр шигърияте» (Алмута, 1990).

Төрле төрки кавемнәр нәшер иткән әдәбият тарихларына һәм аларга якын мөнәсәбәттәге кайбер антологияләргә шушы рәвешчә тукталганнан соң, Совет дәвереннән элек һәм соңрак мәйданга килгән әдәбият тарихларын Фуат Күпреле күзаллавынча чагыштырып карарга мөмкин.

Күпреленең катгый фикеренчә, башлангыч дәвердә бөтен төрки халыкларның әдәбияты уртак булган һәм үзара тыгыз багланышта үскән. Алар соңга таба гына аерымлана, XIII-XIY гасырлардан соң гына, төрле сәбәпләр аркасында, язма тел буларак яңа төрки шивәләр формалаша һәм шул шивәләрдә әсәрләр иҗат ителә башлый. Төркиләрне өйрәнүче беренче урыс галимнәре дә шактый вакыт Төркестанны бербөтен әдәбият даирәсе буларак күрәләр һәм шулай сурәтлиләр.

Күпреле 1926 елда басылган «Төрек әдәбияты тарихы»нда: «Төрки әдәбият барлыкка килүеннән бүгенгә кадәр тоташ, үзара бәреккән бер сыйфатта гына үсми», дигәннән соң, 1911 елда әдәбият тарихыбызның «исбатлы» һәм
«гыйльми» бер юнәлеш
барлыкка китерелергә ти
шлеген бәян итә; төрл
«төрки шивәләр»дә ба
лыкка китерелгән хәзи
нең туплануын һәм аны
мәйданга килүен аңлат
кирәклеген белдерә («Т
рек әдәбияты тарихы
2 басма, Истанбул, Үтүк
басмаханәсе, 1980, 4 б.).
Ул шуннан соң мангу
дәверенә, угызларның зу
дулкын булып көнбатыш
күчүләренә дикъкать ите
сәяси һәм иҗтимагый хәят
тәге үзгәрешләргә анали
ясый; XIII-XIY гасырларда
соң көнчыгышта чагата
һәм харәзем әдәбиятлар
ның барлыкка килүен,
батышта госманлы
әзәри әдәбиятларын
мәйданга чыгуын төп үсе
үзенчәлеге буларак шәр
хли, тарихта әүвәл мәртә
төрки әдәбиятләр тупла
мын күреп, бу әдәбиятла
ны классификацияләр
тотына.
Әзәри һәм чагатай
биятларының нәрсә ик
леген шулай ук берен
булып аныклаган һәм
төшенчәләргә билгелә
биргән зат та Күпреле б
ды. 1910-1920 елларда
күренешләрне ачыкла
Күпреле бераз соңрак
лам энциклопедияс
әзәри һәм чагатай әдәби
лары хакында язган мә
ләләрендә сыйфатлама
рын тагын да камилләш
рә.
Ул гомумтөрки әдәби
ны өч дәвергә бүлеп
рый:
а) Мөселманлыкка
дәр; б) Ислам мәдәни
тәэсире астында; в) Аур
мәдәнияте йогынтысынд
Күпреле бу төп бүлен
эчендә төрки телләрн
тууын һәм ул телләрдә
әдәбиятларның үсешен
язган әдәбият тари
XY йөзгә кадәр, со
«Ислам энциклопедияс
нә язган әзәри һәм чагат
әдәбиятлары хакында
мәкаләләрендә XIX гас
ның соңына һәм өлеш
XX йөз башларына ка
колачлый, аларның
үзенчәлекләрен күрсә
Бу хезмәтләр киләчәк т
шеренүләргә нык нигез
ла һәм төпле анализ үр
гән бирә.
Соңрак, совет дәвер
дә язылган төрле төрк
лыкларның әдәбият т
ларында Күпреленең
әһәмиятле тәҗрибәсе к
кагылмый, файдаланыл
хәлдә исә галимнең хез
тәнә анык таянылмый.
Күпреле бу карашлар
язган чакта Әзәрбәйҗан
яңа әдәбият тарихлар
иҗат итү әле башлана
на, Төркестанда монд
эшләргә керешү өчен
байтак вакыт узуы ки
була.
1920 елларда Идел-Ур
төркиләре арасында да б
ренче әдәбият тарихы х
мәтләре күренде. Бола
социологик шаукым за
ры абайланса да, кайб
җәһәтләрдән Күпрел
сайлап алынды. Әйт
тарларга Төркестан әд
ятының тәэсире Күпр
чыгарган нәтиҗәләрне
ди бер рәвештә кабатла
кайтып калды.
Совет дәверендә ба
Төркестанның бер «Бо
шевистик дәүләт» булу

аршы чыктылар. Урыс мә-
фәгатьләрен күздә тотып,
у җирләрдә төрле этник
еркемнәр яшәвенә карап,
ынлыкта исә һичбер мил-
и-мәдәни чын чикләрне
анга сугып тормастан, ба-
ы сәяси максатларны гы-
а кайгыртып, әллә ничә
җөмһүрият барлык-
а китерелде.

Сәяси бүлгәләү артын-
ан мәдәни һәм тарихи бү-
гәләү дә килде, гомум Тө-
кестан әдәбияты төсендә
абул ителгән чагатай әдә-
ияты башта үзбәк, анна-
ы казакъ, каракалпак,
ыргыз, төрекмән һәм та-
ик әдәбиятларына ясал-
а рәвештә таркатылды.
лки мондый бүленеш ки-
чәктә үзеннән-үзе да ба-
ыкка килгән булыр иде.
әкать урыслар андый та-
гый үсешкә юл куймады-
ясалма тыкшыну со-
ында ни тарих, ни әдәбият
м тел ягыннан нигезлән-
гән парчалауны гамәлгә
ырдылар.

Болай аерым-аерым
рки әдәбиятларның бар-

алар 745-840 елларда шунда көчле бер дәүләт корган уйгырлар исемен файдаланды (Йоһаннес Бенсинг. «Үзбәк һәм яңа уйгыр әдәбияты», — «Төрек дөньясы әдәбияты» җыентыгы. Истанбул, Төрек дөньясы араштырмалары вакыфы, 1991. Бит 85, 98). Фәкать икесе дә тарихи бер үк төрки кавемгә — карлыкларга тоташкан үзбәкләр белән уйгырлар арасында аерымлык һичбер заман тулы сыйфатта ачыкланмаган. Шуңа да карамастан, бу танытма бераз соңрак кытайлар тарафыннан да кабул ителә һәм әлеге төбәкнең халкы да шуңа ияләшә, безнең көннәрдә инде уйгыр атамасы тәмам ныгып бетә.

Бу яклардагы Бохара, Сәмәрканд, Хива, Һират, Кашгар, Фирганә һәм шундый бүтән зур шәһәрләр, бары үзбәкләрнең генә түгел, казакъ, каракалпак, кыргыз, таҗик, татар һәм төрекмәннәрнең дә әһәмиятле мәдәни мәркәзләре

КИРӘК

кка китерелүе өчен төр-
төрки шивәләр язма тел
әсенә күтәрелде, ал-
итлары үзгәртелде, ул
да имла (орфография)
ьәләсе дә яңадан кара-
л, шивәләрнең бер-бе-
нән мөмкин кадәр ера-
ы, мөстәкыйль язма
әби) тел хәленә килүе
н иң нык аерыла торган
еш рәвешләре әдәби
нигезендә салынды.
ың өстенә әүвәл яңа-
окә күчү, соңыннан
с хәрефләрен кабул
рү дә бу хәрәкәтне ны-
ты, әнә шулай урыслар-
бөтен теләкләре гамә-
ашырылды, бу хәл әле
дәвам итә.

игрәк тә Сталинга сыл-
ган, ләкин асылында
с идарәсенең төрле дә-
ерендә даими гамәлдә
ган басып алу, эретү
йоту сәясәте 1930 ел-
да яңадан куәтләнде,
киләр тарихы тәмам бо-
тылдырылган кебек,
ият та пыран-заран
релде.

Ул вакытка кадәр Төр-
ган буларак танылган
салма төстә төрле төр-
җөмһүриятләргә аерыл-
урыслар тарафыннан
н да элегрәк Казагы-
дип аталган җир Урта
төшенчәсеннән тө-
тышта калдырылды.
слар шулай XIX йөздән
лап Казагыстанны Тө-
таннан аердылар һәм
ографик атаманы бө-
дөньяга кабул иттерде-
1920 еллардан соң өк-
ләп Төркестан урыны-
Урта Азия» атамасын
ана башладылар. Бу
әтнең табигый бер нә-
се буларак Төркестан
хы, мәдәнияте үзбәк-
казакълар, каракал-
ар, төрекмәннәр, кыр-
ар һәм таҗиклар ара-
а бүген һичкемнең кү-
нә хуш килмәгән рәве-
парчалана. Бу сурәттә
лар каршында калкуы
мал куәтле бер «Боль-
стик Төркестан» хәве-
е юкка чыгарылды.

ыслар 1921 елда Таш-
а үткәрелгән бер ко-
йда Шәркый Төрке-
да яши торган төп ка-
е атар өчен хәтта бо-
ы бер төрки кабилә
ен дә терелтте: алар-
уйгыр» дигән аерым
тник берәмлек төсен-
аныды. Моның өчен

буларак танылган. Гасырлар дәвамында мондый шәһәрләр даирәсендә барлыкка килгән һәм үскән мәдәниятне: тарихны, телне һәм әдәбиятны хәзер ничек бары бер этник төркемгә генә мирас итәргә? Тарихта «чагатай төркичәсе» диелгән гомум Урта Азия язма телендә һәм ул чорда төркиләр тарафыннан да киң рәвештә әдәбият һәм гыйлем теле буларак кулланылган фарсыча (яки таҗикча) иҗат ителгән әсәрләрне бүген төрки кавемнәр арасында нинди бизмәндә үлчәп бүлешергә?

Тарихта мөселманлыкны кабул иткәннән соң үзенчәлекле җирле тормышын корган төркиләрнең үзләрен атар өчен бары «төрек» яки «мөселман» этнонимын куллануларының аркасында, күп гасырлар элек яшәгән байтак укымышлының, шагыйрьләрнең һәм галимнәрнең милли тамырын барлауда хәзер шактый бәхәсләр чыга. Совет дәверендә кулланылган алым буенча, халыкларның әдәбияты телгә алына икән, мәгълүм төбәкнең бүген кайсы дәүләтчелек эчендә калуына баглы рәвештә, анда туган борынгы бөек шәхесләр дә әлеге җөмһүриятнең төп милләтенә нисбәтләнә. Бу дөрес буламы соң? Мисалга, Нәваиның асылы уйгырлардан икәнлеген беләбез, бүген аны үзбәк әдәбияты кысасында тикшерүне, уйгыр әдәбиятына баглы хәлдә өйрәнүме дөрес булыр? Әллә озак еллар Һиратта яшәвен искә алып, аны бүтән әдәбият эчендә калдырыргамы?

Шундый ук тәртиптә борынгы заманда тулаем Төркестан язма теле хисапланган чагатайчаны кулланган һәркемне, тудырган кавем-кабиләсе билгеле булса да, үзбәк әдәбияты тарихына кертеп кенә тикшерәчәкбезме? Төрекмән булганлыклары ачык беленгән Бәйрәм Хан кебек кайбер шәхесләрне тулаем, әдәби телләренә баглап, үзбәк әдәбияты эчендә генә карарга кирәкме? Бу ысулның әнә шулай һичбер логикага сыймавы кемгә дә сер түгелдер, мөгаен.

Күпреленең катгый рәвештә белдерүенчә, төрки әдәбият башлангычыннан алып билгеле бер заманга кадәр бербөтен төшкил итә, бу бөтенлек вакыт узу белән кайбер шивә әдәбиятларына әверелеп дәвам итсә дә, нигез үзлекләрен югалтмый, кискен үзгәрми. Кайбер аермалык исә телдәге җирле сыйфатлар артуына гына кайтып кала.

Шушы хәлдә иң эзлекле, мантыйклы бер эш — төрки кавемнәрнең сәяси тарихларын да күздән кичереп, әдәбиятны киң җирлеге һәм уртаклыгы белән кабул итү. Совет дәверендә чагатай төркичәсен «иске үзбәкчә» дип, кыргыз һәм төрекмәннәрнең совет дәверенәчә язма әдәбиятлары юк иде, дип раслау дөрес булмаган шикелле, тарихны әнә шулай аңлату да кабул ителә алмый.

«Гомум көнчыгыш төрек әдәбияты» һәм «гомум Төркестан әдәбияты» эчендә җирле үзенчәлеккә ия әсәрләр булса да, уртак төрки әдәбият кимендә XIX гасырга кадәр дәвам итә һәм шушы дәвергәчә көнчыгыш төрки кавемнәренең һәммәсенең язма әдәбияты «Төркестан әдәбияты» исеме астында бары бербөтен буларак каралырга тиеш.

Хәтта төньяк-көнчыгыш төркиләренең зур бер өлешен тәшкил иткән татарларның һәм башкортларның әдәбиятын да әлеге «гомум көнчыгыш төрек әдәбияты»ннан аеру бик үк дөрес түгел. Чөнки урыслар 1552 елдан башлап кулларына төшергән бөтен төрки илләрдәге мәдәният әсәрләрен, шул исәптән, әдәби әсәрләрне дә нигездә юк итәләр. Алтын Урда заманында чынлыкта Төркестанга бик якын бер әдәби традициягә ия булган кыпчак даласында яшәүчеләр һәм Идел-Урал төбәге татарлары XYIII йөздән соң да, мәгълүм сәбәпләр аркасында, Төркестан белән якын бәйләнешләр урнаштыралар, һәлакәткә очраган мәдәниятләрен яңадан аякка бастырганда Төркестанга һәм шул чорда яңарак мәйданга килгән Госманлы казанышларына таяналар. Бигрәк тә бу елларда Төркестаннан бәреп чыккан суфичылык шигърыятенең бөтен кыпчак даласында һәм Идел-Урал төбәгендә зур йогынтысы булганын беләбез.

Шунлыктан, бүген татар, башкорт, хәтта нугай, комык, карачай-балкар һ.б. исемнәрдә йөртелгән төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш төркиләренең язма әдәбиятлары XIX гасырга кадәр «гомум Төркестан әдәбияты» эчендә каралуы табигый. Дагыстанга, Кавказга якын кавемнәрнең язма әдәбияты өлешчә Әзәрбәйҗан белән дә якын мөнәсәбәтләргә керүе бу хәлне артык үзгәртмәс.

Искә алынган төрки төбәкләрдә язылган күп кенә әсәрләрнең телләре дә бер-берсенә шактый якын. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф»ның авторы Галинең кайбер төрки кавемнәр тарафыннан үзләренә нисбәт ителә алмавы моны күрсәтмимени?

Төрки дөньяны сыйфатлыйбыз икән, без куллана торган «көнбатыш төрекләре» сүзтезмәсе Төркия һәм Әзәрбәйҗан төркиләрен берләштереп күздә тотуны аңлата. Төрекмәннәр дә шушы төркемгә керә һәм аны Төркестанга тоташтырган күпер вазифасын үтиләр.

Көнбатыш төрекләренең — угыз һәм төрекмәннәрнең әдәбияты тууы да Күпреле тарафыннан төп сыйфатлары белән сурәтләнә.

Үз үсешен бергә дәвам иткән көнбатыш төрек әдәбиятлары, ягъни әзәри һәм Төркия төрекләренең әдәбиятлары арасында 1920 елларга кадәр яшәгән якын бәйләнешләр урыслар тарафыннан алдарак искәртелгән сәбәпләр аркасында, тулаем инкарь ителде һәм гамәлдән калдырырга омтылынды. Аеруча Әзәрбәйҗанның төрек булуына тырыша-тырыша күләгә төшерделәр. Бу төрки кавемнең тарихи килеп чыгышы ап-ачык булганы хәлдә, урыс шовинистлары, Иран шовинистлары белән берләшеп, бу кавемнең асылда иранлы булулары, угызларның Иран, Кавказ һәм Әзәрбәйҗан җирләренә XI гасырдан соң күпләп килеп урнашкач, җирле халыкның төрекләштерелүе хакында сафсата сатып, бу төркиләр мәдәниятенә Иран буявын яктылар. Шуның өчен дә, төреклегенә һич бер шик булмаган Ганҗәле Низами шигърыятен бер якка куеп торсак, Авеста кебекләрнең иске Иран мәдәнияте җимеше булган кайбер әсәрләрен Әзәрбәйҗан мәдәниятенең нигез ташы итеп күрсәтәләр. Шуңа бәйле рәвештә Әзәрбәйҗанның иң борынгы әдәби әсәрләре арасында саналырга тиешле «Дәдә Коркыт»ны озак дәвер инкарь итәләр, хәтта алай гына да түгел, бервакыт тыялар да! Чөнки Әзәрбәйҗанны Төркиядән ераклаштыру, Иранга якынлаштыру урыс мәнфәгатьләренә файдалы иде.

Асылда төрек мәдәниятенә Иран буявын ягу, шуның белән төркилек аңын какшату бары Әзәрбәйҗанда гына гамәлгә куелган совет программасы түгел. Шундый ук сәясәтнең төрекмән, үзбәк әдәбияты тарихларына карата үткәрелүен дә күрәбез. Бу төрек кавемнәренең телләре һәм милли асыллары аларның мәдәнияте нигезе итеп кабул ителми, хәзер яшәгән җирләрнең тарихы һәм мәдәниятләре исә аларга нисбәтләнә, әнә шулай төркилек аңын зәгыйфьләндерергә тырышыла. Бу төрки кавемнәрнең әдәбият тарихлары Авеста, Бундаһешн, Денкард, Томрис, Ширак шикелле Иран һәм хәтта Һинд чыганакларына тоташтырылуын күрербез.

Белгәнебезчә, бүгенге Төрекмәнстан һәм Үзбәкстан җирләре Көнбатыш һәм урыс тарихчыларының бер өлеше тарафыннан борынгы заманда Иран кабиләләре йорты булган диеп күрсәтелә. Бу җирләрнең, хәтта Кавказ һәм Әзәрбәйҗан тирәләренең, сака һәм һун төркиләре белән якын элемтәдә булганлыгын юри белмәмешкә сабышалар.

Совет дәвере әдәбият тарихларындагы иң зур методологик ялгышларның берсе «марксистик-ленинчыл» дип аталган бер хөкем йогынтысында» язылды.

Төрки кавемнәр тарихының мәгълүм бер дәверендә феодаль бер җәмгыятькә берләшеп яшәгән. Моны кире кагып булмый. Әмма әдәбиятны бары тик кырыс сыйнфый көрәш принцибыннан чыгып кына тикшерү байтак иҗатчыларны «сарай шагыйре» дип хаксыз тамгалауга сәбәп булды.

Әдәби әсәрләрнең, фикер тарихын катгый материалистик һәм атеистик төшенчәләргә таянып аңлатуы, күп кенә әсәрләрнең дини мотивларны эченә алуы сәбәпле, аларны тәмам әдәбияттан себереп түгүгә китерде. Әхмәт Ясәвинең һәм тулаем суфичылык шигърыятенең якын заманнарда бары әдәбият тарихларында гына искә алынуы күпләргә билгеле. Әзәрбәйҗанда Фөзулинең, Үзбәкстанда Нәваиның һәм Төрекмәнстанда Мәхтүмколыйның, Татарстанда Тукайның дини рухтагы байтак әсәрләре телгә алынмый. Алар йә басылмый, йә аларның авторлары әледән-әле мантыйксыз тәнкыйть утына тотыла.

Уртак Төрки мирасын бүлгәләү, кайбер төрки кавемнәрне максатчан бер төстә, үзара ераклаштыру һәм араларында бәхәс, гаугалар чыгару өчен, мәшһүр шәхесләрне бер-берсеннән дәгъвалаулар оештырыла. Ягъни бер халыкның атаклы язучысын икенче халык үз әдәбияты тарихына кертеп җибәрә. Мәсәлән, төрекмәннәр Кадый Борһанетдин, Нәсими, Фөзүли, Караҗауглан, Нәваи кебек затларга үз әдәбиятларында урын бирүдән чигенмәгәннәре сыман, Гомәр Хәйям, Сәгъди кебек фарсы әдәбияты классикларын да үз мәдәниятләре тарихларында телгә алалар. Асылда бу, алдарак та искәрткәнебезчә, төрки әдәбиятларның уртаклыгы күз уңында тотылса, матур бер күренеш булыр иде. Фәкать гадәттә «шовинистик» бер төшенчәдә һәр нәрсәне җирле мәдәниятkә, кабиләгә, тар төбәккә таяндырып, «киң карашлы» хәрәкәтләре белән кешене котелмәгән дәрәҗәдә шаштыралар. Әмма без беләбез: болай үзләштерүләр, үзеңнеке итүләр төрки кавемнәр арасында мәдәни гаугаларның капкасын ача. Ахыр чиктә урысларның максатлары да шул лабаса!

Кайбер әдәбият тарихларында төрки кавемнәрнең үткәндәге бөек һәм уртак мәдәниятләреннән гадәттә һич бәхәс чыгармаган ташъязмаларга, Кашгарлы Мәхмүтнең, Әхмәт Йөгнәкинең, Йосыф Хас Хаҗипның әсәрләренә урын бирелә. Инде кайбер кавемнәр бу әсәрләрне дә бары үзенә генә нисбәтләүнең юлын эзли башладылар сыман!

Бу омтылышны кайбер халык авыз әдәбияты җимешләренә, аерым алганда, дастаннарга ия булырга тырышучылардан күрергә мөмкин. «Дәдә Коркыт», «Күруглы», «Алпамыш», «Кубланды батыр» кебек, асылында бөтен төрки дөньясыныкы түгел икән, күп кенә төркиләрнең уртак малы булган бу әсәрләрне катгый һәм гади «кабиләчелек» аңы тәэсирендә, бары бер төрек кавеменә генә нисбәтләргә маташучылар бар.

Төрки кавемнәрнең әдәби төшенчәсендә күренгән һәм, сәбәбе нинди генә булса да, мәйданга чыккан андый саташуларны хәзер инде төзәтү һәм шушы хакта бергә җыйналышып аңлашуның вакыты җиткәндер, дип саныйбыз.

Мөстәкыйльлекнең бер шарты да кешенең үз төшенчәләрен үзе камилләштерүе лабаса. Якын киләчәктә урыслардан мираска калган ялган тарих, ялгыш төшенчәләр уртадан калкып чыгачагын һәм гомум, уртак төрки тарихның төрки кавемнәр күзеннән яңадан кичерелеп аңлатылачагын өмет итәбез, чөнки бары шуннан соң гына дөрес әдәбият тарихлары языла алыр.

Төрекчәдән **Тәүфикъ ӘЙДИ** тәрҗемә итте.

Фәнис ЯРУЛЛИН

Яңгыр

Матур булып яңгыр явып үтте,
Чистарынып калды бар дөнья.
Сөенешеп коендылар гөлләр
Көтеп алган язгы яңгырда.

Үләннәр дә юылган чәч кебек,
Кинәт кенә китте күпереп.
Сөендерде яңгыр бар дөньяны,
Килгәнгәме бик тә көттереп.

Сабырлыкка сынау узды һәр гөл —
Һәм аларның өмете акланды.
Һәр үсемлек бер йотым су эчте,
Шуның белән гомер сакланды.

Күп вакытта бер йотым су җитми,
Йә җитми бер йотым һавасы.
Шундый якын шундый кыска бит ул —
Яшәү белән үлем арасы.

Клара БУЛАТОВА

* * *

Купга каләм дөрес, сирәк алам
Ә шулай да шактый күп язам.
Кайчагында үзем уйга талам:
Кемнәр укый аны? Ник язам?

Җаннар ярып язган әйберләрең
Югалмасмы шушы кәгазьдә?
Бик ихтимал шулай булуы да
Басылмыйча ятса әгәр дә.

Ә аларда без яшәгән көннәр,
Без кичергән хәвеф аларда
Гүя чорны ачар каберлекләр,
Көннең йөзен ачар авазлар.

Каберлеккә барып йөрим әле.
Дөрес ансы. йөреш бик сирәк.
Ә базарга менә барганым юк,
Акчасызга базар ник кирәк?..

Әз-мәз генә мәзәк

Кем арбасына утырсаң...

Могтәбәр бер журналда Фәнзаман Батталның фотосурәте белән саллы гына әңгәмәсе басылып чыга. Шушы куаныч уңаеннан берничә каләмдәше аның фатирында очрашалар, «өстәл» корып җибәрәләр.

Фәнзаманның, билгеле инде, чәе дә, мәе дә җитәрлек була. Гәпләшәләр, фикер алышалар, акыл көрәштерәләр.

Тора-бара кунаклар тагын да сүзчәнләнеп, җегәрләнеп китә. Һәркайсының сөйлисе килеп кенә тора бит, әттәгенәсе! Әмма ул чакларда тамчы да хәмер капмаучы Фәнзаман, сөйләшү-гәпләшү дигәндә теле-телгә йокмыйча, кунакларыннан да уздырып, сүз чаптарын һаман үз кулында тота.

Шунда Рашат Низами түзми, әйтеп куя:

— Син, Фәнзаман абый, бездән дә ныграк «кәефләндең» бугай. Түлке, зинһар, иртәгә баш төзәтә күрмә, ярыймы?..

— Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың икән ул, егетләр... — ди Фәнзаман.

Котылу юлы

Ихлас шагыйрь болай сөйли:

— Малай беренче хатыннан уңмагач, икенчесенә өйләнгән идем. Эттән качсаң, бүрегә эләгерсең, дигәндәй, монысы беренчесеннән дә яманрак булып чыкты. Каһәрләвенә түзә алмыйча,яшь хатынга талак биреп, янә беренчесе белән никахны яңарттым. Әмма әлегә хәтле яше белән фатирны бүлешеп булмый. Бер түбә астында яшибез. Фатирда үзе генә калмакчы була, бүлешүне һаман суза. «Тиз арада бүлешмәсәң, карт хатынымны монда китерәм!» — дип куркытмакчы булган идем. керфеге дә селкенми! «Аны китерсәң, беребез бетәчәк, икенчебез төрмәгә керәчәк!» — ди.

— Ә син ни дидең соң? — дип сорыйбыз ихлас шагыйрьдән. Ул мыек астыннан елмая:

— Ни диим. Шөкер, икегездән берьюлы котылам икән алайса! — дидем.

Авыруы әйбәт икән...

Шагыйрь Гәрәй Рәхим Мәскәүдә яшәгән чагында Казандагы бер дустына мондый хат язып җибәргән: «Син, хәлләрең ничек, дип сорагансың. Хәлләрем яхшы. Үзем әйбәт кенә авырып ятам...»

Карурманга җиткәнче

Фаяз Дунайның сөйләвенә караганда, аның бер ахирие (күренекле галим) мәҗлестә утырганда гел «Карурман» җырын җырлый. «Карурман»ны җырлый башладымы, беләләр: димәк, инде аның «булуы» җиткән. Шуңа хәзер Фаяз әлеге дустын очратканда болай шаярта икән: «Әйдәле, парин, берәр «Чистай малае»н (ягъни, хәмер) алып, кайда да булса, тегеләр... «Карурманга җиткәнче» утырыйк әле...»

«Буа суы тәмле икән...»

Илленче елларның икенче яртысында шәп журналист һәм язучы Барлас Камаловны Буа район гәзитенә редактор урынбасары итеп билгеләр. Шул көнне ул хезмәттәшләрен үз кабинетына җыеп, яңа урынын «юарга» ниятли. «Конспирация» өчен хәмерне графинга салып, бер стакан белән генә башкарырга булалар. Барлас Хәмитович мөлдерәмә тулы стаканны кулына ала да матур итеп тост әйтә. Инде дә салып куйыйм гына дигәндә, ишекне киң ачып, партия райкомының беренче секретаре килеп кермәсенме! Яшь урынбасар нишләсен, инде иреннәренә китергән стаканны кире өстәлгә куйса, сер ачыла, эчеп бетерүдән башка җай юк. Һәм ул шулай эшли дә. Райком секретареның авыр карашы астында кырлы стаканны тын алмыйча тәки салып куя бу. Үзе, ачынуын һичбер сиздермичә:

— Аһ, бу Буаның суы бигрәк тәмле икән! — дип куя. Коллективның болай җыелуын чираттагы летучка дип аңлата.

Райком секретаре тамагын кыргалап чыгып китә, аны-моны әйтми. Тик соңыннан, берничә ел вакыт узгач кына, бер мәҗлестә Барлас Камаловка елмаеп болай ди:

— Ярый, теге вакытта «тәмле Буа суын» ачынмый-нитми төшереп бетерә алдың. Төшереп бетерә алмаган булсаң, үзеңне эшеңнән төшерергә исәп барые, шельма!

Учак янына җыелган сыман...

«Мәдәни җомга» татар халкының һәрбер гәзитен һәм журналын хөрмәт итә, һәрбер яңа басманы үз кардәше, карендәше итеп таный. Ә «Казан утлары»... Әйе, «Казан утлары» — якын кардәшебез, инде 75 елдан артык халкыбызга хезмәт итүче, акыллы-фикерле якын дустыбыз. «Казан утлары» һәм «Мәдәни җомга» тирәсенә туплану чыннан да җырдагыча, учах янына җыелу булсын!..

Шәп рифма тапкан

Илдәге торгынлык чорыннан соң, ил башлыгы булып Горбачев сайлангач, Рәшит Әхмәтҗан рифмалаштырып әйткән иде:

— Горбач... Горбач... Горбачның эшләре бармас... — дигән идә.

Шәп рифма тапкан бит талантлы шагыйрь.

Кем бете бит...

Бервакыт нәшрият коридорында мөхәррир Яхъя Халитов белән язучы Туфан Миңнуллин очрашалар. Туфан әр-яңа ондатра бүрек кигән.

— Ай-яй, малай, бүрекнең кәттәсен эләктергәнсең! — ди Яхъя Халитов. — Пьесалар яза-яза тәмам баедың.

— Ә кәк же, — ди Туфан горур гына. — Кайбер редакторлар кебек сәләмә бүрек киеп йөрергә безне кем дип белдең?

Бу сүз Яхъя Халитовның кытыгына тия.

— Кая әле тотып карыйм, — дип бүрекне сузылып ала да эченә күз ташлагач әйтә:

— Һи, бетле бүрек икән ич бу! — ди.

Туфан да сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел:

— Бетле булса да, Туфан бөте бит ул, ярлы-ябагай редактор бөтә генә түгел, — дип көлеп китеп бара.

Агарды чәчләр, агармас...

«Казан утлары» редакциясе урнашкан йортның унынчы каты коридорында Рәис Даутов белән Мөннаф очрашалар. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Рәис абыйның күзе әңгәмәдәшенең чәчләренә төшә.

— Мөннаф дус, синең дә чәчең агара башлаган лабаса!

Мөннаф шагыйрь Сибгат Хәким шигыре белән болай җавап бирә:

— «Агарды чәчләр, агармас, утларга кер дә икән...»

Рәис Даутов:

— «Казан утлары»нда эшләп йөр дә икән, — дисәңчә...

«Кирәкмәс шул!..»

Түгәрәк юбилеенда Сибгат Хә[...]гә Казан мехчылары бик әйбәт[...]затлы бүрек бүләк итәләр. Башын[...] кигереп куялар.

Юбилей кичәсенең концерт ө[...] башлана. Җырчылар шагыйрьнең [...]гырьләренә язылган җырларны [...]лыйлар. Менә Илһам Шакиров «Башка берни дә кирәкми...» дип [...] түе була, залдан Нәби Дәүли үзе[...] карлыккан тавышы белән репл[...] ташлый:

— Кирәкмәс шул! Һәр юбилее[...] яхшы бүрекләр биреп торгач, Сиб[...]нең башына берни дә кирәкми, к[...]шны!..

1996 ел хәзинә[...]

«Казан утлары» журналы [...]ләсе елда сезнең игътибарга б[...] так кына кызыклы әсәрләр һ[...] язмалар тәкъдим итәргә җыен[...] Менә шулардан кайберләре:

Тәлгать ГАЛИУЛЛИН. «Тәүб[...] Бүгенге көннәр романы.

Гурий ТАВЛИН. «Һәлакәт». Р[...]ман.

Әнәс ГАЛИЕВ. «Хыял диң[...]зе». Роман.

Габдулла ШӘРӘФИ. «Тормы[...] арбасы». Повесть.

Зөки ЗӘЙНУЛЛИН. «Ат[...]лары». Повесть.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. «Аты[...]ган йолдыз». Пьеса.

Фәрит ЯХИН. «Мөхәммәт п[...]гамбәр турында кыйсса». 2 н[...] китап.

Рабит БАТУЛЛА. «Мин А[...]каны ачтым». Сәяхәтнамә.

Рафаэль СИБАТ. «Текә ку[...]релеш». Документаль повесть.

Сәйфи КУДАШ. Дәрдмәнд [...]рында истәлекләр.

Булат СОЛТАНБӘКОВ. Ф.К[...]рим, А.Шәехгали, Алкиннар; С[...]линның сәркатибе булып эш[...]гән М.Бунтуков турында та[...]хи-документаль язмалар.

Шулай ук танылган әдипләр[...]без, галимнәребез һәм публи[...]стларыбыз **Әбрар КӘРИМУ[...] Гариф АХУНОВ**, Аяз Гы[...]**ҖЕВ**, **Индус ТАҺИРОВ**, Мир[...]сыйм **ГОСМАНОВ**, Ринат М[...]**ХӘММӘДИЕВ**, Рафаэль **МОСТ[...]ФИН**, Миргазиян **ЮНЫС**, Мө[...]сүм **НАСЫЙБУЛЛИН**, Мәхмүт Ә[...]**МӘТҖАНОВ**, Тәүфыйкъ Әй[...] һ.б. үзләренең яңа язмаларын т[...]къдим итәчәк.

Габдулла Тукай, Фатих Ә[...]хан һәм Мәхмүт Галәүнең туу[...] — 110 ел, Муса Җәлилнең ту[...] 90 ел тулу уңаеннан да кызык[...] язмалар белән танышырсыз. С[...]җидә Сөләйманова, Хисам [...]мал, Габдулла Шәрәфи ке[...] язучыларыбызның юбилейла[...] да журналыбыз битләрендә [...]гылыш табачак.

Шагыйрьләребездән Га[...] Афзал, Наҗар Нәҗми, Әхсән Б[...]ян, Илдар Юзеев, Равил Фәй[...]лин, Ренат Харис, Айдар Хә[...] Лена Шагыйрьҗан, Флера Гы[...]зәтуллина, Салисә Гәрәева, К[...]ра Булатова, Рәдиф Гаташ, [...]мил Маннап, Харрас Әюп, [...]фәт, Мөдәррис Әгъләм, Р[...] Низами, Зиннур Мансуров, Р[...] Зәйдулла һ.б. үзләренең яңа [...]гъри шәлкемнәрен тәкъдим [...]ләр.

Сират күперен кичкәндә

БЕР ХАТАНЫҢ ЙӨЗ «ӘҖЕРЕ»

Матбагa күрәсең хәреф хаталарыннан һич тә арына алмастыр Дөньяда беренче китапны баскан алман баласы Гутенберггән башлап бүгенгә көнгә кадәр ул хаталар белән ничекләр генә итеп көрәшеп карамасыннар лекин әлле ни алга сикереш сизелгәне юк әлегә Бу — тараканнар белән көрәшүне хәтерләтә син даруны сибә торасың ә таракан мыскыл иткәндәй идән ярыгыннан тагын мыегын селкетә башлый Пентагон булып Пентагонның күпьеллык көрәштән соң таракан каршында ике кулын күтәрүе юкка гына түгелдер инде Акчаны кая куярга белә торган американнар әнә ич, миллион долларларны шул көрәшкә сарыф иткәннән соң, нәтиҗә булмасына ышангач җитәр дип бу эшкә кул селтәделәр

Дөрес, кайбер мәшһүр нәширләр зур-зур чыгымнар тотып бер хатасыз китап чыгарырга маташып караганнар лекин андый эш хәтта Сытин әфәнде кулыннан да килмәгән Хәзерге компьютерда җыю системасы бу «гөнаһ»тан котылырга ярдәм итә дә кебек үзе Ләкин укыган кеше белә әлегә моның киресе күзәтелә Китап мөхәррирләре җыючылар хата чүпләүчеләр (корректорлар) һәм журналистларга көн саен бер тамчы булса да дегет таммый калганы юк әле

Татарстан матбагасы тарихы да безгә андый мисалларны түйганчы бирә ала Әйтик 1979 елда Табеев күп куйган Совет власте елларында республика ирешкән уңышларны чагылдырган китап чыгады Милли мәсьәләләргә багышланган һәр әсәрдә диярлек Татарстаннан куылган экс премьерның язма соравына Ленинның җавабы китерелә Бу сорау-язуында Сәетгалиев хәйләкәр сораулар ярдәмендә милли республикаларның кирәкме-юкмы икәнлеге хакында юлбашчыдан тиз генә җавап алырга өметләнә Хәлбуки Ленин әле сыртын сындырачак җирле функционерга караганда милли хәрәкәт белән «уйнау» сәясәтен дәвам иттерүнең кирәклеген ныграк белгәнлектән кистереп республикалар әле озак вакытка кирәк булачак («еще надолго») дип җавап бирә Сәетгалиевнең бу җавапны ике ел буе беркемгә дә күрсәтми йөрүе юкка гына булмагандыр шул

Һәм менә әлеге китапта Ленинның җавабы «еще недолго» дип басылган Ни булгандыр әйтүе кыен һәрхәлдә кайберәүләр гөманынча мин монда «Табеев фетнәсе» булгандыр дип уйламыйм Тәгаен бу очракта да бездәге башбаштаклык үз ролен уйнагандыр ә бәлки китапны «дүшәмбе» көнне җыйганнардыр Тик бу 60 нчы елларда булган хәл эшне еракка җибәреп тормыйлар Тиешле кешеләрне тотып сүгәләр дә шуның белән эш бетә Әгәр дә 30 нчы еллар булган булса, бик күп башлар җиргә тәгәрәр иде әлбәттә Чөнки классикларның хезмәтләрен партия карарларын һәм позунгларын белгән аркылы үзгәртү юлы белән матбугатта контрреволюцион пропаганда алып бару дигән формулировка РСФСР җинаять кодексының гаять әшәке 58 нче маддәсенең 10 нчы пунктына туры килә иде Совет властен бәреп төшерүгә чакырган һәм советка каршы коткы алып барган өчен аяусыз җәзага тарту авторның үзеннән башлап полиграфчыларга кадәр барлык матбага эшчеләренең баш очында Дамокл кылычы сыман бер кыл бәртегендә генә асылынып тора иде

30 нчы елларда моңа охшашлы «эш»ләр берсе артыннан берсе туып кына тора Фетнә эзләмәгән «бөрмә» калмый Әгәр дә инде китапның авторы йә тәрҗемә кылучысы «халык дошманы»на чыгарылса китапны да үлем җәзасы көтә Татарстанда мәсәлән бу елларда уку-укыту әдәбиятыннан гына да берничә дистә исемдәге китап яраксызга чыгарыла Сәясәткә кагылышлы китаплар язмышын инде әйтеп тә торасы юк Главлит цензура булуына да карамастан матбугат чыгарган бөтен продукцияне аяусыз тикшереп бару НКВД органнарына йөкләнә «Органнар»ның «оперуполномоченные» алдан карап чыкмый торып нәшрият келәтләреннән бер генә китап та читкә җибәрелә алмый Үз чиратында «опер»лар да «фетнә»не күрми калган өчен «башлары» белән җавап бирәләр Әмма төрле хәлләр килеп чыга тора дөньяда араларында шактый ук берәгәйләләре дә

Без бүген шуларның берсе турында сөйләрбез Чөнки анда республиканың рухи вә мәдәни тормышында зур гына урын тоткан кешеләр катнаша

30 нчы еллар башы һөҗүмчән алласызлыкның котырган еллары була Гыйбадәтханәләр ябыла меңнәрчә дин әһелләре Себергә куыла Бу язмыш бер генә динне дә читләтеп үтми Илнең Аурупа өлеше мөселманнарының үзәге булган Татарстанда бу бигрәк тә Ислам диненә «элэгә» Радикаль алласызлар бер селтәнүдә динне бетерергә ыргылганда шундый адымнар ясыйлар ки моңардан хәтта Мәскәү дә саташа кала Әйтик Коръәнне утилгә тапшырту буенча күмәк кампания башлангач Сталин күрсәтмәсе белән ул туктатыла ә «Кызыл Татарстан» газетасының таярь хәбәрчеләре «Дуңгыз ничек Коръәнне җиңде?» дигән мәкалә өчен шелтә дә алалар хәтта Анда бер авыл советының ябылган мәсҗед бинасын дуңгыз абзары итәргә рөхсәт бирүе уңай якган бәяләнгән була Карарда дин белән көрәшне туктатмаска лекин андый ук хулиганлыкка охшаш радикаль алымнардан тыелырга да тәкъдим ителә Алдагы бишьеллыкларның берсе алласызлар бишьеллыгы булып һәм ул динне тамырыннан йолкып алырга тиеш дип котелгән бер заман лабаса Шуңа күрә Татарстанда да башка җирләрдәге кебек ук «хезмәт ияләренең соравы буенча» мәсҗедләр чиркәүләр костелләр синагогалар һәм монастырьларны ябу белән бергә динге идеологик басым ясау тагын да көчәеп китә Монда һөҗүмчән алласызлар җәмгыяте эшчәнлеген киң җәеелдерүгә фаш итүле китаплар мәкаләләр бастыруга пьесалар куюга һ б зур әһәмият бирелә Шундый китаплар арасында Тимофей Владимировның «Христос дине нәрсә ул?» дигән китабын ашыгыч чыгаруга аеруча тырышлык куела Китап латин шрифты белән басыла Кереш сүзне мәгълүм журналист «Киңәш» журналының редакторы (аннары ул «Кызыл Татарстан» газетасына күчә) Г Беляев яза Керәшеннәргә юнәлтелгән була китап чөнки алар алласызлык юлына тиз генә кереп китәргә теләмиләр

Китапны әзерләүдә танылган журналистлар һәм язучылар М Галиев И Рәмиев А Ризванов һ б катнаша Җаваплы нәшире Камил Якуб исемендәге типография директоры урынбасары Зариф Насыйбуллин була Ел ахыры Нәшрият та типография дә тизрәк план үтәлүе турында рапорт бирергә ашыга Келәрлек тә еларлык та хәлләргә китергән вакыйгага бу да күрәсең сәбәп булгандыр Ләкин укучым алдан шул китапның тышлыгына күз сал әле Син аны башка бер генә җирдә дә очрата бер генә китапханәдә дә таба алмассың Китап үз заманынча соцконструктивизм рухында күзгә бәрелеп торырлык итеп бизәлгән Уртада - алласызлар җәмгыятенең туграсы тамгасы һәм зур хәрефләр белән аның татарча аббревиатурасы бирелгән Ә өстә ул вакыттагы китапларда да язылып торган шигарь - «Дингә каршы көрәш — социализм өчен көрәш» Һәм менә шунда инде кемдер 1931 елны бөтен Татиздатны типографияне тетрәткән күп кешеләрнең язмышын калҗайткан сәяси бомба тыгып калдыра Игътибар белән укыгыз әле **дин өчен көрәш — социализм өчен көрәш** Сәяси дошманнарны эзләү күмәк шымчылык һәм дингә каршы ярсу көрәш барганда бу Хатаның ничегрәк яңгыраганын күз алдына китерүе кыен түгел Бу инде Маркс һәм Энгельсның мәгълүм формуласын «Барлык илләрнең пролетарийлары таралышыгыз!» дип әйтү белән бер Тикшерү эшендә оператив документлар ягъни иснәү әләк һәм махсус мәгълүмат каналлары аркылы кергән документлар сакланмаган һәм бу бәлки шулай кирәктер дә Шунлыктан НКВДның бу хакта ничегрәк белгәнлеге мәгълүм түгел ләкин эзенә тиз төшәләр 29 декабрьдә З Насыйбуллин белән М Галиевне кулга алып алардан сорау алалар ә Яңа елның икенче көнендә 1931 елның 2 гыйнварында - Исмәгыйль Рәмиев Татиздатның җитештерү бүлеге мөдире урынбасары элегрәк - мәгълүм сәяси эшлекле язучы һәм әдәбият тарихы белгече җавап тота Без хәзер дә аның әдәбият сүзлегендәге тел байлыгына сокланабыз Аның әзекләрен «Татарстан» журналы бастырып та чыгарды

Бу эш ГПУның аерым бүлегенә бирелә аны опервәкил Климашев һәм 1 сектор башлыгы Якунин җитәкли Әлеге каһәр төшкән вакыйгага ГПУның нинди әһәмият биргәнлеге аның аерата җитди сәяси җинаятьләр белән шөгыльләнүче бүлеккә тапшырылуыннан ук аңлашылып тора Бәлкем тулы бер советка каршы заговор да күзләренә күренгәндер Чөнки шуның алдыннан гына кайбер басмалар тирәсендә сәяси җәнҗаллар булып уза Әйтик Гали Рәхимнең Мөхсинов редакциясендә чыккан крестьян хуҗалыкларын социологик тикшерүнең әтрафлы планы бирелгән «Авылны ничек өйрәнергә» дигән брошюрасын шпионнар һәм совет дошманнарына дөреслек дип яла ягалар Дөрес авторларны кулга алмыйлар алуын ә менә китап мескен якты дөньядан китеп бара Шуңадыр инде «бөек борылыш»тан соң авылны анкеталар белән объектив гостә сәяси «камикадзе»ның гына өйрәнүе мөмкин булгангадыр Сүз өрәм итеп «анкета-манкета» турында ник сөйләшеп торырга ди шуннан соң озак та үтми хәтта укучылар өчен «Арифметикадан мәсьәләләр җыентыгы»н да җыеп алалар Андагы бер мәсьәләнең җавабында аерым хуҗалык сыеры сотне колхоз сыерына караганда күбрәк биргән булып чыга каһәр (Ә бит чынында да шулай була һаман да шулай булып кала бирә!)

Хәер тагын «идеологик диверсантлары бызга әйләнеп кайтыйк әле Татиздатта «оялаганнарына» (сорау алуда аларның гаебе шулай бәяләнә һәм бу «кыңгыраулы» эшне тикшерү сәгатьләренә колак салыйк

Менә 1931 елның 1 гыйнварында М Галиевтән сорау алу Эшнең ашыгычлык дәрәҗәсен кара әле син аның ГПУ үз вакытын да җәлләми ә инде тоткыннарыныкын әйтеп тә торасы юк М Галиев «гаебен» шундук таный — әйе тәрҗемәне ул эшләгән Үзенең бу «коточкыч» хатасын ул болайрак аңлата Китап тышлыгын аңа күрсәтергә китергәндә ул «Кызыл Татарстан» редакциясендә Ленинны тәрҗемә кылып утырган һәм юлбашчының бер мәкаләсендәме чыгышындамы әйткән «Икмәк өчен көрәш — социализм өчен көрәш» дигән лозунгысының мәгънәсен ашыгычлыкта үзеннән үзе «алласызлар» китабына күчергән Форсаттан файдаланып ГПУ вәкилләре М Галиевтән «Яңа китап» нәшриятының туу тарихы турында сөйләвен таләп итәләр 20 нче еллар уртасында бу нәшрият фәнни һәм уку китаплары чыгаруда бик тә күркәм эшләр башкара Вәкилләрне күп журналистларның һәм нәшрият эшчеләренең характеристикалары да кызыксындыра икән Галиевнең җаваплары бик тә ачык әмма сәяси төстә түгел алар шул эш көн күреш якларына гына кагыла Шуның белән бергә М Галиев үземнән гаепне алып ташламасам да нәшрият эшчеләренең игътибарсызлыгына гаҗәпләнәм ди Алар үзләренең элементар вазифаларын үтәүдә дикъкатьлерәк булырга тиешләр иде лабаса Бүген дә гаҗәп актуаль яңгырый бу сүзләр

2 гыйнвардагы сорау алуларда И Рәмиев белән З Насыйбуллин үз гаепләрен танымыйлар һәм тулаем М Галиев версиясен ныгытып куялар З Насыйбуллин хатаның бөтен тираж басылып беткәч кенә ачыкланганлыгын әйтә Брошюра аның фикеренчә искергән инде һәм аны сатуга чыгару тышлыкта хата булу булмавына карамастан кирәксез эш ул анда өелгән килеш ята бирә ди Китапның искергәнлеге хакында З Насыйбуллин бераз күзгә төтен җибәрә шикелле китап бит өлкә комитеты контролендә тора «Фетнә»ле китапның сәүдәгә киткәнме-юкмы икәнлеге тикшерүчеләрне бик кызыксындыра булса кирәк Якунинның СОУ (секретное оперативное управление башлыгына китапны сатудан алу кирәклеге турында рапорты бар Хәлбуки ГПУ хезмәткәре А Сафин — нәшриятның келәтләрен тикшерү аңа тапшырылган була -- анда китапның 2953 данәсе саклануын хәбәр итә китап ачык сәүдәгә чыкмаган бөтен тираж конфискациядә һәм утилгә тапшырылырга йә яндырылырга тиеш ди

М Галиев һәм И Рәмиевтән сорау алулар дәвам итә бирә Алар инде бу «чукынчык» китапны бастыру әхвәле кысаларыннан чыгып тулаем әдәбияттагы аеруча аның революциягә кадәрге хәлләренә һәм гражданнар сугышы чорындагы үсешенә кагыла башлый Әлеге «әңгәмә»ләрдә татар халкы аның күренекле вәкилләре әдәби агымнар һәм төркемнәр тормышыннан бик тә кызыклы фактлар табарга мөмкин Кәгазьләрдән күренгәнчә М Галиев тә И Рәмиев тә хәл кадәренчә сәяси бәяләрдән читләшергә тырышалар инде килеп керәләр икән һәркемгә билгеле нәрсәләр турында гына сөйлиләр

Архивларда очратып булмый торган шактый кызыклы фактлар да теркәлгән монда Менә шуларның берсе Мирсәет Солтангалиевнең тәрҗемәи хәле турында материаллар җыйганда автор «депо»да аның бик ачулы бер хатына тап була Хат «Чаян» журналында 1925 елда наркомзем Юныс Вәлидовның вафаты уңае белән басылган бер шигырь хакында Юныс Вәлидов җир мөнәсәбәтләрендә «суверенитет»ны актив яклаган Иделбуйлап һәм Казан тирәсе татар авылларын торгызуга күп көч куйган зат Менә шул кеше үлгәч «Чаян»да җир наркомы җир губирнасына китеп барды тиздән кордашлары да шушында булырлар дигән кебегрәк бер җилле генә такмак басыла Рәмиев аны үзе язганлыгын әйтә ул чакта бу оятсыз чыгышы өчен күп затларның аны хөкем иткәнлекләрен дә яшерми ә «Борһан Шәрәф мине бөтен кеше алдында подлец һәм маңка малай дип атады» дип тә өсти Шулай ук җәмгатьчелекнең «Яңалиф»не көчләп кертүгә каршы көрәшен яктыртучы детальләр дә байтак һ б

Тикшерү узагымы белән бара беркетмәләр языла тегелә тора ГПУ бу эшне контрреволюцион коткы 58 10 маддәгә туры килә дип бәяли Эшне СССР ГПУсының «өчлеге» карарга тиеш була Хәлбуки күрәсең Мәскәүдәге башлыклары белән киңәшкәннән соң карар үзгәртелә «Эш» мантырдай булып күренми һәм шау-шулы фаш итүләр вәгъдә итми

Рәмиев белән Галиев өйдән чыгып китмәскә дип кул куеп 12 февральдә һәм 10 мартта иреккә чыгарылалар Халык теленә «Аллаһ каргышы» буларак кергән бу эш шулай чагыштырмача имин тәмамлана Ә бәлкем шушы «Аллаһ каргышы» дигән халык сүзе дә моңа тәэсир иткәндер кем белә Алласызлар китабы баскан өчен утыралар дигән фикерне нигә куәтләп торырга ди?!

Шулай да аларның исемнәре органнарның хәтерендә бик озак саклана Әмма бусы инде - башка мәүзугъ

Булат СОЛТАНБӘКОВ,
тарих фәннәре кандидаты



Дәүләт Советында

Акча булса, театр төзелеп бетәр

Татарстан Дәүләт Советында булган киңәшмәдә Минзәләдәге Татар дәүләт драма театры бинасын яңартып төзүнең барышына анализ ясалды

Киңәшмәне Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы Мөхәммәт Сабиров үткәрде Анда финанс министры Д Нагуманов мәдәният министры М Таишев Икътисад һәм фараз дәүләт комитеты рәисе урынбасары А Салин Министрлар Кабинеты каршындагы капиталь төзелеш идарәсе җитәкчесе Р Халитов Минзәлә хакимияте башлыгы урынбасары А Хажиев бу корылма белән мәшгуль булган проект һәм төзү оешмалары җитәкчеләре катнашты

Театрны реконструкцияләү 1987-1989 елларда башланган иде Бу хакта Министрлар Кабинетының махсус карары да бар Сәхнәне заманча җиһазлау театр остаханәләре һәм гаражлар өчен янкорма төзү артистлар өчен торак йорт салу планлаштырылган иде Төбәктәге иң өлкән театр юбилеена бик зур бүләк булыр иде бу әлбәттә Әмма эш бик озакка сузылды Үзенең 60 еллык юбилеен каршылаганда театр башка урынга сыенырга мәҗбүр 1995 елда 2 миллиард сумнан артык акча тотылырга тиеш иде, ә тугыз айда шуның 643 миллион сумы гына бирелде Генподрядчының үзгәрүе дә үзен сиздерде. әлбәттә Реконструкция өчен хәзер «Автозаводстрой» төзелеш идарәсе җавап бирә

Акча булмау сәбәпле финанслау да нормаль түгел Төзүчеләр алдындагы бурыч инде 250 миллион сумга житте Ел азагына кадәр бу бурычны да түләргә кирәк Эшне дәвам итү өчен тагын 1 миллиард сум табасы бар Ә реконструкция эшләренә барысы 3 миллиард кирәк булачак

Киңәшмәдә чыгыш ясап Министрлар Кабинеты каршындагы капиталь төзелеш идарәсе җитәкчесе Р Халитов бүгенге көндә заказчының финанс ягыннан бик авыр хәлдә булуын әйтте Театр капиталь төзелеш идарәсенең дә Мәдәният министрлыгының да даими контролендә торса да, акчасыз берни дә эшләп булмасын әйтте

М Сабиров исә контрольнең нәтиҗәлелегенә шик белдерде Әгәр реконструкция эшләре планда билгеләнгән срокларда алып барылса финанслау мәсьәләсе дә алай ук кискен тормас иде чөнки элек бюджетта мондый ук киеренкелек юк иде бит әле диде ул

Киңәшмәдә тагын шундый факт мәгълүм булды Финанс министрлыгы гыйнвар аенда ук инде капиталь төзелеш идарәсенә Минзәлә театрын яңартып төзү өчен 200 миллион сум акча биргән Әмма бу акча корылмага килеп җитмәгән Шунлыктан эшне башкару сроклары да сузылган. субподряд оешмалары. акча булмаганлыктан. эшне июль аенда гына башлаганнар Менә шунлыктан мәдәният министры М Таишев максатчан финанслау кирәклеге турында сөйләде Әгәр театр җитәкчелеге катгыйлык. ныклык күрсәткән булса. ярдәм дә үз вакытында килгән булыр иде.

Бу эштә катнашы булган барлык якларның үзара килешеп эшләве җитмәгән Шәһәр хакимиятенең җаваплы хезмәткәрләре театрны реконструкцияләүдә катнашудан читләшкәннәр. Субъектив сәбәпләр дә бар Мәсәлән. корылманы башка подрядчыга тапшыру вакытында проекттагы кайбер конструктив чишелешләрнең эшләнеп җитмәве ачыкланды. Инвентаризация вакытында проекттан шактый чигенүләргә юл куелуы беленде Проектлаучылар 25 октябрьгә кадәр 20 дән артык позиция буенча техник документларны биреп җиткермәделәр. Чаллының «Татинвестгражданпроект» фирмасы директоры А.Русаков төзүчеләргә инде эш сызымнарының бирелүен әйтте Калган документларны шушы көннәрдә бирергә вәгъдә иттеләр

Проект чишелешләрен үзара килештерү бик акрын бара Заказчы. проектлаучылар һәм подрядчы арасында эшкәртү технологиясе һәм техникасы. эчке биналарның бизәлеше. бизәкләү материалларының төре һ б мәсьәләләрне хәл итү бик озакка сузыла.

Киңәшмәдә катнашучылар эшне тизләтергә ярдәм итәрдәй күп кенә чараларны килештерделәр Финанс министрлыгы төзүчеләр алдындагы бурычны түләү өчен дә. ел азагына кадәр финанслау өчен дә акча табарга тиеш

Бүгенге көндә театр өчен сәхнә җиһазлары сатып алынды. аның төп өлеше Саратовтан кайтарылды Заказчы җиһазларны монтажлау өчен акчаны инде октябрьдә үк түләгән. димәк. «Саратовтеатрмонтаж» эшкә шундук керешә алган булыр иде Киңәшмәдә соңгы срок 10 ноябрьгә билгеләнде

Шик юк. депутат М Сабиров үткәргән киңәшмә нәтиҗәле эш өчен этәргеч булып хезмәт итәр Әгәр театрны реконструкцияләүдә катнашучы яклар әлегрәк шулай җыелып сөйләшсәләр. Дәүләт Советына җыелуның кирәге дә булмас иде

Объектта атна саен шундый планеркалар үткәрергә карар бирелде.

Любовь ВАХРАМЕЕВА.

Гәзит һәм укучы

«Әдәби җомга»га әйләнеп кала күрмәгез

«Мәдәни җомга»ны беренче саныннан ук алдырып киләм 1996 ел өчен дә язылып куйдым Бу яңа һәм шактый кызыклы гәзитнең киң катлам укучыларга әлегә бигүк билгеле булмавы мине нык борчый Азнакай кебек шәһәр киоскларына ул нишләптер килеп җитми Халыкка таныту өчен иң кулай юл югыйсә

Минем гәзиткә карата берничә тәкъдимем дә бар Әлегә мәдәни дөньябыз гәзит сәхифәләрендә таррак планда яктыртыла Гәзит «Әдәби җомга»га әйләнеп калмасын иде Язучыларның әдәби әсәрләрен урнаштыру проблема булмас анысы Ә менә сәнгать дөньясын кем яктыртыр? Журналистлар шул юнәлештә ныграк эшләсеннәр иде Музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина истәлекләренең элекке елларда дөнья күргәннәрен дә яңаларын урнаштырганда да зыян булмас Өлкән буын сәнгать әһелләре белән соңга калмыйча төрле әңгәмәләр корып каласы иде Әйтик. Мөнирә Булатова. Фәридә Кудашева һ б лар белән Безнең театрлар тормышы радио-телевидениенең сәнгать өлкәсендә ничек эшләве турында да беләсе килә.

Дикторлардан Камал Саттарова өлкән буын җырчылардан Мәрьям Рахманкулова, Венера Шәрипова һ б лар турында истәлекләр укыйсы иде Сәнгать уку йортларына гәзит аша экскурсия ясау да муафыйк булыр иде

Яңа елда да гәзиткә уңышлар телим

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай

Алхәбәр

Гыйлемхан янып үлә Үзенең күңелендә хисләрендә. хыялларында янып үлә Гомер буе Донбасс шахталарында бәхет эзләп туган җиренә әйләнеп кайт та, танымасыннар әле сине Авылдашларын белән уртак тел тапма әле?! Үзенең иң соңгы таяну ноктасы — туган нигезенә кайтып тезләнгән иде бит ул Күрәсең соңгы утравы да язмыш дулкыны кочагында калган «Авылдашлар күңелендә матурлыкка урын калмаган! Юк булмагандыр ул әллә булып та мәҗбүри бетерткәннәрме? Йөзлексез тәрәзә буламыни? Йөзлектән аларны кеше генә мәхрүм итә ала Кеше үзе дөнья йөзлеге җир йөзлеге!» Ай-һай нәрсә булган бу дөньяга? Авылдашларга ни булган? Ул аларга ак күңел белән яхшылык эшләргә кайткан иде бит Ә алар? Ярабби байлык артыннан куа-куа адәм баласы шунын кадәр дә үзенең эчке матурлыгын күңел байлыгын югалтса-югалта икән Нишләткәннәр авылны? Кешеләрне нишләткәннәр? Әллә ул ялгышамы? Димәк ул акылыннан шашкан Ул — җүләр! Ха-ха-ха

Авыл матур уйлыймы?

Ринат Мөхәммәдиевнең «Истәлек өчен Гыйлемханга » хикәяте буенча төшерелгән яңа нәфис фильм әнә шундый тойгылар уята Сез аны 18 19 ноябрь кичләрендә карый аласыз «Кайту» дип исемләнгән 1 нче бүлек 18 ноябрь көнне 21 сәгать 30 минутта. «Йөзлекләр» дигән 2 нче бүлек 19 ноябрьдә 20 сәгать 10 минутта күрсәтеләчәк Шунысы кызык титрда урысчага тәрҗемә дә биреп барыла Фильмның сценарий авторы һәм режиссеры Әхтәм Зарипов Рольләрдә — танылган артистлар Әзһәр Шакиров Шәүкәт Биктимеров Ринат Таҗетдинов Ирек Баһманов Фирдәвес Әхтәмова Равил Шәрәфиев Илдус Әхмәтҗанов Рәшит Шамкаев Зөлфирә Зарипова Наил Дунаев Фирая Әкбәрова Идрис Мәсгутов һ б Операторлар Элдар Юмакунов һәм Фәрдәт Мансуров

Әле шушы көннәрдә генә телевидениедә әлеге фильмны карап фикер алышу үткәрелдә Фикер алышуда әсәрнең авторы режиссеры радио телевидение җитәкчеләре фильмда уйнаган кайбер актерлар һәм журналистлар катнашты

Рәмис КЫЯМОВ.

● Фильм турында фикер алышу вакыты.
● Фильмнан бер күренеш.

О.КОСОВ фотосы.

ДҮШӘМБЕ

20 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.15 «Татарстан». 19.45 «Телебуклет» Тапшырулар анонслары. 19.55 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булырга тиеш? 20.25 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 «Татарча сөйләшәбез». 1 нче дәрес. 20.40 «Гашыйклар телеканалы» 21.15 «Язучы фикере». 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Эфирда музыка. 7.30 «Тамаша залы». 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 8.15, 11.05 «Юл патруле». Атналык йомгак. 8.30. 14.45 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!» (МТЖ). 9.20, 12.50 «90х60х90». 9.40 Диск-канал. 10.00 «Чей клуб». 10.30 Сериал: «Один к десяти». 11.20 Атна фаразлары. 11.50 «Валюта бәясе». 12.00 Сериал: «Мстители». 13.05 Нәфис фильм: «Бриллиантовая рука». 15.00 Телесериал: «Флиппер». 15.55 «Фитиль». 16.05 «Минем кино». В.Ресин. 16.45 Нәфис фильм премьерасы: «Свечи во мраке». 18.25 «Минем йолдыз». Вера Васильева. 19.10 Теледискотека. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.40 «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Видеомода». 21.05 «Компаньон» белән Европа буйлап» (Италия). 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Криминаль хроника тележурналы». 22.05 Нәфис фильм: «Американский кикбоксер». 0.55 TAP RECORDS коллекциясеннән.

1 НЧЕ КАНАЛ

Көндезге сәгать 3 кә кадәр профилактик эшләр.
15.00, 18.00, 0.00 «Яңалыклар». 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Марафон-15». 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.00 «Джем». 17.30, 0.35 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.05 «Сайлаулар-95». Бәхәсләр. 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 Документаль фильм: «Майя Плисецкая». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Фантастик детектив: «Электронные жучки-7». «Манна Небесная». 22.50 Эдвард Радзинский. «Тарих табышмаклары. Иоанн Мучитель». 1 нче кисәк. 23.30, 0.10 Сериал: «Твин Пикс».

Тәнге канал

1.00 Людмила Чурсина «Графиня» фильмында. 2.25, 3.10 «Кар Мэн». «Тавыш агрессоры».

«РУСИЯ»

7.00, 9.30, 18.40, 23.55 «Сайлаулар-95». Дәүләт Советы. 7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Барысы да аз-азлап». 9.25 «Телегазета». 10.00 «Бары тик Майя исеме генә». 10.45 «Мәһим мизгел». 10.55 Клип-антракт. «Браво» төркеме. 11.20 Милиция хроникасы. 11.30 Безнең хәбәрчедән. «Язмышлар». 11.45 Документаль фильм: «Тогда в Нюрнберге». 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Могҗизаларга ярты сәгать». 17.45 «Коткару-911». 19.10 «Беркем дә онытылмаган». 19.15 «Алыргамы-алмаскамы». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 «Дүшәмбе саен детектив». «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Почти безнадежное дело» (Бөекбритания). 1 нче кисәк. 21.45 Репортер. 22.05 «К.Симонов һәм В.Гроссман: ул һәм үги малай». Лев Аннинский программасы. 22.45 Видеоклип премьерасы. Н.Караченцов. 23.30 «Вакыт әлгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмәте. 0.25, 1.17 Тәнге телесериал. Нәфис фильм: «Гонка за жизнью» (Италия). 1 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

Көндезге сәгать бергә кадәр профилактик эшләр.
13.00, 15.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле». 13.25 «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.40 Нәфис фильм: «Бедный богач» (Италия). 17.10 «Арлекинолар»ны кара». В.Набоков. 17.30 ТВ мәгълүматлары. Европа калейдоскобы. 18.00 «Сайлаулар-95». 20.00 «Музыка белән бергә!» Дирижер Марис Янсонс һәм Берлин филармониясе оркестры. 22.30 «Шәһәр эшләре». 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Музыкаль шоу: «Парадлар парады». 0.15 Нәфис телефильм: «Валентина» (Италия). 13 нче серия.

СИШӘМБЕ

21 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.15 «Татарстан». 19.45 «Телебуклет» Тапшыру анонслары. 19.50 «Геннадий Зимин. Портретка штрихлар» Телеочерк. («Зәй» телевидениесе) 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Татарча сөйләшәбез». 20.30 «Ерактагы якын кардәшләр» Себер татарлары. 21.05 «КВН-95». Ярымфинал. КДУ КДМУ, КЮАКИУ командалары очрашуы. 22.20 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10, 18.30 «Эфирда музыка». 7.30, 20.20, 23.40 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (20 ноябрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05 «Юл патруле». 8.30, 14.45 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!». 9.20, 12.55 «90х60х90». 9.40 «Диск-канал». 10.00 «Минем кино»: Ф.Ресин. 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти». 11.20 «Атна һәлакәтләре». 11.50 «Валюта бәясе». 12.00 Сериал: «Спасатели Малибу». 13.10 Нәфис фильм: «Коньяк». 15.00 «Музыка һәм матбугат» «Калем осталары». Е.Кемеровский. 15.55 «Зур театр балеты: «Кармен-сюита» М.Плисецкая юбилеена карата. 18.40 Мультфильм: «Крокодил Гена». 19.00 Сериал: «Против течения». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Коммерция өйләнмәсе». 21.05 Мультфильм: «Чебурашка идет в школу». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Туры эфирда уен: «Кичке җыргыш» 22.25, 0.05 Русия киносы көнне. Нәфис фильм: «Любовь». 1 нче һәм 2 нче серияләр.

ЧӘРШӘМБЕ

22 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.15 «Татарстан». 19.40 «Телебуклет» Тапшыру анонслары. 19.45 «Сайлауларны каршылап». 20.15 «Әлли-бәлли-бәү». 20.25 «Татарча сөйләшәбез». 20.35 «Туган ягым — моңым син». Концерт. 20.50 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Бал». Режиссер Этре Скола. 22.35 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда музыка». 7.30, 20.20, 23.55 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (21 ноябрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05, 16.35 «Юл патруле». 8.30, 14.50 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!». 9.20, 12.50 «90х60х90». 9.40 «Диск-канал». 10.00 «Минем йолдыз» Вера Васильева. 10.40 Сериал: «Один к десяти». 11.20, 15.20 «Атна низаглары». 11.50 «Валюта бәясе». 12.00 Детектив сериал: «Ночная жара». 13.05 Нәфис фильм: «Европейская ночь». 15.00 «Тегеләр, кемнәр...». 15.50 Юмористик программа: «Мистер Бин». 16.20 «ПОСТ — музыка яңалыклары». 16.50 «Диск-канал». 17.35 Нәфис фильм: «Джокер». 19.00 «Актуаль әңгәмә». 19.20 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Мультфильм: «Мечта петать». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Үз кешеләр». 22.10 Анни Жирардо, Филипп Нуаре «Украли бедро Юпитера» комедиясендә. 0.20 Red Wave тәкъдим итә: Джим Эванс.

1 НЧЕ КАНАЛ

